
# ШУРА

№18

2017




2000795268362

## Дини альманах

1908 нче елдан бирле нәшер ителә

ЭЧТӘЛЕК

ВӘГАЗЬЛӘР
Кеше – Аллаһы Тәгаләнең могҗизасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 8
Исламда Гайсә пәйгамбәр. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 15
Талак – иң актык чик . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 19
Исламда канәгать булу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 26
Аллаһы Тәгаләнең нигъмәте – туры юл . . . . . . . . . . . . . . . . . . 31
Бердәмлектә - бәрәкәт. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 37
Пәйгамбәр күрсәтмәләре — безгә маяклы юл. . . . . . . . . . . . . . . 42
Карун кыйссасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 50
Үзеңне онытма . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 56
Аллаһка рәхмәтле булу тиеш икәнлеген аңламау . . . . . . . . . . . . 63
Иманның тәме . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 69
Син әзерме?. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 78
Көнчелек турында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 82

СОРАУ-ҖАВАП
Сәҗдә вакытында ике аяк табаны да җирдән аерылса,
намаз бозыламы? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 87
Бурычны кичерү зәкәт түләүгә санала аламы? . . . . . . . . . . . . . . 88
Хаҗи мосафир булып саналамы? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 88

ҮРНӘК ЗАТЛАР
Гарифҗан Буави . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 91
Мөфти Мөхәммәдьяр Солтан һәм аның балалары –
нәселебез горурлыгы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 96

МӨСЛИМӘ
Балаларда компьютерга бәйлелек – аны ничек җиңәргә? . . . . . . 105

ФӘН
Хәнәфи мәзһәбенең ысулы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 110
Җәһәннәм мәңгелекме? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 116
Коръән турында гыйлем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 125
«Әхмәдия» яисә «Кадиания» хәрәкәте . . . . . . . . . . . . . . . . . . 135
Хәләл һәм хәрамга мөнәсәбәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 139

МИРАС

Мәрҗанинең хаҗ сәфәре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 147
Пәйгамбәрләр тарихы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 155
Кием-салым. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 160
Ашау-эчү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 168
Милли матбугатыбыз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 171

ТАРИХ
Дүрт ягым кыйбла: Арчаның тарихи халкына бер сәяхәт. . . . . . . 180
Мөселман руханиларына каршы репрессияләр . . . . . . . . . . . . . . . 189

НӘСЫЙХӘТ
Локман Хәкимнең Коръәндә әйтелгән нәсыйхәтләре. . . . . . . . . . . 197
Пәйгамбәребезнең s кичерү сәләте . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 204
Пәйгамбәрнең s хатын-кызларга мөнәсәбәте . . . . . . . . . . . . . . . 205
Пәйгамбәребезнең s ятимнәргә мөнәсәбәте . . . . . . . . . . . . . . . . 206

ЙӘГЕЗ, БЕР ДОГА
Дога – гыйбадәтнең асылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 209
Намазлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 213

«МӘҮЛИД ӘН-НӘБИ»
«Мәүлид Ән-Нәби бәйрәме» хакында бер-ике сүз . . . . . . . . . . . . 224
Төрки «Мәүлид Ән-Нәби касыйдәсе» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 226

ӘДӘБИ СӘХИФӘ
Муса Акъегет «Хисаметдин мелла» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 240
Ришат хәзрәт Курамшин «Сорый белсәң – теләк, сорый
белмәсәң...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 254

**«ШУРА» дини альманах, №18**

октябрь – декабрь 2017
мөхәррам – рабигыль-ахыр 1439

Альманах Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәтнең (Роскомнадзор) Татарстан Республикасы (Татарстан) идарәсендә 2013 нче елның 17 нче июлендә ПИ №ТУ16-01077 нче теркәлү таныклыгы алды.

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:**

Үзәкләшкән дини оешма –
Татарстан Республикасы
мөселманнары Диния нәзарәте
420021 Казан, Габдулла Тукай урамы, 38 нче йорт

Бәясе ирекле
2013 нче елның июленнән чыга
Басма кварталга бер тапкыр чыга
12+

**БАШ РЕДАКТОР:**
Камил Искәндәр улы Сәмигуллин
Телефон: +7 (843) 237-94-53 (кабул итү бүлмәсе)

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Ришат Хәмидуллин
Нияз Сабиров
Илдус Фәиз

**ҖАВАПЛЫ СӘРКАТИП:**
Рәмзилә Шафикова
Телефон: +7 (843) 598-09-42

**ДИЗАЙНЕРЛАР:**
Рөстәм Даутов
Илшат Хәйретдинов

**БИТКӘ САЛУЧЫ:**
Раушан Сәйфетдияров

**ӘДӘБИ РЕДАКТОР:**
Рәмзилә Шафикова

**РЕДАКЦИЯ**

Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:
«Хозур» – «Тынычлык» нәшрият йорты» шәхси оешмасы
420111 Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27 нчы йорт
Тел./факс: +7 (843) 598-09-42
Электрон почта: shura@huzur.ru
Сайт: www. huzur.ru

Типографиянең адресы:
«Комбинат программных средств» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте типографиясендә бирелгән электрон-макетның тулы сыйфатына тәңгәлләштереп бастырылды.
420044, Казан ш., Ямашев проспекты, 36 Б
Тел./факс: +7 (843) 519-91-10
Сайт: http://kpkps.ru/

Тираж – 2000 данә
Басарга кул куелды: 22.09.2017
График буенча: 22.09.2017

*Редакциягә килгән язмалар кире кайтарылмый*

*Журналда тәрҗемә итеп бастырылган материалларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела*

*Журнал битләрендә Коръәни Кәримдәге аять-сүрәләр урын алганлыктан, басмага игътибарлы булуыгыз сорала*

**«СОВЕТ»**

Ежеквартальное печатное издание на татарском языке

## **Әссәламү галәйкүм вә рахмәтүллаһи вә бәрәкәтүһү!**

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте һәм шәхсән үз исемемнән барлык мөселманнарны да МәүлидӘн-Нәби белән тәбрик итәм! Пәйгамбәребез Мөхәммәднең S дөньяга килү вакыты булып рабигыль-әүвәл аеның унбереннән уникесенә каршы төн санала, һәм бу вакыйга григориан ел исәбе буенча 571 нче елда булган. Рабигыль-әүвәл – Ислам тарихында иң сөекле айларның берсе, чөнки бу ай бар Галәмгә рәхмәт буларак соңгы Пәйгамбәр килүе белән истәлекле.

Аллаһы Тәгалә Кәламе шәрифтә болай ди:

**«Ий Мөхәммәд S ! Кешеләргә Аллаһның юмартлыгы вә рәхмәте илә иңдерелгән Коръән белән сөйлә һәм аларны Коръән белән гамәл кылырга өндә! Коръән иңдерелгән өчен һәм аның белән гамәл кылганнары, Аның рәхмәтләре өчен шатлансыннар!»**

«Юныс», 10:58

Башка сүзләр белән әйткәндә, Аллаһы безгә иңдерелгән рәхмәт өчен шатланырга боера, ә Пәйгамбәребез Мөхәммәд S – иң бөек рәхмәт, чөнки Яратучы шулай ук болай дигән:

**«(Ий Мөхәммәд) Без сине бары тик рәхмәт билгесе итеп галәмдәге халыкларга күндердек».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:107

МәүлидӘн-Нәби ае безгә яңадан Аллаһы Илчесенең S тормыш юлын һәм мирасын, аның образын хәтеребездә яңартырга һәм искә төшерергә ярдәм итә. Пәйгамбәребезнең S йөзеннән яктылык, нур бөркелеп торган, бу хакта Гайшә g болай дип сөйләгән: «Пәйгамбәрнең йөз-кыяфәте айның ундүртенче кичендә балкыган айдан да яктырак, нурлырак иде. Мин хәтта әлеге яктылыкта җеп белән энә саплый алдым».

Пәйгамбәребез Мөхәммәднең S дөньяга килүе дөнья тарихының агышын тулаем үзгәртә, дөнья мәдәниятен, фәнне югары баскычка күтәрә, җир шарының геосәяси торышын көйли.

Мөхәммәд пәйгамбәр S тормышының кай ягын гына карасак та – ул һәр яктан үрнәк. Әти буларак, гаилә башлыгы буларак, рухи остаз, хәрби җитәкче, сәүдәгәр, иптәш – ул һәркайда безнең өчен идеал һәм соклану өчен зур мисал. Яшь буынга Пәйгамбәр өйрәтеп калдырган кыйммәтләрне яхшылап сеңдерергә, үзләштерергә кирәк.

Аллаһы Тәгалә барчабызны Үзенең рәхмәте белән бүләкләсә һәм Пәйгамбәребез Мөхәммәднең S мөбарәк Сөннәте белән яшәүләрне насыйп әйләсә иде! Әмин!

*Ихтирам һәм изге догалар белән*

*Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы*

*Мөселманнарының Диния нәзарәте рәисе,*

*Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин*

# Вәгазьләр

*13 октябрь вәгазе,*

*Мөхәррам аеның 23 нче көне, һиҗри исәп буенча 1439 ел*

# Кеше – Аллаһы Тәгаләнең могҗизасы

Барча галәмне юктан бар кылучы Раббыбыз Аллаһы Сөбханәһү вә Тәгаләгә хәмде-сәнә, мактауларыбыз, сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафага S күңелебезнең түреннән чыккан салават-шәрифләребез булса иде. Аның әһле бәйтенә сәламнәребез ирешсә иде. Раббыбыз Аллаһның әмерен үтәп, Аның Рәхмәтләренә ирешергә ният итеп, җомга намазына килгән мөэмин-мөселман кардәшләрем, әс-сәламү галәйкүм вә рахмәтүллаһи вә бәрәкәтүһ. Һәрберебезгә дә Аллаһ Сөбханәһү вә Тәгаләнең сәламе, ике дөнья рәхмәте һәм бәрәкәте булсын!

Адәм баласы элек-электән ниндидер могҗиза булуын көткән, пәйгамбәрләрдән дә могҗиза күрсәтүләрен сораганнар. Безнең әйләнә-тирәбездәге барча мәхлукат Аллаһы Тәгаләнең яратуы нәтиҗәсе буларак, һәрберсе бик күп могҗизалы нәрсәләрне үз эченә ала. Барчасы да Раббыбыз Аллаһның хикмәтен, кодрәтен, бөеклеген күрсәтә. Күз ярдәмендә күреп була торган нәрсәләрне аңлау җиңелрәк һәм Коръәни Кәрим дә безгә алар турында фикер йөртергә боера.

Аллаһы Тәгаләнең могҗизаларына бер тамчы орлыктан (сыекча-дан) барлыкка килгән кеше дә керә. Кеше җир йөзендәге мәхлуклар арасында иң зур могҗизаларның берсе булып санала. Адәм баласы өчен үз җаныннан да кадерлерәк нәрсә юктыр. Аның үзендә, үзе дә игътибар итмәгән бик күп искиткеч нәрсәләр бар. Үзенең тәненең төзелеше, һәрбер әгъзасының вазифасы турында уйласа, иманым камил, исе китеп, шаккатар иде. Нәтиҗәдә, каяндыр могҗиза күрсәткәннәрен көтеп йөрмәс иде. Ни өчен соң кеше үзенең җаны, тәне, тышкы һәм эчке әгъзаларының

төзелеше чиксез зур могҗиза икәнлеген танымаган һәм, акылын эшкә җигеп, шуны өйрәнү урынына, башкаларны аңларга омтыла соң?

Аллаһы Тәгалә Үзенең Изге китабында кешегә үзе турында фикерләргә кушып әйтә:

وَفِي الْأَرْضِ آيَاتٌ لِّلْمُوقِنِينَ ﴿٢٠﴾ وَفِي أَنفُسِكُمْ ۚ أَفَلَا تُبْصِرُونَ ﴿٢١﴾

**«Җирдә дә ышанучы акыллы кешеләр өчен галәмәтләр бардыр. Дәхи үзегезнең төзелешегездә дә галәмәтләр бардыр, әллә шуларны күрмисезме?»**

«Зарият / Таратучы», 51:20-21

Аллаһы Тәгаләгә ихластан (телдән, башкалар да күрсен өчен генә түгел) иман китергән кешегә янәшәбездә, әйләнә-тирәбездә Аллаһы Тәгаләнең барлыгына һәм бердәнбер булуына көчле дәлилләр бихисап.

Кайберәүләр Аллаһы Тәгаләнең барлыгын телдән әйтсәләр дә, ихластан ышанулары шикле. Үзебезнең барлыкка килүебез турында уйлап-фикерләп карыйк әле. Аллаһ Сөбханә вә Тәгалә йөкләгән бурычларны таный белсәк, иманыбыз нык булыр иде.

«Фүссиләт» сүрәсенең 53 нче аятендә болай дип әйтелә:

سَنُرِيهِمْ آيَاتِنَا فِي الْآفَاقِ وَفِي أَنفُسِهِمْ حَتَّىٰ يَتَبَيَّنَ لَهُمْ أَنَّهُ الْحَقُّ ۗ أَوَلَمْ يَكْفِ بِرَبِّكَ أَنَّهُ عَلَىٰ كُلِّ شَيْءٍ شَهِيدٌ ﴿٥٣﴾

**«Бөтен галәм төзелешенең хәлләреннән Безнең кодрәтебезгә вә берлегебезгә дәлаләт иткән ачык вә көчле галәмәтләребезне кешеләргә күрсәтербез. Аллаһы Тәгаләнең хаклыгы һәм бер генә икәнлеге, вә Коръән Аллаһ китабы, вә Мөхәммәд Аллаһның расүле икәнлеге ачыкланганчы, кешеләрнең барлыкка килүе Аллаһ эше икәнлеген үзләренең төзелешеннән**

**күрсәтербез. Яки һәрнәрсәгә шаһит булырга синең Раббың җитмиме?»**

«Фүссиләт / Аңлатылды», 41:53

Аллаһы Тәгалә «Рум» сүрәсендә болай дип әйтә:

وَمِنْ آيَاتِهِ أَنْ خَلَقَكُم مِّن تُرَابٍ ثُمَّ إِذَا أَنتُم بَشَرٌ تَنتَشِرُونَ ﴿٢٠﴾

**«Дәхи Аллаһның кодрәтенә дәлаләт иткән нәрсәләрнең берсе – асылыгыз Адәмне туфрактан халык итте, соңрак сез кеше булып җир йөзенә таралдыгыз.»**

«Рум», 30:20

Аллаһы Тәгалә: **«Әй бәндәләрем, Мин сезне шушы балчыктан яраттым һәм үлгәннән соң кире балчыкка кертәмен яңадан, Кыямәт көне җиткәч, шул балчыктан кубарып (терелтеп) чыгарабыз»,** – дип әйтә.

Күп еллар буе кешенең барлыкка килүенә каршы килгән фән дә, бүгенге көн ачышларыннан соң, иман китереп, Коръән сүзләренең хак икәнен әйтә. Бүгенге көндә кешенең тәнендә булган химик матдәләрнең балчыкта да булуы фәнни тәҗрибәләр ярдәмендә исбат ителде.

«Мөэминнәр» сүрәсенең 12,13,14 аятьләрендә болай дип әйтелә:

وَلَقَدْ خَلَقْنَا الْإِنسَانَ مِن سُلَالَةٍ مِّن طِينٍ ﴿١٢﴾ ثُمَّ جَعَلْنَاهُ نُطْفَةً فِي قَرَارٍ مَّكِينٍ ﴿١٣﴾ ثُمَّ خَلَقْنَا النُّطْفَةَ عَلَقَةً فَخَلَقْنَا الْعَلَقَةَ مُضْغَةً فَخَلَقْنَا الْمُضْغَةَ عِظَامًا فَكَسَوْنَا الْعِظَامَ لَحْمًا ثُمَّ أَنشَأْنَاهُ خَلْقًا آخَرَ ۚ فَتَبَارَكَ اللَّهُ أَحْسَنُ الْخَالِقِينَ ﴿١٤﴾

**«Тәхкыйк, Без Адәмне саф балчыктан яраттык. Соңыннан Адәмнең нәселен карарланган бер урында мәни кылдык,**

**ул - аналыктыр. Соңыннан мәнине каты кан итеп яраттык, соңыннан ул каты канны чәйнәлгән ит кебек кылдык, соңыннан ул сөякләргә итләр кидердек. Соңыннан аны икенче төрле халык иттек, ягъни аңа җан бирдек. Аллаһы Тәгалә кодрәтендә вә хикмәтендә дәрәҗәсе бөек булды, Ул тәкъдир итүчеләрнең иң күркәмедер».**

«Әл-Мөэминүн / Мөэминнәр», 23:12-14

Әбү Габдеррахман Габдуллаһ бин Мәсгүд d болай дип әйтте: «Гадел һәм ышанычлы Пәйгамбәр s : «Дөреслектә, һәрберегез ана карынында кырык көн орлык-тамчы булып, шул кадәр үк вакыт оешкан кан булып, аннары шуның кадәр үк ит кисәге булып оеша. Аннары аның янына фәрештә килеп җан өрә. Аңа (фәрештәгә) дүрт төрле нәрсәне язарга боерыла: баланың ризыгын, гомер озынлыгын, эшләрен, бәхетле яки бәхетсез булачагын», – дип әйтте»[1].

Хәдистән аңлашылганча, яралгы һәрберсе кырыгар көннән торган өч чор үтә икән. Беренче кырык көндә ул мәни тамчысы хәлендә була, икенчесендә – оешкан кан, өченчесендә ит кисәгенә әверелә. Шуннан соң фәрештә аңа җан өрә. Аллаһы Тәгалә «Мөэминнәр» сүрәсенең 12-14 аятьләрендә тагын өч башка чор турында сөйли. Ибне Габбас бик еш: «Кеше җиде нәрсәдән яратылган», – дип әйткән һәм «Мөэминнәр» сүрәсенең 12-14 аятьләрен укыган.

Әгәр дә Аллаһ теләгән булса, Ул безне бер мизгелдә барлыкка китерә алыр иде. Әмма Ул кешене шулай бер чордан икенче чорга күчереп яраткан. Бу Аның Галәмне барлыкка китерүенә охшаш. Бу рәвешле барлыкка китерү – Аллаһның кодрәтле хикмәтен күрсәтә. Шулай итеп Аллаһы Тәгалә колларын гамәлләрдә ашыкмаска һәм сак булырга өйрәтә.

Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

---

1 Имамнар Бохари һәм Мөслим хәдисләр җыентыгыннан. Хәдиснең бер өлеше.

أَوَلَا يَذْكُرُ الْإِنسَانُ أَنَّا خَلَقْنَاهُ مِن قَبْلُ وَلَمْ يَكُ شَيْئًا ﴿٦٧﴾

**«Әллә ул кеше Без аны моннан элек халык кылганны исендә тотмыймы әллә? Гәрчә ул элек ют та иде бит?»**

«Мәрьям», 19:67

Әгәр уйлап-фикерләп карасак, чыннан да, без бернәрсә дә түгел идек. Җир өстендә бездән, кешеләрдән, беркем дә юк иде, бүген исә без бар, ягъни тере, яшибез һәм ризыкланабыз. Без каян килеп чыккан? Кешене кем яраткан соң? Адәм баласын хәлиф буларак җир йөзенә кем китергән соң?

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

أَمْ خُلِقُوا مِنْ غَيْرِ شَيْءٍ أَمْ هُمُ الْخَالِقُونَ ﴿٣٥﴾

**«Әллә алар һичнәрсәсез халык ителделәрме, ягъни аларны халык кылган Аллаһ юкмы, әллә алар үзләре халык кылучылармы?»**

«Тур / Тур Тавы», 52:35

Дөреслектә, Аллаһы Тәгаләнең чиксез кодрәте генә юктан нәрсәнедер бар итә ала. Динсез, атеистик тәрбия чорларында күпләр Чарльз Дарвинның «маймылдан чыккан» кешесенә ышансалар да, баребер дин үз фикерендә нык калды. Бүгенге көндә кайбер бәндәләр маймыл сыйфатына кереп, маймыл булдылар, ягъни хайван дәрәҗәсенә төштеләр.

Кызганычка, фән тарафыннан дәлилләп, кешене Аллаһы Тәгалә барлыкка китергәне исбатланса да, һаман да, Чарльз Дарвинның ялган тәгълиматы белән бүгенге көндә дә мәктәпләрдә яшь балаларның башларын катыралар, дөресен сөйләмичә, үзләренә карата ышанычны бетерәләр. Дөреслекне балалардан, кешеләрдән яшерүчеләр Кыямәт

көнендә Аллаһы Тәгаләнең хозурына килгәндә, каберләреннән телсез шайтан булып кубарылачакларын онытмасыннар иде!

Кешенең барлыкка килүе турында ялган сөйләп, соңыннан тәүбәгә килүче турында әйтеп китәсем килә. Бер кардәшебез Балык бистәсе районы авылларының берсендә укытучы һәм директор вазифасын башкарып, байтак вакыт мәктәптә эшләгәннән соң, гаилә хәле буенча башка җиргә күчеп китәргә мәҗбүр була. Күчеп киткән җирлектәге мәктәптә эшләгән чорда намазга баса. Тәүбәгә килә. Әүвәл укыткан авылга барып, мәктәп балаларыннан, авыл халкыннан: «Мин сезне ялган Дарвин теориясе буенча, кеше маймылдан чыккан дип укыттым, мине Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы өчен гафу итегез!» – дип, тәүбә иткән.

Бер уйлап-фикерләп карыйк әле: бер тамчы мәнине кабаттан күз алдына китерик. Әгәр дә без ул сыекчаны ачык урында күпмедер вакытка калдырсак, ул бозылачак һәм сасы исләр чыгачак. Ә Аллаһ аны ирләрнең умыртка сөягеннән чыгарган. Ир белән хатынның күңелләренә мәхәббәт биреп, аларны кавыштырган, нәтиҗәдә, орлык ана карынына урнаштырыла, тугыз айдан соң бала туа. Ул ана карыныннан ошбу фани дөньяда яшәр өчен әзерләнеп чыга. Туганда ук инде аның бу дөньяда кирәк булачак аяк-куллары, башы, күзе, колагы, борыны һ.б. барча әгъзалары да урынына урнаштырылган.

Телебезгә игътибар итсәк кенә дә – тел өстендә 6 меңләп тәм тату бизләре урнаштырылган. Сүзләрне әйтер өчен, ризыкны чәйнәр өчен, һәрбер хәрефне дөрес итеп әйтү өчен телебез аерым хәрәкәтләр башкара, ләкин без моңа игътибар да итмибез.

Без ризыкны да, һаваны да бугазыбыз аша үткәрәбез, әмма һава ашказанына китми, ризык та үпкәләргә керми. Могҗиза буларак, бугазыбызга кимерчәк урнашкан, әгәр дә ризык килсә, ул шунда ук үпкә юлын яба һәм ашказанына юл ача.

Борынның да төзелеше искиткеч: аның аша һава сулыйбыз, ә һавадагы тузан бөртекләрен борын эчендәге махсус сыекчалар тоткарлап кала. Салкын һаваны борын белән үпкә арасындагы киртәләр җылытып кертә. Борын аша кеше 10 меңләп исне сизә ала.

Кешенең акылы йөрәгендә урнаштырылган. 1,4 кг авырлыгы булган баш мие белән бәйләнгән тәнебездә, нинди генә хәрәкәт эшләнсә дә, иң алдан баш миенә хәбәр килә һәм соңыннан гына әгъзага әмер китә. Эш уйлап башкарыла торган булсынмы, без белмәгән һәм күрмәгән эчке әгъзаларның эше булсынмы, барыбер ул гамәл баш мие аша үткәрелә икән.

Кешенең баш мие тәннең 2% ын гына тәшкил итсә дә, баш миенә бер секундка 100 миллионга кадәр хәбәр килә. Бу кадәр хәбәрнең шул кадәр кыска вакытта кабул ителүен без үзебез аңлый да алмыйбыз. Шулай ук баш мие урнаштырылган баш сөягенә игътибар итсәк тә, ул сөякләр арасында өске һәм аскы теш казналары бар. Аларга урнашкан тешләрнең нечкә, үткеннәре тешләү, өзү өчен яраклаштырылса, ә киңнәре чәйнәү өчен җайлаштырылган. Аллаһ муенны баш белән умыртка сөяген тоташтыручы итеп яраткан. Умыртка баганасы койрык сөягенә кадәр сузыла һәм егерме дүрт умыртка сөягеннән тора. Ул умыртка сөяген күкрәк сөяге, кабыргалар белән, җилкә, кул, оча сөяге, бот сөяге, тез, балтырлар белән тоташтырылган.

Әгәр дә Аллаһ Сөбханә вә Тәгалә бер генә әгъзабызны булса да артык яки ким итеп яратса, бу очракта безгә зарар килер иде.

Раббыбыз Аллаһ барчаларыбызга да тәүфыйк вә һидаять бирсә иде.

*Равил хәзрәт Нуруллин,*

*Яр Чаллы шәһәре «Туфан» мәчете имам-хатыйбы,*

*Аксакаллар шурасы рәисе*

*20 октябрь вәгазе,*

*Мөхәррам аеның 30 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1439 ел*

# Исламда Гайсә пәйгамбәр

Галәмнәрне юктан бар итүче, безгә һәрдаим төрле нигъмәтләрен җибәреп торучы Аллаһы Раббыбызга дан һәм мактауларыбыз булсын. Шушы дөньяга соңгы расүл итеп җибәрелгән Мөхәммәдкә s күңелләребезнең түрләреннән чыккан салават вә шәрифләребез булса иде.

Коръәни Кәримдә Аллаһы Тәгалә бик күп төрле вакыйгалар, гаҗәеп олы күңелле бәндәләр хакында бәян итә. Бу вакыйгаларда Аллаһы Раббыбыз безнең тормышыбызны яктырта.

Мөгаен, Аллаһы Тәгалә китабында, ягъни нурлы Коръәндә, иң могҗизалы, дәрәҗәле пәйгамбәрләре арасында Мәрьям улы Гайсәне a аерып чыгарырга буладыр. Бу пәйгамбәр үзенең һәм әнисенең тәкъвалыгы белән хәтердә калып, күбебез өчен әхлакый, тормышта үрнәк алырдай Аллаһның яраткан колларыннан берсе. Әлбәттә, кайбер диннәрдә Гайсә a төрле дәрәҗәдә бирелә, насара, ягъни христиан динендә ул Исус Христос дип бәян ителә. Ә безнең динебездә, шәригатебездә Гайсә хакында Аллаһы Тәгалә нинди мәгълүмат иңдергән соң? Һәм Ул нинди халыкка пәйгамбәр итеп җибәрелгән?

Белгәнебезчә, Мәрьям Аллаһы Тәгалә каршында шул кадәр тәкъва була ки, хәтта Аллаһы Тәгалә Аңа үз нигъмәтләреннән күп өлеш чыгара иде: җәен кыш көнендә генә була торган, ә кышын җәй вакытында гына була торган ризыклар белән сыйлый.

Аллаһы Тәгалә аны Үзе тәрбия кылуы хакында да әйтә һәм шушы вакыйганы Үзенең бөек Китабында түбәндәгечә бәян кыла:

فَتَقَبَّلَهَا رَبُّهَا بِقَبُولٍ حَسَنٍ وَأَنبَتَهَا نَبَاتًا حَسَنًا وَكَفَّلَهَا زَكَرِيَّا ۖ كُلَّمَا دَخَلَ
عَلَيْهَا زَكَرِيَّا الْمِحْرَابَ وَجَدَ عِندَهَا رِزْقًا ۖ قَالَ يَا مَرْيَمُ أَنَّىٰ لَكِ هَٰذَا ۖ قَالَتْ
هُوَ مِنْ عِندِ اللَّهِ ۖ إِنَّ اللَّهَ يَرْزُقُ مَن يَشَاءُ بِغَيْرِ حِسَابٍ ﴿٣٧﴾

**«Мәрьямне Раббысы мәсҗид Әкъсага күркәм кабул итү белән кабул итте һәм яхшы тәрбия белән тәрбияләде, һәм тәрбияләп үстермәк өчен Зәкәриягә тапшырды. Зәкәрия Мәрьям янына кайчан гына керсә дә, алдында төрле җимешләр һәм башка ризыкларны күрер иде. Бер кергәнендә: «Ий Мәрьям, бу ризыклар сиңа кайдан килә?» – дип сорады. Мәрьям әйтте: «Бу ризыклар Аллаһ хозурыннан килә, Аллаһ, әлбәттә, Үзе теләгән бәндәсен хисапсыз ризыкландыра».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:37

Инде Мәрьямгә көннәрдән бер көнне Аллаһы Тәгалә Җәбраил фәрештәне җибәреп, җиңенә өрдерә һәм шул өргән рух Мәрьям карынына кереп, бала булып, ахырда дөньяга могҗизаларга иң бай пәйгамбәр Гайсә a килә.

Гайсә a Ягъкуб балаларына, ягъни Бәни Исраил кавеменә пәйгамбәр итеп җибәрелә. Аллаһы Тәгалә Гайсәгә a кече яшендә үк могҗизалар бирә. Кечкенә вакытында, урамда уйнап йөргән балаларга килеп, һәрберсенең өйләрендә нинди ризык бар икәнен әйтә торган була. Аллаһы Раббыбыз аны пәйгамбәр итеп сайлагач, Инҗил китабын иңдерә.

Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

وَقَفَّيْنَا عَلَىٰ آثَارِهِم بِعِيسَى ابْنِ مَرْيَمَ مُصَدِّقًا لِّمَا بَيْنَ يَدَيْهِ مِنَ التَّوْرَاةِ ۖ
وَآتَيْنَاهُ الْإِنجِيلَ فِيهِ هُدًى وَنُورٌ وَمُصَدِّقًا لِّمَا بَيْنَ يَدَيْهِ مِنَ التَّوْرَاةِ وَهُدًى
وَمَوْعِظَةً لِّلْمُتَّقِينَ ﴿٤٦﴾

**«Мәрьям улы Гайсәне әүвәлге пәйгамбәрләр әсәренә иярттек, үзеннән элек иңгән Тәүрат китабын тәсдыйк иткән хәлдә аңа Инҗилне бирдек, ул Инҗилдә һидаять билгеләре вә белем яктылыгы бар, һәм ул Инҗил Тәүрат хөкемнәренә муафикъ, шулай ук ул һидаять һәм тәкъва кешеләргә вәгазь».**

«Мәидә / Аш Яулыгы», 5:46

Инҗилдән кала, Аллаһ аңа үле кешеләрне терелтү һәм махау (проказа) авыруын дәвалау могҗизасын бирә. Гайсә a бик ярлы яшәсә дә, үзенең гыйбадәтен ташламый, тормышына ризасызлык белдерми. Һәрдаим Раббысына гыйбадәт кыла һәм хәмед-сәнәләр әйтеп тора. Шушы Гайсә a тормышына карап, үзебезгә тәкъвалык сорарга һәм нинди генә хәлдә булсак та, һәрдаим Аллаһы Тәгаләгә шөкер итеп яшәүне калдыр-маска тиеш.

Әлбәттә, Гайсәнең a хакыйкатьне таратуы, вәгазьләве кайбер кешеләргә ошамый торган була. Алар Рим императорына куркыныч бер кеше бар дип, ялган ифтира итеп, бохтан хәбәр җиткерәләр. Бу Рим императорына ошамый, ул Гайсәне a табып үтерергә куша. Әмма Аллаһы Тәгалә Җәбраил фәрештә аркылы Гайсәне коткара, күккә иңдерә, ә үтерергә килүчеләр, Гайсә дип, башка кешене үтерәләр. Тик Гайсә a янә әнисе белән саубуллашыр өчен җиргә төшерелә. Кайбер чыганакларга караганда, ул әнисенә тәкъва булуны, гөнаһларга тәүбә сорауны васыять итә.

Гайсә бу җиргә әле киләчәк. Кыямәт алдыннан Мәсихү-Дәҗҗал белән көрәшергә төшәчәк һәм Дәҗҗални җиңеп, гади мөселман булып яшиячәк һәм үләчәк. Бу хакта пәйгамбәребез Мөхәммәд s хәдисләрендә риваять ителә.

Әлбәттә, бу олы пәйгамбәр хакында бер җомга вәгазендә генә сөйләп бетерергә мөмкин түгел, моның өчен бик күп дәресләр үткәрү зарурдыр. Әмма шушы вәгазь – төп, дөрес мәгълүматны җиткерү генә, чөнки күп ва-

кытта кешеләр Гайсәне ә фәкать христианнарның пәйгамбәре дип кенә уйлыйлар. Бу алай түгел, без Гайсәне ә пәйгамбәр буларак кабул итәбез, яратабыз. Аллаһы Тәгалә барчабызны иманлы итеп, ахирәттә җәннәттә шушындый олы пәйгамбәрләр янәшәсендә булырга насыйп кылса иде. Әмин!

*Алмаз Галимҗанов,*
*Саба районы имам-мөхтәсибенең*
*яшьләр эше буенча урынбасары*

*27 октябрь вәгазе,*

*Сафәр аеның 7 нче көне, һиҗри исәп буенча 1439 ел*

# Талак – иң актык чик

Әгүүзү билләһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир рахмәәнир-рахиим.

Бу фани дөньяны оештыручы, бөтен галәмне юктан бар итеп тәрбия кылучы Аллаһ Сөбханәһү вә Тәгаләгә иксез-чиксез мактауларыбыз, шөкраналарыбыз, рәхмәтләребез булса иде. Безгә бәхет юлын күрсәтеп калдылган сөекле остазыбыз Мөхәммәд Мостафага S, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә күңел түрләребездән чыккан сәламнәребез, салаватларыбыз һәм изге догаларыбыз булса иде. Мөхтәрәм дин кардәшләрем, әс-сәләмү галәйкүм вә рахмәтүллаһи вә бәрәкәтүһ!

Аллаһы Тәгалә бу дөньяда бөтен нәрсәне дә парлы итеп яраткан. Аның җирдәге бу кануны шулай ук кешеләргә дә кагыла. Аллаһы Тәгалә бу хакта Коръәннең «Рум» сүрәсенең 21 нче аятендә әйтә:

وَمِنْ آيَاتِهِ أَنْ خَلَقَ لَكُم مِّنْ أَنفُسِكُمْ أَزْوَاجًا لِّتَسْكُنُوا إِلَيْهَا وَجَعَلَ بَيْنَكُم مَّوَدَّةً وَرَحْمَةً ۚ إِنَّ فِي ذَٰلِكَ لَآيَاتٍ لِّقَوْمٍ يَتَفَكَّرُونَ ﴿٢١﴾

> **«Аның (Аллаһның кодрәтен күрсәтүче) билгеләреннән: Ул (Аллаһ) сезгә (күңелегез) алардан тынычлык табу өчен үзегез кебек үк парларны (хатын-кызларны) яратты, арагызда ярату һәм рәхимлелек булдырды. Чынлыкта, бу нәрсәләрдә фикерләүче кешеләр өчен билгеләр бар!»**

«Рум», 30:21

Бу аятьтә Аллаһы Тәгалә ир кешенең пары – хатын-кызны барлыкка китерүе турында хәбәр итә. Аллаһы Тәгалә ир кешегә парны җеннәр, хай-

ваннар арасыннан сайламады, ә үзе кебек үк булган, аңа охшаган парны – хатын-кызны барлыкка китерде.

Әгәр кеше: «Аллаһы Тәгалә ни өчен хатын-кызны бу дөньяга барлыкка китерде икән?» – дип сораса, җавапны белү өчен аятьнең дәвамын укырга кирәк. Әлеге аятьтән күренгәнчә, Аллаһы Тәгалә хатын-кызны ир кешенең күңеле тынычлык тапсын өчен яратты. Бу дөньяда ир-атның күңеле акчадан да, яхшы эштән дә, спорт белән шөгыльләнүдән дә тулысынча тынычлык таба алмый, бары тик хәләл юл белән гаилә корып, хатын-кыз аркылы гына таба ала. Кеше яшәүнең мәгънәсен дә бары тик никахлы гаилә корып һәм балалар үстереп кенә аңлый ала. Шуңа күрә Аллаһы Тәгалә бу дөньяга хатын-кызларны Үзенең рәхмәте белән ирләр өчен яраткан.

Бу дөньяда бөтен гаилә дә бәхетле булу өчен корыла, ләкин аларның бөтенесе дә бәхетле булып чыкмый. Ир белән хатын гаилә корып, берникадәр вакыт бергә яшәгәннән соң аерылалар. Бүгенге көндә хәтта намаз укучы, ураза тотучы мөселманнар арасында да мондый хәл күзәтелә. Ни өчен гаиләләр таркала? Моның төбендә нинди сәбәпләр ята?

Гаиләләр таркалуның төп сәбәбе: ир белән хатынның Коръән һәм пәйгамбәребез Мөхәммәд S сөннәте белән гамәл кылмавына әйләнеп кайта. Ир белән хатын үз вазифаларын Аллаһ кушканча һәм Пәйгамбәребез S өйрәтеп калдырганча үтәмиләр. Кайбер вакытта ир дә, хатын да мәдрәсә яки башка дини уку йорты тәмамлаган, ләкин аларның гаиләләре ни өчендер таркала? Моның төп сәбәбе гаиләдәге бәхәсне Аллаһы Тәгалә һәм Пәйгамбәребез күрсәткәнчә түгел, ә динсез әти-әниләренең бер-берсенә карата тупас мөгамәләләрен һәм ызгыш-талашларын күреп, аларча хәл итүгә бәйләнгән. Яңа гына гаилә корып җибәргән яшьләр динсез әти-әниләренең бер-берсенә карата мөгамәләсен, араларында туган бәхәсләрне ничек чишкәннәрен күреп үсә һәм шуны үз гаилә тормышларында да куллана. Кечкенәдән күреп үскән һәм күңелгә сеңгән дин-

сез тәрбия биш-алты ел мәдрәсәдә укып кына яхшы якка үзгәрми. Бу яшьләрнең мәдрәсәдә өйрәнгән белемнәре зиһеннәрендә бер мәгълүмат буларак кына саклана, ә тормышта кулланылмый. Гаиләдә туган бәхәсләрне хәл иткәндә өстенлекне хискә түгел, ә Аллаһның дини күрсәтмәләренә бирергә кирәк. Шуңа күрә ир белән хатын бәхетле яшиселәре килсә, иң беренче чиратта, Коръәнгә һәм Мөхәммәд пәйгамбәрнең S сөннәтенә кайтырга тиеш.

Өйләнешкән вакытта һәрбер ир яхшы һәм итагатьле, үзенә ошый торган бер хатын алуны, шулай ук, һәрбер хатын-кыз үзе барачак ир-егетнең мәрхәмәтле, мөлаем, үзләрен яхшы тәрбия кылырлык, җил-яңгыр тидермәслек булуын телиләр. Моның өчен бөтен көчләре белән тырышалар һәм һәртөрле чаралар күрәләр. Әмма шулкадәр тырышулар белән дә, кайвакыт эшләр теләгән рәвештә булмаска мөмкин. Башларына шундый бәла килгән ир белән хатын нишләсеннәр? Бу авыр вәзгыятьтән чыгу юлы бармы? Бар, иң яхшы юл – ир белән хатынның сабыр кылулары. Аралары никадәр нык бозылса да, сабыр итәргә, аерылышуда булган зарар һәм файдаларны яхшылап үлчәргә тиешләр. Бәлки шушы сабыр итү һәм үлчәү сәбәбеннән, ир белән хатын үзләренең ялгыш юлга кергәнлекләрен аңлап, үз фикерләреннән кайтырлар һәм мәслихәт юлын тотарлар.

Табигатьләре бер-берсенә мәгълүм булмаган кешеләр күп вакытта беренче аралашуларында үзара килешә алмаслар да, әмма соңыннан араларында өлфәт һәм дуслык хасил була. Иң әүвәлге суыклык һәм илтифатсызлык сәбәпле ир белән хатынның аерылышуы дөрес эш түгел. Чөнки моннан соң алачак хатын яки торачак ир белән дә шундый ук хәл булырга мөмкин. Әгәр шул әүвәлге вакыйгада бераз сабыр итү сәбәпле эш төзәлеп китсә, икенче мәртәбә мәшәкатькә очраудан иминлек булыр. Әүвәлге елларында бик начар торып та, соңыннан аралары төзәлеп киткән ир белән хатын дөньяда аз түгел.

Әгәр ир белән хатын сабыр итә алмасалар, яки сабыр итүдән файда күрелмәсә, ул вакытта эшне казый хөкеменә тапшырырга кирәк. Казый ир белән хатын арасындагы мәхәббәтсезлекнең сәбәпләрен нечкәләп тикшерер һәм, сәбәпләрен тапканнан соң, кулыннан килгән кадәр чаралар белән араларын төзәтергә тырышыр. Ихтимал ки, гаепле тараф бу вакытта үзенең гаебен аңлар да, хатасыннан кайтыр һәм тәүбә кылыр.

Шул вакытта, ихтимал, һәр ике тарафка: «Әгәр аерылсак, кечкенә балалар ятим кала, аларны кемнәр карар, кемнәр кулына калырлар, моннан соң нинди рәвештә мәгыйшәт насыйп булыр, кемнәр белән дөнья көтәргә туры килер? Хәерле тереклек насыйп булырмы яки бу көннәрдән яманрак хәлләргә очрарбызмы?» – дигән уйлар төшә дә, башларны кызгану һәм гаилә хөрмәтен саклау сәбәпле, әүвәлге дошманлыкларны гафу итешерләр һәм чын күңелләреннән килешерләр, элек кылган җәбер, җәфалары өчен үкенешерләр һәм бер-берсенә тугрылыклы гаилә булып китәрләр. Мондый хәлләрнең дә булганлыгы ишетелеп тора.

Динебездә хатын алу һәм аеру дөрес булса да, һичбер сәбәпсез хатын аеруны Аллаһы Тәгалә сөйми. Өйләнү дә, аеру да дөрес, әмма бердән артык хатын алуның, алганын аеруның дөрес булуы – бу ни дигән сүз соң? Бу нәрсәләр ни өчен рөхсәт ителгән, хикмәте нәрсәдә, шуны аңлыйбызмы икән?

Талак нәфескә генә ияреп хәл кылына торган нәрсә түгел, бәлки ул вәзгыятьне төзәтү, әдәп-инсафны алга җибәрү өчен бирелгән бер коралдыр. «Иң соңгы дару – тимер кыздырып басу» дигән әйтемдәге кебек, талак та иң актык чиктә генә торган бер юлдыр. Әгәр талак мәсьәләсендә бары тик үз кәефебезне генә саклап эш кылсак, Аллаһы Тәгалә каршында иң ачулы булган хәләлне сайлаган булырбыз.

Гаилә бәхетле булсын өчен, ир белән хатын үзләренең гаиләдәге вазифаларын һәм хакларын яхшы белергә тиеш. Һәр дәүләтнең, оешманың җитәкчесе булган кебек, гаиләнең дә җитәкчесе бар. Аллаһы Тәгалә ул җитәкчелекне ир кеше өстенә йөкләгән:

الرِّجَالُ قَوَّامُونَ عَلَى النِّسَاءِ بِمَا فَضَّلَ اللَّهُ بَعْضَهُمْ عَلَىٰ بَعْضٍ وَبِمَا أَنفَقُوا مِنْ أَمْوَالِهِمْ ﴿٣٤﴾

**«Ирләр хатыннар өстеннән җитәкчелек итәләр. Чөнки Аллаһы Тәгалә ирләрне хатыннардан акыл, көч-куәт, гыйлем ягыннан өстен кылды һәм алар үз байлыкларыннан хатыннарына сарыф итәләр».**

«Нисә / Хатыннар», 4:34

Аллаһы Тәгаләнең ир кешене гаилә башлыгы һәм хатыннар өстеннән идарә итүче итеп билгеләве юкка гына түгел. Монда бик зур хикмәт яшеренеп ята. Беренчедән, ир кешенең физик яктан, акыл ягыннан һәм авыр вазифаларны башкарып чыгу ягыннан хатын-кызга караганда өстенрәк булуы. Икенчедән, ир кешенең акча эшләү мөмкинлеге хатын-кызга караганда күбрәк. Шуңа күрә дә гаиләне матди яктан тәэмин итүне Аллаһы Тәгалә ир-ат өстенә йөкләде.

Гаиләне алып бару – җиңел эш түгел, ул Аллаһның сакларга биргән әманәте. Бу әманәт турында Аллаһы Тәгалә ир кешедән Кыямәт көнендә дә сораячак. Ир кешенең хатыны өстеннән җитәкче булуы аннан көләргә, мыскыл итәргә һәм аны җәберләп яшәргә рөхсәт бирми. Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَعَاشِرُوهُنَّ بِالْمَعْرُوفِ ۚ فَإِن كَرِهْتُمُوهُنَّ فَعَسَىٰ أَن تَكْرَهُوا شَيْئًا وَيَجْعَلَ اللَّهُ فِيهِ خَيْرًا كَثِيرًا ﴿١٩﴾

**«Алар белән (шәригатьтә һәм гореф-гадәттә) күрсәтелгән рәвештә (яхшы мөнәсәбәттә булып, хакларын үтәп) мөгамәлә кылыгыз. Әгәр дә сез аларны яратып бетермәсәгез (хатыннарыгызга карата сабыр итегез), бәлки сез нәрсәне дә булса яратып бетер-**

**мисездер, ә Аллаһ анда (ягъни хатыннарыгызга сабыр итеп яшәүдә) сезнең өчен бик күп хәерле нәрсә булдыра».**

«Нисә / Хатыннар», 4:19

Бу аятьтә Аллаһы Тәгалә хатыннарының кайбер гадәтләрен һәм холыкларын яратып бетермәгән ирләргә хатыннары белән аерылмыйча сабыр итеп яшәргә киңәш бирә. Чөнки, әгәр дә ир кеше хатынының тискәре холкына һәм сыйфатларына сабыр итеп яшәсә, Аллаһы Тәгалә аларның арасын яхшыртырга мөмкин.

Галидән d хәбәр ителә: Мөхәммәд пәйгамбәр s шулай ди: «Сезнең иң хәерлеләрегез – хатыннарына карата яхшы мөнәсәбәттә булганы, ә сезнең арагызда хатынына карата иң хәерле мөнәсәбәттә булучы кеше – ул мин».

Пәйгамбәребезнең s гаиләсенә карата мөнәсәбәтен карасак, ул үз хатыннарына карата һәрвакытта да йомшак мөгамәләдә булды, алар белән шаяра, күңелләрен күтәрә, матди яктан кирәгенчә тәэмин итә, һәр көнне төн уздыра торган хатыны өендә бөтен хатыннары белән бергә җыелып кичке ашны ашый, ястү намазын укыгач, йокларга ятар алдыннан гаиләсе белән бераз сөйләшеп утыра иде.

Коръәндә безгә Аллаһы Тәгалә шулай ук хатыннарның ирләренә карата нинди мөнәсәбәттә булырга тиешлеген дә аңлата. Аллаһы Тәгалә әйтә:

فَالصَّالِحَاتُ قَانِتَاتٌ حَافِظَاتٌ لِّلْغَيْبِ بِمَا حَفِظَ اللَّهُ ﴿٣٤﴾

**«Яхшы хатыннар – алар Аллаһка һәм ирләренә буйсына, Аллаһы Тәгалә сакларга кушкан яшерен нәрсәне (үзләрен зина кылудан, иренең байлыгын) саклыйлар».**

«Нисә / Хатыннар», 4:34

Бу аятьтә Раббыбыз хәерле, яхшы хатын-кызларга билгеләмә бирә. Хәерле хатын булу өчен Аллаһы Тәгаләгә буйсынырга, ягъни биш вакыт

намаз укырга, Ураза тотарга, хәрам ризыклырдан тыелып хәләл ризыклар гына ашарга һәм ирне санлап, аңа итагатьле булып, тыйнаклык күрсәтеп яшәргә, үзен иренә хыянәт итүдән, ягъни башка ирләр белән чуалып зина кылудан сакларга һәм ирнең акчасын, байлыгын әрәм итмичә тота белергә тиеш.

Кайбер очракларда гаиләләр хатын-кыз ирен санлап яшәмәгәнлектән таркала. Ир кеше хатыны санламаганга, ихтирам итмәгәнгә күрә кимсенеп яши, ә ахыр чиктә аерылырга мәҗбүр була. Шуңа күрә Мөхәммәд S бер хәдисендә хатын-кызның җәннәткә керүен ирне санлап, хөрмәт итеп һәм аңа буйсынып яшәүгә бәйләп куйган: «Әгәр дә хатын-кыз биш вакыт намазын укыса, Рамазан аенда ураза тотса, җенес әгъзасын зинадан сакласа һәм иренә буйсынса, аңа җәннәткә үзең теләгән ишектән кер, дип әйтәләр».

Шәригатебез талак эшен сабыр һәм чыдам табигатьле ирләргә тапшырган. Моның максаты – кечкенә сәбәпләр, вак ялгышлыклар белән гаилә эшләре бозылып китмәсен, һәрвакыт булып үтә торган үпкә, ачулар сәбәпле гаилә эшләренә берәр төрле хәл килмәсен өчендер. Ләкин безнең ирләрдә Ислам шәригате тарафыннан ышанып тапшырылган бу нәрсәне явыз ният белән куллану бик киң таралган. Талак Аллаһы Тәгалә сөймәгән бер нәрсә булса да, хатынны җәберләп тоту, мәхәббәте булмаган, аны үзенә иптәш санамаган, аның өстеннән йөрүдән оялмаган кешенең үз хатынын каһәрләп тотуы бигрәк тә сөелмәгән эштер. Аллаһ Сөбханәһү вә Тәгалә никахлашкан яшьләребезнең күңелләренә өлфәт-мәхәббәт салып, мәхәббәтләрен дәвамлы, гаиләләрен иманлы, бәрәкәтле һәм көчле кылып, алардан туган балаларны динебезгә, Ватаныбызга иманлы, мәрхәмәтле, игелекле балалар насыйп кылса иде.

*Руфат хәзрәт Мөслимов,*

*Питрәч районы Көек авылы имам-хатыйбы*

*3 ноябрь вәгазе,*

*Сафәр аеның 14 нче көне, һиҗри исәп буенча 1439 ел*

# Исламда канәгать булу

Әгүүзү билләһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим! Әлхәмдү лилләһи Раббил гәәләмиин, вәс-салəәтү вәс-сәләәмү гәләә расүлинәә Мүхәммәд вә гәләә әәлиһи вә сахбиһи әҗмәгыйн.

Галәмнәрнең хуҗасы, барча тереклекнең тәрбиячесе булган Раббыбыз Аллаһы Тәгаләгә барча мактау догаларыбыз булса иде.

Җир өстенә рәхмәт өчен җибәрелгән Мөхәммәдкә S чын күңелдән әйткән салават-сәламнәребез бертуктаусыз ирешеп торсалар иде.

Бүгенге вәгазебезне ризалык һәм канәгатьлелек төшенчәләренең мәгънәләрен караудан башлыйк. Бер караганда, бу сүзләр бик охшаш, ләкин асылда һәрберсе аерым бер мәгънәгә ия.

**Ризалык**

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

جَزَاؤُهُمْ عِندَ رَبِّهِمْ جَنَّاتُ عَدْنٍ تَجْرِي مِن تَحْتِهَا الْأَنْهَارُ خَالِدِينَ فِيهَا
أَبَدًا ۖ رَّضِيَ اللَّهُ عَنْهُمْ وَرَضُوا عَنْهُ ۚ ذَٰلِكَ لِمَنْ خَشِيَ رَبَّهُ ﴿٨﴾

**«Раббылары хозурында аларның җәзасы Гәден җәннәтләредер, ул җәннәтләрнең асларыннан елгалар агадыр, алар анда мәңге калырлар. Аллаһ алардан разый булды, һәм алар да Аллаһтан разый булдылар. Бу дәрәҗәләр Раббыларыннан курыккан хак мөэминнәргәдер».**

«Бәйинә / Аңлатма», 98:8

Бу дөньяга һәрбер кеше гыйбадәт кылыр өчен җибәрелгән. Гыйбадәт ул – намаз, ураза, зәкәт, хаҗ кебек гамәлләр генә түгел. Гыйбадәт – ихластан Аллаһ ризалыгы өчен ниятләнеп, Коръән һәм сөннәткә туры китереп эшләнгән төрле гамәлләр була ала. Мәсәлән, без ихластан намаз укырга ниятләдек, ләкин тәһарәтебез юк. Бу гыйбадәт булып саналамы? Юк, чөнки ният бар, ә шәригатькә туры килми. Яисә, без урамдагы чүпне алып ташладык. Бу гыйбадәт була аламы? Әлбәттә, бу гыйбадәт. Ләкин шул ук гамәл кеше күрсен өчен, кеше мактасын дип эшләнелсә, ул шунда ук гыйбадәт булудан туктый. Димәк, гамәл-гыйбадәткә әйләнсен өчен ул ихлас ниятән – Аллаһ ризалагы өчен һәм шәригать кысаларына туры килергә тиеш. Без тормышыбызда һәр көнебезне, һәр эшләгән эшләребезне Аллаһы Тәгалә ризалыгын алу өчен тырышып эшләргә тиешбез.

## Канәгатьлелек

«Канәгать булыгыз, чөнки ул юкка чыкмый торган байлык»[1].

Канәгать булу – бәхет. Ә нәрсә соң ул бәхет? Һәрбер кеше бәхетне үзенчә аңлый. Баерга теләгән кеше бәхетне байлыкта, дан-шөһрәткә омтылганы дәрәҗәгә ирешүдә күрә. Сөеклесен югалткан кеше сөйгән яры белән күрешүдә, баласыз гаилә – балалы булуда күрә һ.б.

Галимнәр һәрбер яңа әйбер иң күбе 90 көн дәвам итә дип әйтәләр. Мәсәлән, бер яңа кием алыгыз. Бер киясез – матур, ә берничә атнадан гадәти күлмәккә әйләнә. Еллар буе йорт салабыз. Йортка Коръән укып керәбез, яшибез, 90 көннән соң ул гадәти бер йортка әйләнә, яңалык рәхәте бетә. Аллаһы Тәгалә адәм балаларының дөньяда ләззәтләнү вакытын кыскарткан, ә Җәннәттә бу хис мәңге бара. Яңа кигән киемнең дә ләззәте мәңге барыр, чөнки Аллаһы Тәгалә җәннәттәге тормышны атна саен яңартып торыр. Бу дөньяда бераз гына татып карыйбыз да, соңыннан гади тормышка әверелә.

[1] Имам Табарани хәдисләр җыентыгыннан

Ни өчен шулай соң? Адәм балалары бу тормышның ләззәтенә алданмасын өчен, чөнки бу төп максатыбыз түгел. Әгәр Аллаһы Тәгалә белән элемтәбез булса, шушы бәхет була, канәгатьлелек хисе мәңге бара.

Стамбул шәһәрендә Азия белән Ауропаны тоташтыра торган Босфор күпере бар. Дөньяда мондый күпер икәү генә. Архитектор бу күперне бик озак салган, ләкин Босфор күперен ачкан көнендә, кызыл лентаны кискәч үк, архитектор аска ташлана. Ни өчен? Чөнки бәхете шул булган. Лентаны кискәч, җаны бушап кала, бүтән бернинди максаты юк, бернинди омтылышы юк, тормышта бүтән мәгънә күрми.

Әгәр дә адәм баласы Аллаһы Тәгалә белән булган элемтәне өзсә, бу дөньяда аны бернәрсә дә бәхетле итә алмый. Ул шушы рәхәтлеген малда күреп, матурлыкта күреп, сәламәтлектә генә күреп, бу дөньяда калганнар белән сугышып, дошманлашып, гайбәтләшеп, үзен әшәкелеккә генә илтә.

Галимнәр адәм баласына бу дөньяда Аллаһы Тәгалә белән тыгыз элемтә җитми дип әйтәләр. Телевизор, интернет челтәрендә нинди дә булса әшәкелекне күрдегезме, гайбәт тараттыгызмы, ялган сөйләдегезме – элемтә өзелә. Аны саклап тору өчен тырышлык кирәк.

Иң зур бәхет – җан белән Аллаһы Тәгалә арасындагы булган якынлыкны сизеп яшәү, иманның ләззәтен тоеп яшәү. Ничек моңа ирешергә соң?

Дин галимнәре иман ләззетен табып, саклап калуны түбәндәге гамәлләрдә күрәләр. Иң беренче адым булып фарыз гамәлләрне үтәү тора. Фарыз гамәлләрне үтәмичә, Аллаһы Тәгалә белән сезнең арагызда булган элемтә барлыкка килми. Ләкин Аллаһы Тәгаләнең мәхәббәте уянсын өчен фарыз гамәлләрдән соң нәфел гамәлләргә кучәргә кирәк. Нәфелне үтәмичә, Аллаһ белән якынаеп булмый.

Зикер кылу. Зикер кылып кына җаннар үзләренә урын таба. Аллаһ белән якынайтып, бәхетле итә торган тагын бер әйбер – ул Коръән уку. «Вакыт юк?»

Аллаһы Тәгалә Кыямәт көнендә болай дип әйтер: «Синең капкаңа минем бәхетем килгән иде. Мин бәхетне һәрбер кешенең өенә җибәрдем, ул һәрбер кешенең ишеген шакыды. Кеше исә ишеген ачты да: «Минем әле бу бәхеткә вакытым юк», – дип, ишеген ябып куйды».

Бәхет дин белән килә, ә безнең вакыт юк. Коръән укымаган кешенең Аллаһы Тәгалә белән булган арасы суына.

Намаз.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

إِنَّ الصَّلَاةَ تَنْهَىٰ عَنِ الْفَحْشَاءِ وَالْمُنكَرِ

**«Дөреслектә, намаз фәхеш, ярамаган эшләрдән укучыны тыя...»**

«Гәнкәбут / Үрмәкүч», 29:45

Әгәр дә син намаз укып та, гөнаһ кыласың икән, димәк намазың кимчелекле.

Изгелек кылу. Изгелек кылмыйча, үзеңә кадерле әйберне башкаларга бирмичә, алар белән бүлешмичә, Аллаһы Тәгаләгә якынаеп булмас.

Тәүбә итү. Тәүбә капкалары ябылганчы тәүбә итеп, хакыйкый юлга чыксак иде.

Һәрберебезгә Аллаһы Тәгалә рәхмәт капкаларын киңрәк ачса иде. Мөселман халкының күңелен Аллаһы Тәгалә белән якынайтсак иде. Шуны иң зур бәхет итеп сизсәк иде. Вакытлыча бирелгән ләззәткә алданып, олуг нигъмәттән коры калмасак иде.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

ارْجِعِي إِلَىٰ رَبِّكِ رَاضِيَةً مَّرْضِيَّةً ﴿٢٨﴾ فَادْخُلِي فِي عِبَادِي ﴿٢٩﴾
وَادْخُلِي جَنَّتِي ﴿٣٠﴾

**«Синең дөньяда өлешең бетте һәм бурычың үтәлде инде, Аллаһтан разый булган хәлдә һәм Аллаһ синнән разый булган**

**хәлдә Раббыңа кайт! Минем изге бәндәләрем арасына кер. Һәм Минем җәннәтемә мәңгегә кер!» – дип әйтелер».**

«Фәҗер / Таң», 89:28-30

Һәрберебезгә дә Кыямәт көнендә шушы сүзләр әйтелсен иде. Әмин!

*Хәсбиева Гөлназ,*

*«Яшь вәгазьче» бәйгесе җиңүчесе*

*10 ноябрь вәгазе,*

*Сафәр аеның 21 нче көне, һиҗри исәп буенча 1439 ел*

# Аллаһы Тәгаләнең нигъмәте – туры юл

Барча мактауларыбыз, хәмед-сәнәләребез Аллаһы Тәгаләгә булса иде, Аның хак хәбибе, пәйгамбәребез Мөхәммәдкә S, аның гаиләсенә, сәхабә-кирамнарына салаватларыбыз барып ирешсә иде.

Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтүллаһи вә бәрәкәтүһ. Аллаһы Тәгаләнең сәламе, бәрәкәтләре тормышыбызда дәвамлы булса иде. Ошбу вәгазебез дә шушы фани дөнья хакында, шушы дөньядагы Аллаһы Тәгаләнең безгә карата булган нигъмәтләре хакында булыр. Иң олуг нигъмәтләрнең берсе – дин. Аллаһы Тәгаләнең безгә бүләк итеп бирелгән шәригате. Әлхәмдүлилләһ, дини китапларыбыз, дини вәгазьләр, өйрәнүләр, укуларыбыз бар. Без, Аллаһка шөкер, бик яхшы тормышта яшибез: уку йортларыбыз күп, дин турында сөйли торган кешеләр күп, дини гыйлем таратучылар күп, интернет челтәре бар, китаплар, язмалар языла. Кайвакыт кеше аптырап кала ала: ә болар арасыннан кайсын укыйм, кайсысыннан кулланыйм? Әлбәттә, бу бик мөһим, җаваплылык сорый торган мәсьәлә.

Барыбызга да билгеле булган факт: Аллаһ каршында хак дин – ул Ислам дине. Динебез Ислам бары тик хәергә, нигъмәткә чакыра. Үзенә дөрес остаз сайламаганга күрә, дөрес китаплар сайламау сәбәпле, дөрес булмаган язмалар тыңлаганга, кайвакыт, мөселман кардәшләребезнең дөрес булмаган, тайгак юлга кереп китүен күрәбез, җәмәгать. Ягъни алданып, үзләрен дә, якыннарын да, дусларын-туганнарын да, хәтта ки балаларын да бәхетсез итәләр. Бу – дөрес булмаган юлны сайлау аркасында.

Аллаһка шөкер, мөбарәк Татарстаныбызда яшибез. 1500 артык мәчетебез бар. Ул мәчетләрнең һәрберсе теркәлгән, аларның үз имамнары бар. Һәрбер имамның шәһадәтнамәләре кулларында, ягъни алар укыган, гыйлем алган. Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмин, иң беренче, кем артыннан иярергә соң, дип сорасагыз, бу сезнең мәхәллә имамнарыгыз, ягъни һәрвакыт синең каршыңда булган зат. Гаиләсе белән, сүзе белән, гамәле белән җәмәгать каршында абруй казанган, шөһрәт казанган, сүзе үтә торган хәер инсан – имам булырга тиеш. Инде шушы кешене без үрнәк итеп, якын итеп алырга тиешлебез. Ә бүтән бер җирдәге кешегә иярүебез начар булып чыгуы бар. Ул – сүз өчен җавап бирми, гамәле өчен җавап бирми. Аллаһ сакласын, аларның ялгыш, тайгак юлларына кереп, үзебезне һәлакәткә алып баруыбыз бар. Аллаһ Үзе сакласын, Ахирәттә дә җавап бирәсе булырга мөмкин.

Аллаһы Тәгаләнең нигъмәте илә авырып китсәк, табиблар янына барабыз. Урамда очраган һәр кеше табиб түгел. Табиб янына барганда да без аның укыган икәнен, гыйлем алганын, шәһадәтнамәсе бар икәнен беләбез. Ул бу эшне эшли белә, шуңа күрә аңа ышанып тапшырылабыз. Нәкъ шуның кебек имамнарыбыз да, уку-йортларыбыз да безнең җирлегебездәге, традицион, гадәти булган, җәмгыятебезгә туры килгән, мең ел буе сыналган динебезне, шәригатебезне өйрәтәләр, мәзһәбебезне күрсәтәләр. Илләребездә, хәятләребездә тынычлык булсын дип, сәламәтлек булсын, дип тырышалар.

Бу бик зур мәсьәлә, җәмәгатүл-мүслимин. Адәм баласының тормышында, гыйлем туплаган вакытында ялгышмасын өчен, әүвәл бу традицион Исламыбыз, укуларыбыз, гадәти булган, традицион булган яшәеш рәвеше, башлангыч фикерләр гаиләләребездә бирелергә тиеш. Бабаларыбыздан, әти-әниләребездән үзебезнең балаларыбызга бирелергә тиеш. Аларны шул рәвешле үстереп, динне дөрес яктан күсәтеп: «Менә шушындый йолаларыбыз бар, гадәтләребез, Ислам дине шушындый дин ул», –

дип әйтсәк, – «Аллаһы Тәгалә мәрхәмәтле, Үзе дә мәрхәмәтлелеккә генә чакыра, сугышка чакырмый, илләмәгәр хәерлелеккә, күркәмлеккә генә өнди», – дип өйрәтсәк, тәрбияләсәк, балаларыбызның күңелләре, Аллаһ бирсә, буш булмас. Алар бу бушлыкны тутырыр өчен төрле юлларга, төрле юнәлешләргә кермәсләр, Аллаһ бирсә. Аларның нык булган, үзләре сайлаган юллары булыр.

Аллаһның хикмәте илә Адәм атабыз һәм Хава анабыз Аның әмеренә буйсынмадылар һәм җәннәттән куылдылар. Әмма алар истигъфар әйләп, Раббыбыздан гафу сорадылар. Аллаһы Тәбәракә вә Тәгалә аларны гафу итте. Әмма бөтен фәрештәләргә сәҗдә кылырга кушылган чакта, Иблис сәҗдә кылмады. Сәҗдә кылмады, олугланды, тәкәбберләнде, әмма тәүбә итмәде.

Аллаһы Тәгалә болай дип әйтте:

وَإِذْ قُلْنَا لِلْمَلَائِكَةِ اسْجُدُوا لِآدَمَ فَسَجَدُوا إِلَّا إِبْلِيسَ أَبَىٰ وَاسْتَكْبَرَ وَكَانَ مِنَ الْكَافِرِينَ ﴿٣٤﴾

**«Хөрмәт йөзеннән Адәмгә сәҗдә кылыгыз», – дип, фәрештәләргә әйткән вакытыбызда, алар сәҗдә кылдылар, мәгәр Иблис сәҗдә кылмады, тәкәбберләнде һәм кәферләрдән булды».**

«Бәкара / Сыер», 2:34

Иблиснең:

– Я Раббым, мине Кыяматкә кадәр калдыр, мин бәндәләреңне юлдан яздырырга тырышырмын», – дигән сүзләре соңгы сүзләренең берсе иде. Шуңа күрә дә тормышыбызда, динебездә, Аллаһ юлында булып, мәчетләргә баруыбызда, гыйбадәт кылган чакларыбызда, күп киртәләр хасил була. Бу киртәләр төрле-төрле хәлдә килә һәм һәрбер кешегә үзенчәлекле булып килә. Мусыйбәләр кемнеңдер малы кимеп, кемнеңдер сәламәтлегенә зыян килү рәвешендә була ала. Кемдер гөнаһка бата ала,

икенче кардәшләре хакында начар фикердә булуы – болар барысы да киртә булып торалар. Әлбәттә, һәрбер адәм баласы ялгышлыклар кыла ала, әмма: «Кешеләрнең иң хәерлесе – күп гафу үтенүче, тәүбә кылучы», – дип әйтте пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ.

Бер үлчәп карыйк әле: бу фани дөньядан Аллаһ хозурына китеп барсаң, бу байлыкларың нинди кыйммәткә ия булыр икән? Алар сине җәһәннәм утыннан саклап кала алырмы икән?

Аллаһы Тәгалә Үзенең изге Китабында болай дип әйтә:

يَوْمَ لَا يَنفَعُ مَالٌ وَلَا بَنُونَ ﴿٨٨﴾ إِلَّا مَنْ أَتَى اللَّهَ بِقَلْبٍ سَلِيمٍ ﴿٨٩﴾

**«Ул көндә малы вә баласы һичкемгә файда бирмәс. Мәгәр мөшриклек вә монафикълык керләреннән күңеле пакь хәлдә чын мөселман булып килсә, аңа файда булыр».**

«Шүгәраү / Шагыйрьләр», 26:88-89

Пакь күңел, сәламәт йөрәк – Аллаһы Тәгалә таләп иткән, кызыктырган йөрәк. Бу йөрәктә – Аллаһны тану, Аңа инану, ошбу фани дөньяны бетә торган итеп кабул итү. Шуңа да бу дөньяны күркәм рәвешле файдаланып, аны ахирәткә күпер итү, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтләренә ирешү кирәк.

Дөньяда яшәгәндә, адәм баласына бик күп киртәләр бар сыман. Әмма ныгытып уйлап карасаң, бу киртәләрнең күбесе бернинди кыйммәткә ия түгелләр. Алар адәм баласы тарафыннан зурайтып күрсәтелгән, шайтан Иблис тарафыннан зур итеп күрсәтелгән нәрсәләр, җәмәгать. Аллаһы Тәгалә дә Коръәндә моның турында кисәтә, кешегә яманлыклары матур итеп күрсәтелсә, үзен дөрес юлда дип санар, яхшы тормышта яшим дип уйлар, дип әйтелә анда. Аллаһы Тәбәракә вә Тәгалә Үз рәхмәте белән гыйлем алырга өйрәтте, гыйлем алырга кушты. Шуңа күрә дә Коръәннең беренче аяте үк «Укы» дип инде. Адәм баласының иң куркынычлары да, гыйлеме булмый торып, үзен гыйлемле дип санаган кешедер. Ул шуның

белән белемгә омтылмый, шуның белән хәлен-әхвәлен дөресләми, үзен хаклыкта-дөреслектә дип саный, җәмәгать.

Без тыныч илләрдә яшибез, табыннарыбыз мул, сый-хөрмәтләребез күп, Аллаһка шөкер, гаилә бәхете бар, өстебездә нинди төр генә киемнәр юк. Ошбу нигъмәтләргә шөкрана кылу безнең өстебездәге бурыч, чөнки Аллаһы Тәгалә шөкрана кылучыларга тагын да арттырырмын, дип әйткән.

Аллаһы Раббыбыз Үзенең Коръәни Кәрим китабында безләрне һәрвакыт уйланырга чакыра, гакылларыбызны эшләтергә чакыра, фикерләргә куша. Мондый аятьләр бик күп, җәмәгать. Аллаһы Тәгалә адәм баласын җиргә хуҗа итеп яратты, аңа акылны бирде. Аллаһы Тәгалә Коръәндә кешегә ике юл бирүен әйтә, һәм әгәр дә кеше үзенең акылы белән дөрес юлны сайласа, сәгадәткә ирешүен әйтә.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

الَّذِينَ يَذْكُرُونَ اللَّهَ قِيَامًا وَقُعُودًا وَعَلَىٰ جُنُوبِهِمْ وَيَتَفَكَّرُونَ فِي خَلْقِ
السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ رَبَّنَا مَا خَلَقْتَ هَٰذَا بَاطِلًا سُبْحَانَكَ فَقِنَا عَذَابَ النَّارِ
﴿١٩١﴾

**«Ул акыл ияләре намаз укырлар, намаздан башка вакытта да Аллаһны зикер итәрләр баскан, утырган вә яннарына яткан хәлдә, дәхи җир, күкләрнең төзелеше хакында акылларын эшләтеп, фикер йөртерләр: «Ий Раббыбыз, бу төзелешне Син максатсыз төземәдең. Мактау сиңа, Син барча кимчелектән пакь! Безне ут газабыннан сакла!»**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:191

Шуңа адәм баласының да тормышта максаты хак, дөрес булырга тиеш. Максаты бетми торган булырга тиешле. Әгәр максаты бу дөнья эчендә генә булса, ул аңа ирешер, әмма соңыннан ни булыр соң? Раббыбыз Аллаһ безгә олуг максат билгеләде. Безгә дә шул максатка ирешеп,

Адәм атабызның ватанына кайтырга –җәннәтле булырга насыйп булса иде.

Пәйгамбәребез S : «Дөнья – ул ахирәтнең чәчүлеге», – дип әйтте. Шуңа дөньядады иң беренче адымнарыбыз – Аллаһны тану. Ни өчен яшибез, нинди максат белән? Икенче адым – Аллаһны тану. Аның әмерләрен үтәргә тырышу. Тыйганнарыннан тыелу. Үзебездән соң күркәм эз калдыру – балаларыбызга карата мәрхәмәтле мөнәсәбәтебез. Гаиләбезгә карата күркәм мөгамәлә дә – Аллаһ кушкан әмердер.

«Гасыр» сүрәсендәге кебек:

إِلَّا الَّذِينَ آمَنُوا وَعَمِلُوا الصَّالِحَاتِ وَتَوَاصَوْا بِالْحَقِّ وَتَوَاصَوْا بِالصَّبْرِ ﴿٣﴾

**«Бер-берсенә хакны васыять итүчеләр, бер берсенә сабырлык васыять итүчеләр хәсрәттә булмаслар».**

«Гасыр», 103:3

Аллаһы Тәгалә адымнарыбызны нык кылып, Үзенең югары җәннәтләренә ирешергә насыйп әйләсә иде. Әмин!

*Равил Зөфәров,*

*Аксубай районы имам-мөхтәсибе*

*17 ноябрь вәгазе,*

*Сафәр аеның 28 нче көне, һиҗри исәп буенча 1439 ел*

# Бердәмлектә - бәрәкәт

Бөтен галәмне юктан бар итеп, тәрбия кылучы Аллаһы Тәбәракә вә Тәгаләгә чиксез рәхмәтләребез, шөкраналарыбыз булса иде. Аллаһы Раббыбыз тарафыннан галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафага S , аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә күңел түрләребездән чыккан сәламнәребез, салаватларыбыз һәм һәртөрле изге догаларыбыз булса иде.

Ерак һәм якын җирләрдән изге җомга көнне Раббыбыз Аллаһы Тәгаләнең әмерен үтәр өчен мәчетебезгә җыелган мөхтәрәм дин кардәшләрем, сезне динебезнең иң күркәм сәламе белән сәламлим: әссәләәмү галәйкүм вә рахмәтүллаһи вә бәрәкәтүһ!

Хөрмәтле мөселманнар! Барлык көннәрнең солтаны булган изге җомга бәйрәме барчаларыбызга да мөбарәк һәм хәерле булсын! Аллаһы Сөбханәһү вә Тәгалә ил-көннәребезгә, җаннарыбызга тынычлык, тәннәребезгә исәнлек-саулык, күңелләребезгә тәүфикъ-һидаять биреп, һәркайсыбызга хәерле һәм бәрәкәтле тормыш насыйп итсен. Мөкаддәс җомга көнне ихлас күңелдән изге гамәл-гыйбадәтләр кылып, Аллаһы Тәгаләнең иксез-чиксез рәхмәтләренә барчабызга да ирешергә насыйп булса иде!

Мөхтәрәм мөселманнар! Әлхәмдүлилләһ, илебездә дин тотучылар саны көннән-көн арткан-арта бара. Мәгълүматлардан күренгәнчә, бүген Россия Федерациясендә 20 миллионга якын мөселман халкы яши. Җомга көннәрендә, гает бәйрәмнәрендә мәчетләр гыйбадәткә килүчеләр белән тула.

Бүгенге көндә мөселман өммәтенә бердәмлек җитеп бетмәгәне беркемгә дә сер түгел. Ул булмаса, без уңышларга, Аллаһның чиксез рәхмәтенә, ризалыгына ирешә алмаячакбыз. Бары тик бергә булып, бердәм булып кына бу дөньяда да, ахирәттә дә бәхетле була алачакбыз.

Ни өчен бер-беребездән аерылганбыз соң? Нинди сәбәпләр аркасында араларыбыз өзелгән? Бердәмлеккә ничек ирешергә кирәк? Әлеге сорауларга бүгенге вәгазебездә җавап бирергә тырышырбыз, ин шә Аллаһ.

Мөхтәрәм җәмәгать! Бер Аллаһка һәм Аның расүле, сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәдкә S инанучылар бер-берсенә кардәшләр икәнлеген истә тотарга тиеш. Бу турыда Аллаһы Раббыбыз «Хүҗүрат» сүрәсенең 10 нчы аятендә болай дип әйткән:

إِنَّمَا الْمُؤْمِنُونَ إِخْوَةٌ فَأَصْلِحُوا بَيْنَ أَخَوَيْكُمْ وَاتَّقُوا اللَّهَ لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ ﴿١٠﴾

**«Мөселманнар үзара кардәшләр. Шулай булгач, кардәшләрнең арасын җайласагыз һәм Аллаһтан (җәзасыннан) курыксагыз, ярлыканырсыз, Аның рәхмәтләренә ирешерсез».**

«Хүҗүрат / Бүлмәләр», 49:10

Бу аятьтән аңлашылганча, мөселманнар бер-берсенә танышлар, дуслар гына түгел, ә бик якын кардәшләр. Андыйларга нинди мөнәсәбәттә булырга кирәклеген барыбыз да беләбез. Кардәшлек турында хәдисләрдә дә күп әйтелгән.

Пәйгамбәребез S : «Мөселман икенче мөселманга кардәштер. Ул аңа хыянәт итәргә, аны алдарга һәм ярдәмсез калдырырга тиеш түгел. Аның намусына, малына һәм тормышына кул сузу – хәрамдыр. Тәкъвалык менә монда! – дип, Аллаһның Расүле өч тапкыр калебенә төртеп күрсәткән дә: «Әгәр берәү мөселман кардәшен кимсетсә, рәнҗетсә, аңа бу гамәл җитәрлек зарар булыр», – дип әйткән[1].

[1] Имам Нәвави хәдисләр җыентыгыннан

Шулай ук: «Мәрхәмәт, ярату һәм бер-берсен аңлауда мөэминнәр бер гәүдә шикелле: әгъзаларның берсендә авыру булса, бөтен гәүдә моңа борчу һәм тән кызуы белән җавап бирә»[1].

«Аллаһ ризалыгы өчен бер-берсен сөйгән кардәшләр Кыямәт көнендә Гареш күләгәсендә нурдан ясалган тәхетләрдә утырырлар». Хәдисне Әхмәд ибн Хәнбәл китерә.

«Әгәр берәү үзенә теләгәнне кардәшенә теләмәсә, аның иманы камил булмас»[2].

Әүвәл без шуны аңларга тиеш: дөньяда яшәүче барлык мөселманнарның Раббысы – бер, Пәйгамбәре – бер, Китабы – бер, кыйбласы – бер, шуңа күрә барлык мөселманнар үзара кардәш. Динебезнең төп максатларының берсе – кешеләрнең сөю һәм дуслык белән, бер-берсен хөрмәт итеп, кадерләп, бер-берсе өчен кайгырып яшәүләре. Сөекле Пәйгамбәребез S һәр кешене башкаларга яхшылык, изгелек теләргә чакыра. Моны тормышка ашыру нәтиҗәсендә үрнәк дәүләт төзелә. Һәр кеше үзендә булган нигъмәтләрне башкаларга теләсә, ул аларга яхшылыклар эшләячәк, рәнҗетүдән саклаячак. Бу очракта кешеләр дә аны яратачаклар, тиешле ярдәм итәчәкләр, рәнҗетүдән сакланачаклар. Нәтиҗәдә, кешеләр арасында мәхәббәт булачак, золым юкка чыгачак.

Кызганыч, бер мөселманның икенчесен тәнкыйтьләгәнен, орышканын еш ишетергә һәм күрергә туры килә. Хәтта кайбер мөселманнар бер-берсе белән сугышалар, әйтерсең, бер-берсенә дошманнар!

Әгәр берәү мөселман кардәшен үзенә дошман итеп санаса, димәк, аның калебе (күңеле) – авыру. Бу күңелдә я иман юк, я ул зәгыйфь. Без һәрвакыт күңелләребезгә игътибарлы булырга тиеш.

Көннәрдән беркөнне Пәйгамбәребез S сәхабәләргә: «Бүген сезнең яныгызга җәннәткә керәчәк бер кеше килә», – дип игълан иткән. Әтеге кеше килгәч, сәхабәләр аның артыннан күзәтеп йөри башлаганнар. Берничә

1 Имам Нәвави хәдисләр җыентыгыннан

2 Имам Бохари һәм имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан

көн күзәткәч, аның башкалардан артык гыйбадәт кылганын күрмәгәннәр һәм аптырап: «Синең кешеләрдән артык нинди сыйфатларың бар?» – дип сораганнар. Әлеге кеше әйткән: «Мин үз гомеремдә кешеләр турында начар сүз сөйләмәдем һәм берәүдән дә көнләшмәдем», – дип әйткән. Бу кеше үзенең теленә, күңеленә хуҗа булган, башкаларны рәнҗетерлек сүзләр сөйләмәгән, калебен көнчелектән пакьләгән, шулай итеп җәннәт әһеле дәрәҗәсенә ирешкән.

Мөселманнарда төрле фикерләрнең булуы таркаулыкка, дошманлыкка китерергә тиеш түгел. Фикер каршылыклары – Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте. Бу хакта сөекле Пәйгамбәребез S: «Өммәтемдә төрле фикерләрнең булуы – Аллаһның рәхмәтедер», – дип әйткән. Сәхабәләр дә төрле фикердә булган, ләкин алар бер-берсен бидгатьтә (яңалык кертүдә), ширектә, көферлектә гаепләмәгәннәр, киресенчә, уртак тел табып, бер-берсен хөрмәт иткәннәр, бердәм булганнар, шуңа күрә аларга Аллаһы Раббыбыз үз рәхмәтен һәм бәрәкәтен биргән.

Изге Коръәндә Аллаһы Тәгалә безгә болай дип боера:

وَاعْتَصِمُواْ بِحَبْلِ اللّهِ جَمِيعًا وَلاَ تَفَرَّقُواْ وَاذْكُرُواْ نِعْمَةَ اللّهِ عَلَيْكُمْ إِذْ كُنتُمْ أَعْدَاء فَأَلَّفَ بَيْنَ قُلُوبِكُمْ فَأَصْبَحْتُم بِنِعْمَتِهِ إِخْوَانًا ﴿١٠٣﴾

**«Ий мөэминнәр! Барчагыз да бер булып, Аллаһ арканына, ягъни Коръән хөкемнәренә ныклап ябышыгыз! Таркалып аерылмагыз! Бер-берегезгә дошман идегез, Ул сезнең күңелләрегезне берләштерде. Аның нигъмәте белән кардәшләр булыгыз».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:103

Сәхабәләрнең тормышыннан бер мисал китерәсем килә. Бер көнне сәхабәләр Бәни Курайза исемле кабиләгә каршы походка әзерләнгәндә, Аллаһның Расүле S аларга мөрәҗәгать итеп: «Бәни Курайзага барып җиткәнче беркем дә икенде намазын укымасын», – дип әйткән, ләкин

алар юлда булганда намаз вакыты кергән. Сәхабәләрнең кайберләре намазны соңрак, ягъни Бәни Курайзага барып җиткәч укырга ният кылганнар, икенчеләре исә, башка фикердә булганнар. Алар уйлавынча, Пәйгамбәребезнең S сүзләре тыюны аңлатмаган һәм икенде намазын юлда укыганнар. Бу хәл турындагы хәбәр Расүл әкрамга S барып җиткәч, ул бер якны да тәнкыйтьләмәгән. Әлеге вакыйга безгә бер үк аятьне яисә хәдисне төрлечә аңларга мөмкин булуын күрсәтә. Безгә шуны бик яхшы истә тотарга кирәк: фикер каршылыклары шәригать кысаларыннан чыкмаска тиеш.

Тарихка күз салсак, дүрт мәзһәбнең дә галимнәре үзара тату, дус булганнар, бер-берсенә белемнәрен арттырырга ярдәм иткәннәр. Алар сөйләшү, бәхәсләшү әдәпләрен бик яхшы белгәннәр.

Мөхтәрәм мөселманнар! Аллаһы Тәгалә барыбызга да бердәм булып, игелекле гамәлләр кылып, хәрамнардан тыелып яшәргә, бу дөньяда һәм ахирәттә дә бәхет-сәгадәткә ирешергә насыйп итсә иде.

*Нияз хәзрәт Сабиров,*
*ТҖ МДНнең дәгъвәт бүлегенең җитәкчесе,*
*Апанай мәчете имам-хатыйбы,*

*24 ноябрь вәгазе*

*Рабигыль-әүвәл аеның 6 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1439 ел*

# Пәйгамбәр күрсәтмәләре — безгә маяклы юл

Рабигыль-әүвәл ае башланды. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа S рабигыль-әүвәл аенда туган, рабигыль-әүвәл аенда дөньядан үткән. Без бу айда аның тормышын, сыйфатларын өйрәнергә, аны күбрәк искә алырга, аңа охшарга тырышырга тиеш. Пәйгамбәребезнең S күркәм сыйфатларының берсе – күркәм холкы, күркәм әхлагы. Аллаһы Раббыбыз да аңа: «Синең әхлагың төзек булмаса, синең күңелең йомшак булмаса, сиңа иярүчеләр дә шушы хәтле күп булмас иде», – дип әйткән. Ислам динебезнең нигезе булып тәүхид — бер Аллаһка гына ышану торса, аның икенче мөһим өлеше — гүзәл әхлак, күркәм холык. Аллаһның безгә боерган фарызлары, тыйган хәрамнары бүген безнең әхлагыбызны төзәтергә ярдәм итә. Әгәр бер кеше намаз укып, ураза тотып, аның холкы яман булса, аның теленнән дә, кулыннан да башкалар зыян күрсәләр, бу вакытта аның шушы ямьсез холкы, начар гадәтләре кылган фарыз гамәлләрен юкка чыгара, аларның әҗерен бетерә. Димәк, бу кеше намаз укымый, тик хәрәкәтен генә ясый, теленнән дә, кулыннан да, сүзеннән дә тирә-юнендәге кешеләргә тынгылык юк. Димәк, аның намазы «өлгереп», «пешеп» җитмәгән. Кеше намаз укый, ураза тота икән, ул — гүзәл әхлак иясе дә булырга, үзен-үзе тыя белергә дә тиеш. Шушы вакытта гына аның үтәгән фарыз гамәлләре кабул булачак, дип әйтелә хәдисләрдә.

Пәйгамбәребезнең S бер хәдисендә болай дип әйтелә: «Бер кеше гүзәл, күркәм холыкка ия булса, аның шушы гүзәл холкы нәфел уразалары, нәфел намазы савабын алу дәрәҗәсенә күтәрелер». Начар холык фарыз гамәлләребезне юкка чыгара, ә гүзәл холык хәтта безнең нәфел ура-

залары, нәфел намазларына караганда да күбрәк савап бирә, безне күбрәк дәрәҗәгә күтәрә икән.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафаның S гүзәл холык, күркәм әхлак турында тагын бер хәдисе бар: «Шәригатебезгә һәм акылыбызга муафыйк булмаган, начар, фәхеш, оятсыз булган сүзләрне кычкырып сөйләмәгез, аны кат-кат әйтмәгез».

Хәдиснең беренче өлешендә Пәйгамбәребез телебезне бозык сүзләр әйтүдән сакларга куша. Безнең нәфис әдәбиятыбыз, матур сәнгатебез дә әхлакны төзәтү юлында эшләргә тиеш. Күбегез телевизор карыйсыздыр. Ул әхлакны төзәтәме? Әгәр гаилә, балаларыбыз, әти-әниләребез белән бергә утырып карыйбыз икән, шуннан гыйбрәт алырга тиешбез. Күрсәтелгән әсәрләр, тапшырулар бездә ахмаклыкка, наданлыкка, оятсызлыкка каршы нәфрәт уятырга, күркәм, гүзәл хисләрне көчәйтергә тиеш. Ә бүген анда нәрсә генә күрсәтмиләр? Әти-әниең, балаларың белән түгел, ә кайчакта хәтта җәмәгатең белән утырып карарга да оят булып китә. Бозык халыкта — бозык сәнгать, дигән шикелле.

Аллаһы Тәгалә болай дип әйтте:

إِنَّ اللَّهَ لَا يُغَيِّرُ مَا بِقَوْمٍ حَتَّىٰ يُغَيِّرُوا مَا بِأَنفُسِهِمْ ﴿١١﴾

**«Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә бер кавемдә булган нәрсәне, алар үзләре яхшы гамәлләрен явызлыкларга алмаштырганчы үзгәртми, ягъни халыктан күркәм хәлнең китүенә халык үзе сәбәпче».**

«Рәгыд / Күк Күкрәү», 13:11

Без бүген татар халкын, татар милләтен күтәрергә теләсәк, иң беренче чиратта әхлакны төзәтергә кирәк. Гүзәл әхлаклы халыкны беркем дә җиңә алмый. Бозык әхлаклы халыкка исә бернинди дошман да кирәк түгел, ул үз бозыклыгы белән үзен-үзе юкка чыгара.

Гарәпләр ислам динен кабул иткән вакытта, әхлакны шулхәтле югары дәрәҗәгә күтәрделәр ки, алар алдында зур империяләр баш иде. Бөтен дөньяны үз кулында тоткан Рим империясе, Фарсы империясе яшәгән, әмма андагы халыкларның әхлагы бозык булган. Үзләренең гүзәл холыклары белән гарәпләр өстен чыкты. Бер халык Җир йөзендә үзенең урынын табарга теләсә, ул гүзәл әхлаклы булырга, балаларын шушы гүзәл әхлак белән тәрбияләргә тиеш. Аларда яхшылыкка мәхәббәт, начарлыкка карата нәфрәт уянсын. Сәнгать әсәрләре дә шуңа хезмәт итсен. Бүген безнең халкыбыз әхлак ягыннан шулхәтле түбән төште ки, югары сәнгатьне бөтенләй аңламас хәлгә җитте. Безнең сәнгать әһелләребез, язучыларыбыз халыкта күркәм әхлак тәрбияләсе урынга, үзләре үк төрле ямьсез сүзләр кулланалар, оятсыз мәзәкләр сөйлиләр, газетага да шуны язалар, телевизордан да шуны күрсәтәләр. Дивананы тилертәм дигән шикелле, нәтиҗәсен белмичә, шырык-шырык көлдерер өчен, нәрсәләр генә эшләмиләр. Артистларыбыз да ниләр генә кыланмыйлар, сәхнәдә кайсы җирләрен генә ачып күрсәтмиләр. Моның белән милләтне тәрбияләп, алгы урынга чыгып булмый.

Пәйгамбәребез Мөхәммәднең S бу турыда да хәдисе бар: «Үзебезне мөселман дип саныйбыйз икән, «Ләә иләәһә илләлааа һ, Мүхәммәдүр Расүүлүллааһ» дип иман китергәнбез икән, без әхлагыбызны сафландырырга тиешбез». Балаларыбызны да гүзәл әхлак белән тәрбиялик. Шулай булганда гына безнең картлыгыбыз тыныч үтәр, балаларыбыз да инсафлы булыр, милләтебез дә алга чыгар.

Әхлак төзәтүнең иң беренче адымында без балаларыбызны Аллаһны танырга, Аллаһны хөрмәт итәргә өйрәтик. Аллаһның безгә кушкан иң зур фарызы — гыйлем. Гыйлемгә мәхәббәт уятырга кирәк. Гыйлем нәрсә ул? Пәйгамбәребез S бу сорауга: «Гамәл һәм әдәп», — дип җавап бирә. Димәк, берәү гамәлен үтәп, аның әдәбе булмаса, ул — надан. Гыйлемле кеше гамәлне, фарыз гамәлләрен үтәргә, хәрамнан тыелырга тиеш. Һәм аның

шушы ук вакытта әдәпле, күркәм кеше булып калуы шарт. Аңардан нур бөркелеп торсын. Ул фарыз гамәлләрне кеше күрсен өчен генә, я булмаса, кемдер кушкан өчен генә үтәмәсен, үзе тырышып, гүзәл әхлакка килсен. Шулай булмаса, ул үз эшен җиренә җиткерми, дигән сүз. «Хикмәт нәрсә ул?» — дигән сорауга Пәйгамбәребез Мөхәммәд: «Гыйлем белән гамәлнең туры килүе ул», — дип җавап кайтарган. Берәү галимлеккә ирешә, әмма ялкау була. Намазларын укымый, ураза тотмый. Үзе динен дә яхшы белә: «Мин динле, шәригатьне бик яхшы беләм», – дип, мактанып та йөри әле. Әмма үзе аракы эчә, дуңгыз асрый, аның итен ашый, хәрамнан тыелмый, фарыз гамәлләрне үтәми. Димәк, моның гыйлемлегеннән үзенә дә, халыкка да бер файда да юк. Берәү тырыша, гыйбадәт, гамәл кыла, ураза тота, намаз укый — гыйлеме юк. Мөхәммәд S : «Диннең афәте өчтер: аның беренчесе — бозык имамдыр, икенчесе — залим түрәдер, өченчесе — үзе надан булып та, дин өчен тырышлык күрсәтүче кешедер», — дип әйткән.

Надан кеше, нәрсәләрнедер белеп бетермәгәнлеге аркасында, кечкенә генә бер әйберне зур итеп күтәреп, төрле низаглар чыгарырга мөмкин. Берәү исә галим дә булса, гыйлемлегенә күрә гамәлен дә кылса, фарызларын үтәп, хәрамнардан тыелса — менә бу хикмәт була, югары дәрәҗәгә ирешкән кеше була. Без дә шушындый хикмәтле гыйлемгә ия булырга тырышыйк. Мин бер вәгаземдә: «Юл кагыйдәсен белгән шофер шул кагыйдәләрне үтәмәсә, аның белүеннән файда юк. Дин гыйбадәтендә дә шул ук хәл», – дип әйткән идем.

Икенчесе: без үзебездә ышану көче тәрбияләргә тиеш, балаларыбызда да. Без моны булдыра алабыз, эшли алабыз. Аллаһы Тәгалә безгә ярдәм итә, ярдәменнән ташламый. Күп кенә кешеләребез: «Бернәрсәнең дә рәте юк», – дип, төшенкелеккә бирелеп, эчкечелеккә юлыгалар. Аракыдан юаныч табарга тырышалар. Җиләк шикелле егетләребез, кызларыбыз

аракыга гына түгел, наркомания базына таралар. Бу бит яшәү мәгънәсен тапмаудан, үзеңнең көчеңә ышанмаудан килә.

Без балаларыбызда гүзәл әхлак тәрбияләгәндә, аларның үз көчләренә үзләре ышану рухын күңелләренә сеңдерергә тиеш. Күркәм әхлак тәрбияләүнең бер юнәлеше — вазифаңны, җәмгыятьтә үз урыныңны белү. Сиңа бер эш йөкләтелгән икән, аны намус белән башкарырга тиешсең. Әгәр һәркайсыбыз шулай эшләсә, җәмгыятебездә бик күп хафалар булмый калыр иде. Без алга киткән, хөрмәтле милләт булыр идек. Без еш кына вәгъдәбездә тормыйбыз, вазифаларыбызны кирәгенчә башкармыйбыз, аны кирәклектән түгел, кемдер кушканга күрә, кемдер карап торганга күрә, кемдер өчен генә эшлибез.

Безнең әхлагыбыз шул дәрәҗәгә җитеп бозылды ки, хәтта мәчетләрдә бер-беребез белән ызгышабыз, бер-беребезнең якасына ябышабыз. Бер-беребезне гел гаепләп, юл куймыйча, яман тормыш алып барабыз.

Балык башыннан кортлый, койрыгыннан чистарталар, дигән шикелле, кайсы тармакны карама, ил башындагы җитәкчеләрдән башлап, кеше бер-берсен хөрмәтләп, теге яки бу эштә юл куеп, әйбәт мөгамәләдә буласы урында, ызгышып, тавыш чыгарып яши.

Берәүдән: «Тормышыгыз ничек, ничек яшисез?» — дип сораганнар. Теге кеше: «Тавык кетәгендәге шикелле», — дип җавап биргән. «Ничек соң ул?» — дип сораганнар. «Һәркемнең югарырак менеп кунаклыйсы килә», — дип әйткән, — «янәшәсендәгесен чукыйсы, астындагысын нәҗеслисе килә. Менә шулай итеп яшибез», — дип әйткән, ди. Без дә шушындый тормыш алып барабыз кебек.

Авыллар саен мәчетләрне төзеп, аякка бастырабыз. Миллионлаган акчалар чыгарып, мәчет салганбыз икән, алар әхлак тәрбиясе урынына әверелергә тиеш. Әмма бүген кайберләрендә әледән-әле низаг чыгып тора. Дин әһелләре үзара ызгышалар. Халыкны тәрбияләү, намазны торгызу урынына, һаман нәрсәдер бүлешәләр. Бу да — безнең тәрбиясезлегебезнең

җимеше. Тәрбияләүгә кечкенәдән тотынырга кирәк. Анда да бөтен игътибарны әхлак төзеклегенә, әхлак төзәтүгә юнәлтик. Аллаһны тану, Аны хөрмәт итү, Мөхәммәдне S пәйгамбәр дип тану, аннан үрнәк алу, аның тормышын өйрәнү һәм Аллаһы Тәгалә кушканнарны үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәү гүзәл әхлакка китерер. Әхлак нигезсез була алмый. Ул әхлак Аллаһны танудан башланырга тиеш. Коммунизмның әхлак кодексы бар иде. Анда бер начар сүз дә юк, алар хәтта Коръән аятенә дә, хәдисләргә дә каршы килми. Әмма аның нигезе бушлыкка корылган иде. Аллаһны тану дигән нәрсә юк анда. Бу дөньяда мәңге үзгәрми торган фәкать бер Аллаһы Тәгалә, Аның кануннары бар. Шуңа күрә без Аллаһы Тәгалә кушкан әхлак белән, Ул кушканча яшәргә тиеш. Аллаһы Тәгалә тыйганнардан тыелырга тиешбез.

Без, иманыбызны ныгытып, җаннарыбызны сафландырып, гүзәл әхлак белән яшәргә тиешбез. Гыйлемнең нигезен — Аллаһны тану гыйлемен өйрәник. Аны «тәүхид гыйлеме» диләр. Аллаһның берлегенә инану гыйлеме, Аллаһны тану гыйлеме. Аллаһны танысак, Аны инкяр итмәсәк, хәрам дигән әйберләрдән тыелсак, дөрес әхлакка ирешербез.

Кешедә холык ике төрле була. Бала туганда ук шатлана, борчыла, кайгыра, көлә, матурлык өчен сөенә, начар әйберне күрсә — көенә. Бу — холыкның тумыштан булган, үзгәрми торган сыйфатлары. Бу сыйфатлар кеше картайганчы дәвам итә, үзгәрми. Кешенең берсе намаз укый, ураза тота, Аллаһы Тәгалә кушканча яши. Әмма холыкта икенче төрле як та бар. Кеше аракы эчә, отышлы уеннар уйный, хәрам ризыклар ашый: менә монысы — холыкның үзгәрә торган яклары. Без холыктагы үзгәрә торган якны тәрбияләргә тиеш. Пәйгамбәрләр дә шуның өчен җибәрелгәннәр. Бүген без рабигыль-әүвәл ае, Мәүлид ае, дибез икән, Мөхәммәд S безгә дөрес юлны өйрәтер өчен Аллаһы Тәгалә тарафыннан җибәрелгән пәйгамбәр икән, без аның эшен дәвам итеп, кешеләрнең холкын яхшы

якка үзгәртү өчен эшләргә тиешбез. Бөтенебез дә. Әгәр шушы эшне эшли алмасак, безнең җәмгыятебез бетәргә мөмкин.

Аллаһы Тәгалә болай дип әйтте:

وَلَقَدْ أَهْلَكْنَا الْقُرُونَ مِن قَبْلِكُمْ لَمَّا ظَلَمُوا ۙ وَجَاءَتْهُمْ رُسُلُهُم بِالْبَيِّنَاتِ وَمَا كَانُوا لِيُؤْمِنُوا ۚ كَذَٰلِكَ نَجْزِي الْقَوْمَ الْمُجْرِمِينَ ﴿١٣﴾

**«Тәхкыйк, сездән әүвәл килеп золым кылган кавемне Без һәлак иттек, моннан гыйбрәт алыгыз! Расүлләре аларга ачык могҗизалар, вә ислам диненең гадел хөкемнәре белән килделәр, шулай да иман китермәделәр. Шуның кеби гөнаһка чумган кешеләрне җәза кылачакбыз».**

«Юныс», 10:13

Бозыклыкның чигенә җиткәндә Аллаһы Раббыбыз безгә дә шушындый мөмкинлек бирде: юк җирдән диярлек мәчетләребез калкып чыкты, имамнарыбыз бар, җомга намазлары укыла, радио-телевидениедән күп булмаса да дини вәгазьләр ишетелә. Аллаһны танырга, фарыз гамәлләрне үтәргә, хәрамнан тыелырга чакыралар. Әгәр шуннан соң да дөрес юлны тапмасак, без һәлак булмабызмы соң? Бу хәл турында Коръәндә ачык әйтелгән. Әгәр без холкыбызны, әхлагыбызны үзгәртә алмыйбыз икән, без юкка чыгабыз. Моңа бернинди чит ил тыкшынуы да, күрсәтмә дә кирәк түгел.

Кабаттан, Аллаһы Тәгалә болай дип әйтте:

إِنَّ اللَّهَ لَا يُغَيِّرُ مَا بِقَوْمٍ حَتَّىٰ يُغَيِّرُوا مَا بِأَنفُسِهِمْ ﴿١١﴾

**«Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә бер кавемдә булган нәрсәне, алар үзләре яхшы гамәлләрен явызлыкларга алмаштырганчы үзгәртми, ягъни халыктан күркәм хәлнең китүенә халык үзе сәбәпче».**

«Рәгыд / Күк Күкрәү», 13:11

Пәйгамбәребез Мөхәммәднең S бер хәдисендә Кыямәт көнендә Аллаһның рәхмәтенә ирешәчәк 7 төрле кеше күрсәтелә. Шуның беренчесе — гадел җитәкче. Икенчесе — мәчеттә укылган намаздан яңадан анда керү теләге белән чыккан кеше. Өченчесе — гыйбадәт кылучы егет. Дүртенчесе — ахирәт, Аллаһ ризалыгы өчен дуслашкан кешеләр. Бишенчесе — сәдаканы яшерен бирүче кеше. Алтынчысы — аулакта бер Аллаһның ризалыгын өмет итеп кенә намаз укып, күзләреннән яшь чыгарып гыйбадәт кылучы. Соңгысы — берәү бозык юлга чакырганда, Аллаһтан куркып, үзен шушы бозыклыктан тыеп кала алган кеше.

Аллаһы Раббыбыз барчабызга да шушы сәгадәтне бирсен иде. Әгәр безнең оныкларыбыз шушы сәгадәткә ирешсәләр, әлбәттә, милләтебез дә аек, көчле булыр, нык булыр, һәм Татарстаныбыз да шушы гүзәл холыклы кешеләр белән матур тормышта яшәр.

*Җәлил хәзрәт Фазлыев,*

*Татарстанның баш казые*

*1 декабрь вәгазе,*

*Рабигыль-әүвәл аеның 13 нче көне, һиҗри исәп буенча 1439 ел*

# Карун кыйссасы

Изге Коръәндә Карун кыйссасы бик зур урын алып тора. Карун Мусаның а туганнан туган энесе иде. Исраил угылларының башында Фиргавен хаким булып торганда, Карун аның ярдәмчеләреннән берсе булды, золымлык кылды, күпләрне рәнҗетте, әмма дингә килгәч, ул бик итагатьле һәм диндар кешегә әйләнде. Кайбер риваятьләр буенча, ул Мусадан а соң Тәүратны иң яхшы белүчеләрдән булды. Карун башта фәкыйрьлектә яшәде.

Көннәрдән бер көнне Карун янына кеше кыяфәтендә шайтан килде һәм әйтте: «Әйдә бер көн гыйбадәт кыл, ә икенче көн сәүдә белән мәшгуль бул һәм кешеләргә дә мохтаҗ булмассың», – диде. Әлбәттә, Карунга бу тәкъдим бик ошады һәм алар икенче көнне базарга бардылар.

Аннары шайтан тагын килеп Карунга әйтте: «Әйдә хәзер бер атна сәүдәдә бул, ә икенче атнада гыйбадәт кыл», – диде. Бу тәкъдим дә Карунга ошады. Һәм әкрен-әкрен Карун көннән көн байый башлады, гыйлемгә бик зур хирыслыгы булды. Карун үз чорында бик укымышлы кеше булды. Карун төрле фәннәрне үзләштерде: химия, икътисад, сәүдә гыйлеме һ. б. Ул үз заманының иң бай кешесенә әйләнде.

Аның күңелендә һәрвакыт агасы Мусага көнчелек яшәде. Мусаның зур ихтирамга ирешкәнгә, халык аның сүзен тыңлаганга, Карун бик нык көнләште. Көнчелек чире күпләребездә бар. Бу чир иманның зәгыйфьлегеннән килә. Әгәр берәребездә кара көнчелек булса, аны тиз дәваларга кирәк, чөнки көнчелек күп кенә бозыклыкларның башы, сәбәбе булып тора. Ләкин, мөхтәрәм кардәшләр, Карунда иман югала, аның бөтен уе мал һәм гыйлем туплап, үзенең дәрәҗәсен кешеләр ара-

сында күтәрүгә юнәлгән була, ягъни «менә мин дә монда бар һәм мин дә Мусадан ким түгел» икәнен исбатлыйсы килде аның. Карун зур дәрәҗәгә ирешә. Коръәндә бу турыда әйтелә:

إِنَّ قَارُونَ كَانَ مِن قَوْمِ مُوسَىٰ فَبَغَىٰ عَلَيْهِمْ ۖ وَآتَيْنَاهُ مِنَ الْكُنُوزِ مَا إِنَّ مَفَاتِحَهُ لَتَنُوءُ بِالْعُصْبَةِ أُولِي الْقُوَّةِ إِذْ قَالَ لَهُ قَوْمُهُ لَا تَفْرَحْ ۖ إِنَّ اللَّهَ لَا يُحِبُّ الْفَرِحِينَ ﴿٧٦﴾

**«Хактыр ки, Карун – Муса кавеменнән иде. Ләкин ул (халкына) каршы гаделсезлек кылды. Без аңа шундый байлык бирдек ки, (аның хәзинә саклана торган амбарларның) ачкычларын хәтта куәтле баһадирлар да көчкә күтәреп йөрер иде. Шул вакыт кавемдәшләре аңа әйтте: «Масайма (байлыгың белән)! Аллаһ мактанчыкларны сөймәс», – диде».**

«Касас / Хикәя», 28:76

Ягъни аның акча тулы бик күп сарайлары булган, ачкычлары бик зур булганга күрә, шул ачкычларны ун кеше күтәреп йөргән. Әгәр кеше байлыкка ирешеп, калебендә миһербанлык булмаса, һәм шул байлыкны Аллаһ кушканча кулланмаса, ягъни зәкәтен, сәдакасын бирмәсә, мохтаҗ кешеләргә ярдәм итмәсә, бу акча бозыклыкка юнәлтә һәм ахыр чиктә һәлакәткә илтә!

Аллаһы Тәгалә Карун кыйссасын дәвам итеп әйтә:

وَابْتَغِ فِيمَا آتَاكَ اللَّهُ الدَّارَ الْآخِرَةَ ۖ وَلَا تَنسَ نَصِيبَكَ مِنَ الدُّنْيَا ۖ وَأَحْسِن كَمَا أَحْسَنَ اللَّهُ إِلَيْكَ ۖ وَلَا تَبْغِ الْفَسَادَ فِي الْأَرْضِ ۖ إِنَّ اللَّهَ لَا يُحِبُّ الْمُفْسِدِينَ ﴿٧٧﴾

**«(Карунның кавемдәшләре) әйтте: «Аллаһның сиңа биргән мөлкәтеннән (хәер, сәдака, зәкәт) биреп, Ахирәт көненә**

**әзерлән. Дөньядагы өлешеңне дә онытма. Аллаһ сиңа бәрәкәт биргән кебек, син дә (кешеләргә сәдака биреп) юмарт бул. Җир йөзенә бозыклык таратма. Аллаһ бозыкларны сөйми».**

«Касас / Хикәя», 28:77

Аятьтә бәян ителгәнчә, Мусаның а кавеме Карунга әйтте: «Аллаһы Тәгалә сиңа күп байлык бирде, шуның белән мактанып йөрмә, бу байлыгыңа артык шатланма, гөнаһ кылып, кешеләргә зыян китермә, үзең өчен, җәмгыять өчен зарарлы булган гамәлләрдән тыел инде! Ахирәтне күбрәк уйлап, Аллаһ каршына барып, хисап бирәсе бар, дип фикерлә, ләкин шул ук вакытта дөнья насыйбыңны да онытма!»

Карунның җавабын карагыз:

قَالَ إِنَّمَا أُوتِيتُهُ عَلَىٰ عِلْمٍ عِندِي ۚ أَوَلَمْ يَعْلَمْ أَنَّ اللَّهَ قَدْ أَهْلَكَ مِن قَبْلِهِ
مِنَ الْقُرُونِ مَنْ هُوَ أَشَدُّ مِنْهُ قُوَّةً وَأَكْثَرُ جَمْعًا ۚ وَلَا يُسْأَلُ عَن ذُنُوبِهِمُ
الْمُجْرِمُونَ ﴿٧٨﴾

**«Бу байлык миңа бары тик гыйлемем аркасында гына (үз тырышлыгыма күрә) килде, – диде. Үзеннән әүвәл килгән, аннан да куәтле-бай, өстен булганнарны Аллаһ һәлак иткәнен белмиме ул? Андый гөнаһлардан сорау алып торылмас (алар туптуры җәһәннәмгә ябылыр)».**

«Касас / Хикәя», 28:78

Ягъни гыйлемгә мин үзем ирештем, Аллаһ миңа аны бирмәде һәм байлыкка да үзем ирештем, дип, Аллаһ биргән гыйлемне, малны инкяр итеп, бу мал һәм гыйлем үземнеке генә, дип тәкәбберләнде.

Карунның кыйссасы бүгенге көндә күпләребезгә зур бер гыйбрәт. Карунның кыйссасы шушы сүзләрне әйтү өчен генә булса да сөйләнергә тиеш. Күпләр Карун кебек: «Мин үз тырышлыгым, гыйлемем белән генә

бу дәрәҗәгә яки байлыкка ирештем», – дип әйтәләр, әйтмәсәләр дә, шулай уйлылар. Хәтта үзен мөселман дип санаган кешеләрдән шундый сүзләр ишетергә туры килә. Мондый мактанулардан сакланырга кирәк, чөнки бу көферлеккә илтә! Бөтен мактаулар Раббыбыз Аллаһыга гына хас!

Кайбер риваятьләрдә килә: Карун әйткән: «Әгәр мин яхшы кеше булмасам, Аллаһ миңа бу байлыкны бирмәгән булыр иде», – дигән. Күпләребез шулай уйлый, кеше фәкыйрь, авыру икән, димәк, Аллаһ аны яратмый һәм ул начар кеше, әгәр инде бай һәм сәламәт икән, димәк, Аллаһ аны ярата. Мондый уйлар дөресме? Дөрес булса, Мөхәммәдне s Аллаһ яратмадымы? Гайсәне a яратмадымы? Гайсә дөньяда иң фәкыйрь кеше була. Әйюб пәйгамбәрне яратмадымы? Ул иң авыру кеше була. Аллаһы Тәгалә пәйгамбәрләргә һәм әүлияләргә иң авыр сынаулырны җибәрде. Раббыбыз Аллаһ сабыр иткән кешеләрне яратадыр. Байлык яки фәкыйрьлек Аллаһның сынавы, ярату яратмау галәмәте түгел!

Әлбәттә, укырга, эшләргә, һәрвакыт хәрәкәттә булырга, дәрәҗәләребезне арттырырга тырышырга тиешбез, тик масаймаска, мактанмаска, үзебезгә генә таянмаска, сәбәпкә дә таянмаска, Аллаһны мактап, иң әүвәл Аңа гына таянып яшәргә кирәк.

Муса a көннәрдән бер көнне вәгазь сөйләде, бөтен кеше гаҗәпләнеп, сокланып аны тыңлап утырды, шунда Карун чыкты һәм бу турыда Коръәндә болай дип әйтелә:

فَخَرَجَ عَلَىٰ قَوْمِهِ فِي زِينَتِهِ ۖ قَالَ الَّذِينَ يُرِيدُونَ الْحَيَاةَ الدُّنْيَا يَا لَيْتَ لَنَا مِثْلَ مَا أُوتِيَ قَارُونُ إِنَّهُ لَذُو حَظٍّ عَظِيمٍ ﴿٧٩﴾

**«Шулай киенеп, ясанып (Карун) халык каршысына чыкты. Дөнья артыннан куучылар әйтте: «Их, Карун кебек бай булсаң иде. Ул, чыннан да, дөньядагы иң бәхетле кеше» – диделәр.**

«Касас / Хикәя», 28:79

Муса пәйгамбәрнең вәгазен тыңлаган халыкның күбесе «ах-вах» килеп Карунга таба борылдылар һәм үзләренә дә мондый байлык теләделәр, тик бармак белән генә санарлык гыйлем әһелләре, вәгазь тыңлаудан туктамаган кешеләр, боларга әйттеләр:

وَقَالَ الَّذِينَ أُوتُوا الْعِلْمَ وَيْلَكُمْ ثَوَابُ اللَّهِ خَيْرٌ لِّمَنْ آمَنَ وَعَمِلَ صَالِحًا
وَلَا يُلَقَّاهَا إِلَّا الصَّابِرُونَ ﴿٨٠﴾

**«Үкенеч булсын сезгә, иман китереп изге гамәлләр кылган кешеләргә Аллаһ вәгъдә иткән җәннәт нигъмәтләре Карунга бирелгән малдан хәерлерәктер, ул җәннәткә ирешмәс, һичкем, мәгәр сабыр итеп Аллаһ юлында яшәгән хак мөэминнәр ирешерләр».**

«Касас / Хикәя», 28:80

Әмма күп кенә кешеләр бу дөнья зиннәтләренә, байлыкларына кызыгып, хак зиннәтне, ягъни динне оныталар.

Бер көнне Муса а Карунга әйтте: «Әйдә халык каршында бергә дога кылабыз һәм шунда кемнең догасы кабул булачагын белербез. Беренче доганы син кыл, Карун, миңа карата нинди теләкләрең булса, догада шуларны әйтерсең, аннары мин дога кылырмын», – диде Муса а. Карун Муса пәйгамбәргә каршы дога кылды, эчендәге бөтен әшәкелеген чыгарды. Шуннан соң Муса а әйтте: «Нәрсә булса да үзгәрдеме?» «Юк», – дип җавап бирде Карун. Аннары Муса а: «Хәзер мин дога кылам», – диде. Муса а дога гына кыла башлагач, җир селкенде һәм бөтен байлыгы, йорты белән Карунны җир йотып җибәрде. Аллаһы Тәгалә бу турыда болай дип хәбәр бирә:

فَخَسَفْنَا بِهِ وَبِدَارِهِ الْأَرْضَ فَمَا كَانَ لَهُ مِن فِئَةٍ يَنصُرُونَهُ مِن دُونِ اللَّهِ وَمَا
كَانَ مِنَ الْمُنتَصِرِينَ ﴿٨١﴾

**«Без ул Карунны һәм йортын җиргә йоттырдык, чөнки Карун байлыгына таянып, Мусаны күп җәберләде. Шул вакытта Аллаһтан башка Карунга ярдәм бирүче булмады, һәм җир астына китүдән үзен-үзе дә саклый алмады».**

«Касас / Хикәя», 28:81

Шундагы кешеләр бу хәлне күреп шаккаталар һәм ярый әле без Карунга иярмәдек, дип әйтәләр.

Аллаһ әйтә:

وَأَصْبَحَ الَّذِينَ تَمَنَّوْا مَكَانَهُ بِالْأَمْسِ يَقُولُونَ وَيْكَأَنَّ اللَّهَ يَبْسُطُ الرِّزْقَ لِمَن يَشَاءُ مِنْ عِبَادِهِ وَيَقْدِرُ ۖ لَوْلَا أَن مَّنَّ اللَّهُ عَلَيْنَا لَخَسَفَ بِنَا ۖ وَيْكَأَنَّهُ لَا يُفْلِحُ الْكَافِرُونَ ﴿٨٢﴾

**«Әле күптән түгел генә Карунның дәрәҗәсен өмет итүче кешеләр аның йорты белән җир астына киткәнен күреп тордылар һәм әйттеләр: «Гаҗәп, бу эш безгә шөбһәле булды, Аллаһ сынар өчен теләгән бәндәсенә киң ризык һәм теләгән бәндәсенә тар ризык бирер икән, әгәр Аллаһ, без теләгәнчә, Карун малы кебек малны безгә дә биргән булса, әлбәттә, без дә Карун белән бергә җир астына киткән булыр идек, Карунның эше үкенечле булды! Аллаһка каршы булучылар (комсызлар, гаделсезләр) Аллаһ газабыннан котыла алмаслар икән ләбаса», – диделәр.**

«Касас / Хикәя», 28:82

Аллаһы Тәгалә барыбызны Карун сыйфатларыннан һәм гамәлләреннән сакласа иде!

*Тимергали хәзрәт Юлдашев,*

*«Галиев» мәчете имам-хатыйбы,*

*МДН дәгъвәт бүлегенең баш белгече*

*8 декабрь вәгазе,*

*Рабигыль-әүвәл аеның 20 нче көне, һиҗри исәп буенча 1439 ел*

# Үзеңне онытма

Бөтен галәмне юктан бар итеп, тәрбия кылучы Аллаһы Тәбәракә вә Тәгаләгә чиксез рәхмәтләребез, шөкраналарыбыз булса иде. Аллаһы Раббыбыз тарафыннан галәмнәргә рәхмәт булarak җибәрелгән сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафага S, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә күңел түрләребездән чыккан сәламнәребез, салаватларыбыз һәм һәртөрле изге догаларыбыз булса иде.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

أَتَأْمُرُونَ النَّاسَ بِالْبِرِّ وَتَنسَوْنَ أَنفُسَكُمْ وَأَنتُمْ تَتْلُونَ الْكِتَابَ ۚ أَفَلَا تَعْقِلُونَ ﴿٤٤﴾

**«Сез кешеләрне изгелеккә өндисезме? Әмма үзегезне онытасыз, сез бит Аллаһ китабын укыйсыз, шуны уйлап карамыйсызмы?»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:44

Ягъни үзегез, сез, кешеләр, калган кешеләрне изге гамәлләр кылырга чакырасыз, әмма үзегез турында ни өчен уйламыйсыз, дип әйтелә. Ә бит үзегез китапны беләсез, аны укыйсыз. Шуның турында уйлап карамыйсызмы, ягъни башыгызны бераз эшләтергә теләмисезме?

Коръәннең күп җирендә Пәйгамбәребезнең S уй-фикерләренә карата җавап рәвешендә иңдерелгән аятьләрне күрергә була. Ягъни Пәйгамбәребез S әле үзенең башында гына, теле белән әйтмичә дә, үзенең җирдәге миссиясенең авырлыгы турында уйлап куйганда, Аллаһы Тәгалә аңа җавап итеп Коръән аяте җибәрә: син генә түгел, сиңа кадәр килгән пәйгамбәрләрне дә, алар җибәрелгән кавемнең бер өлеше кабул

итми иде. Әүлияләрне инкяр иттеләр, галимнәрне дә инкяр иттеләр, дип Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләдән аятьләр иңә. Чыннан да, Пәйгамбәребез S нинди генә гамәл кертсә дә, эшләсә дә, аның да кавеменең бер өлеше аңа карата гел явызлыклар эшләде, аңа каршы торды. Адәм баласы шулай бит ул: бөтен кешегә карата да яхшы булып булмый. Бөтен кешегә дә яхшы булып булмый, бөтен кешегә дә начар булып булмый. Бөтен кешегә дә яхшы булган кеше – вафат булган кешедер. Кабердә ятучы кеше. Әле ул да кайбер кешенең: «Ул мондый кеше иде, бик үк түгел иде», – дип, шелтәләгән кешесе була ала. Пәйгамбәребез үз эшен башлагач, ягъни кешеләрне иманга, изгелеккә чакыра башлагач, аның турында башка дин әһелләре дә начар сүзләр сөйли башладылар. Алар аңа: «Син безнең арада фетнә кертәсең, ата-бабаларыбыз динен бетерергә телисең, син ялганчы, без сиңа ышанмыйбыз», – кебек сүзләр белән яла яга, аны орыша, шелтәли башладылар. Менә шушы сүзләреннән соң, Аллаһы Тәгалә аларга мөрәҗәгать итеп шушы аятьне иңдерә дә:

أَتَأْمُرُونَ النَّاسَ بِالْبِرِّ وَتَنسَوْنَ أَنفُسَكُمْ وَأَنتُمْ تَتْلُونَ الْكِتَابَ ۚ أَفَلَا تَعْقِلُونَ ﴿٤٤﴾

**«Сез кешеләрне изгелеккә өндисезме? Әмма үзегезне онытасыз, бит сез Аллаһ китабын укыйсыз, шуны уйлап карамыйсызмы?»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:44

Бу аятьнең иңдерелү тарихы, ягъни иңү сәбәбе шушындый булса да, ул безгә дә кагыла. Күп вакытта, адәм баласы калган кешеләрне изгелеккә чакыра, яхшылыкка өнди, ә үзен оныта, үзен карамый. Ул үзе турында уйламый. Ул – Коръәнне укый, Пәйгамбәребезнең S хәдисләрен белә, динне белә: мондый әдәп бар, мондый тәртип бар, дип әйткән була. Тик үзен оныта.

Бүгенге көндә: «Бездә фарыз бар, нәфел бар», – дип сөрән салып йөрүчеләрне күрергә мөмкин. Алар өчен сөннәт ул нәфелгә керә, шуңа күрә үтәсәң ярый, үтәмәсәң дә ярый. Бездә исә, ягъни әһлес-сөннәт вәл җәмәгадә, дүрт мәзһәб буенча караганда, фарыз дигән төшенчә бар, вәҗиб бар, сөннәт, нәфел, мөстәхәб, мөбах, хәрам, мәкрүһ, мөстәкрәһ дигән төшенчәләр бар, без аларны өйрәнәбез, без аларны белергә тиеш.

Кайбер кешеләр, Аллаһы Тәгаләнең «Гайбәт сөйләмә» дигән әмерен алалар да, аның никадәр авыр икәненә төшенгәч, ә бит чыннан да авыр: «Бу аять Бәни Исраилгә яки башка кавемгә иңгәндер», – дип, үзләренең гайбәт сөйләүләренә аклану эзли башлыйлар. Кеше бит көзге каршына басса: «Мин генә иң гүзәл, иң матур, бар җирем килешкән, иң камиле дә, пөхтәсе дә мин генә», – дип уйлый башлый. Бу фикрләр һәрбер кешенең күңеленнән үтә. «Абау, мин ямьсез; менә мин кабахәт кеше икән; мин явыз кеше», – дип әйткән кеше юк! Ул бит андый әйберләрне кабул итми. Адәм баласы үзен гел изгелектә дип уйлый. Адәм баласы үзен иң матуры, дип уйлый. Адәм баласы үзен иң галим, дип уйлый. Шуңа да үзенә кирәклесен, тиешлесен ала.

Әйтелгән: «Гайбәт сөйләмә». Искә төшерегез: «Сез кешеләрне изгелеккә өндисезме?» Менә ул кеше бүтән бер кешенең гайбәтен сөйли дә, соңыннан: «Әйдә, гыйбрәт булсын», – дип өстәп куя. Ә инде бүтән бер кеше синең яныңда, сиңа ошамаган итеп гайбәт сөйләп куйса: «Син нәрсә? Гөнаһка баттың! Ай-вай», – дип, аны сүгә башлыйсың. Ягъни үзеңнеке гыйбрәт була, кешенеке гайбәт булып кала.

Шулай ук инде, үзе ул бәлки тәхәҗҗүдләрен дә үтәми, нәфелләрне дә үтәргә ашкынмый, сөннәтне сөннәт кенә дип йөри һәм көч-хәл белән фарызларын үти торган кешедер. Хәзер бит шундый тенденция китте: витр намазы вәҗибмы, әллә түгелме? Әлбәттә, Әбү Хәнифә мәзһәбендә ул вәҗиб, Шәфигый мәзһәбендә вәҗиб түгел. Шуңа безнең якларда,

тегеннән-моннан ишеткән сүзләргә таянып, вәҗибларны да төшереп калдырмакчы булалар.

Тәшрик тәкбирләрен дә шундый ук формулировка белән калдырмакчы булалар, ягъни: «Аны бит инде әйтсәң ярый, әйтмәсәң ярый», – дип, вәҗиблыгын калдыралар. Ә бит тәшрик тәкбирләре барлык мәзһәбләр буенча вәҗиб ул. Аллаһы Тәгалә бит безгә: «Тәкәббирһү», – дип әйтә, ягъни «тәкбир әйт». Шуның белән дә вәҗиб була бит ул. Аллаһы Тәгалә «Сыер» сүрәсендә Үзе үк бу турыда безгә хәбәр итә:

وَاذْكُرُوا اللَّـهَ فِي أَيَّامٍ مَّعْدُودَاتٍ

**«Билгеле олуг көннәрдә, ягъни хаҗ көннәрендә Аллаһны күп зикер итегез!»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:203

Ошбу аятьтә нәкъ шушы көннәр турында сүз бара да инде. Без Аллаһны шушы көннәрдә, билгеле көннәрдә күп итеп зикер кылырга тиешбез. Тәкбир әйтергә, хәмед әйтергә, тәсбих әйтергә тиешбез. Әмма шушыларны белә торып та, адәм баласы үзенә туры килгәнне алып, үзенә авыр булганны калдырмакчы була. Исегезгә төшерегез әле, кемнәр фарыз намазларны мәчеттә укыды да, тәшрик тәкбирләрен җәмәгать белән әйтә алды? Ә кемнәр фарызларын, беренчедән, үз өйләрендә укып ятты, шуңа өстәп, кайсыгыз тәшрик тәкбирләрен әйтте?

أَتَأْمُرُونَ النَّاسَ بِالْبِرِّ وَتَنسَوْنَ أَنفُسَكُمْ وَأَنتُمْ تَتْلُونَ الْكِتَابَ ۚ أَفَلَا تَعْقِلُونَ ﴿٤٤﴾

**«Сез кешеләрне изгелеккә өндисезме? Әмма үзегезне онытасыз, бит сез Аллаһ китабын укыйсыз, шуны уйлап карамыйсызмы?»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:44

Бу аятьнең сәбәбе-нүзүле, ягъни иңү сәбәбе булып Пәйгамбәребез заманындагы яһүдләрнең Пәйгамбәребезгә S каршы чыгулары торды. Әмма, әйткәнемчә, аны бит үзебезгә дә кабул итәргә кирәк. Гадәттә, берәр гамәлне халыкка җиткерәсең икән, аны син үзең дә эшләүче булырга тиешсең. Әмма, кеше әле намазның «Н» хәрефен дә белми, намазның ни икәнен күз алдына да китерми, әмма кешеләрне инде өйрәтә башлый. Бер җиргә бара да: «Монда болай эшлә», – дип әйтә, икенче җиргә баргач: «Монда тегеләй эшлә», – дип әйтә башлый. Аңа карата: «Фәлән имам болай дип әйтте бит, ә фәлән галим мондый фәтва чыгарды бит», – дип әйтсәң: «Ул бернәрсә дә белми, ә мин беләм», – дип, үзен акларга керешер, калганнарны наданга да чыгарыр әле. Ләкин, эш монда да түгел, ул – үзен оныта. Үзе бит шул ук гамәлләрне үтәми. Алай гына да түгел, үзе үти дә белми, чөнки намаз дигән гыйбадәтне үтәр өчен генә дә фарыз дигән төшенчәне белергә кирәк, вәҗиб дигән төшенчәне белергә кирәк, сөннәт, нәфел, мөстәхәб, мөбах, хәрам, мәкрүһ, мөстәкрәһ дигән төшенчәләрне белергә кирәк бит. Ягъни намазның фарызларын, сөннәтләрен, мәкрүһларын белергә кирәк бит. Аның фарызларын, сөннәтләрен, мәкрүһларын, әдәпләрен белмәсәң, ничек итеп намаз укырга җыенасың? Әле алай гына да түгел, тәһарәт алу өчен дә бу төшенчәләрне белергә кирәк. Тәһарәтнең фарызларын, сөннәтләрен, мәкрүһларын, әдәпләрен белмәсәң, ничек итеп тәһарәт алырга җыенасың? Пәйгамбәребез S : «Тәһарәт – намаз ачкычы», – дип әйтте. Тәһарәтсез намаз юк дигәнне аңлата бит бу.

Мәсәлән, тәшәһһүдтә утырган вакытта, бармакны күтәреп торыргамы, әллә уң якка әйләндерергәме, сул якка әйләндерергәме, кәкре итеп тотаргамы, туры итеп тотаргамы, дип бүген дә талашалар бит. Әбү Хәнифә аны мөстәһәб гамәл диде, бу бит бәхәсләшә торган гамәл түгел. Синең Аллаһы Тәгаләнең Барлыгын һәм Берлеген телең белән икрар итүең кирәк, күңелең белән кабул итүең кирәк. Намазда, күңелең белән кабул иткән хәлдә, телең белән «Әшһәду әлләә иләәһә илләллаһ» дип әйтүең кирәк. Ә

бармакны күтәрү, я күтәрмәү мәсьәләсе буенча бәхәсләшү кирәкми. Шуңа күрә дә, бармак күтәрүнең мөстәхәб гамәл икәне билгеләнсә, бәхәсләшергә урын да бетәр иде. Башка төр мәсьәләләрдә дә шулай.

أَتَأْمُرُونَ النَّاسَ بِالْبِرِّ وَتَنسَوْنَ أَنفُسَكُمْ وَأَنتُمْ تَتْلُونَ الْكِتَابَ ۚ أَفَلَا تَعْقِلُونَ ﴿٤٤﴾

**«Сез кешеләрне изгелеккә өндисезме? Әмма үзегезне онытасыз, бит сез Аллаһ китабын укыйсыз, шуны уйлап карамыйсызмы?»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:44

Чыннан да уйлап карыйбызмы соң? Китапны, бары тик кешеләрне изгелеккә чакырыр өчен укымыйбыз. Берәр аять, хәдис ишеткәч, өйрәнгәч, аны калганнарга әйтергә ашыкмаска кирәк. Үзебезне тәртипкә салыр өчен дип укырга, өйрәнергә кирәк. Ягъни, берәр кешегә берәр төрле гамәл өйрәткәнче, үзең шул гамәлне өйрән, аны кыла башла. Шуннан соң гына калган кешеләрнең гамәлләрен дөресләү, күңелләрен чистарту, иманнарын ныгыту, Аллаһка якынайту нияте белән калганнарга да өйрәтә башлый аласың.

90 % кеше шундый, китап укыйлар да, калганнарга әйтергә дип, чыгып йөгерәләр. Соң ул кеше Исламны өйрәнмәгән, иманның ләззәтен татып карамаган, интернеттан нидер күрде дә, тизрәк калганнарга сөйли башлый. Башта үзең! Башта үзең эшләп кара, эшли алырсыңмы? Әле ул гамәл файдалымы соң? Аның файдасы турында белер өчен берәр гыйлем иясеннән сорарга кирәк, дип уйламыйсыңмы? Гыйлемле кешеләр, Аллаһка шөкер, бик күп. Әһлес-сөннәт рәтендә булган, Пәйгамбәребезнең S сөннәтендә булган, 4 мәзһәбне дә кабул иткән, гомумән, мәзһәбләрне кабул иткән гыйлем ияләре бар.

Онытмагыз, Кыямәт көнендә һәр кеше Аллаһ каршында берүзе җавап тотачак. Аның каршына кеше япа-ялгыз, үзенең кылган гамәлләре

белән чыгачак. Синең ни дәрәҗәң, ни нәселең, дусларың, туганнарың, ата-анаң да сиңа булыша алмас. Үзең, бары тик үзең өчен генә җавап тотасың бит. Онытма. Дөньяда калганнарга син әйтерсең дә, Кыяматтә үзеңнең гамәлләреңне тапмасаң? Ни эшләрсең? Акчага сатып ала алмыйсың бит!

Аллаһым, безне һидаятьтә алып бар, адаштырма, саташтырма, иманыбызны нык кыл. Адашкан-саташканнарга да, дошманнарыбызга да тәүфыйк-һидаять бир. Бу дөньяны иман белән үтеп, Үзең вәгъдә иткән җәннәтләреңә кереп, Пәйгамбәребезнең s мәҗлестәше булырга насыйп ит. Әмин!

*Илдус хәзрәт Фәиз,*
*«Болгар» мәчете имам-хатыйбы*

*15 декабрь вәгазе,*

*Рабигыль-әүвәл аенның 27 нче көне, һиҗри исәп буенча 1439 ел*

# Аллаһка рәхмәтле булу тиеш икәнлегеп аңламау

Бөтен галәмне юктан бар итеп, тәрбия кылучы Аллаһы Тәбәракә вә Тәгаләгә чиксез рәхмәтләребез, шөкраналарыбыз булса иде. Аллаһы Раббыбыз тарафыннан галәмнәргә рәхмәт булarak җибәрелгән сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафага S, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә күңел түрләребездән чыккан сәламнәребез, салаватларыбыз һәм һәртөрле изге догаларыбыз булса иде.

Хактыр ки, кешеләр арасындагы мөгамәләдә, берәрсе икенчесенә бүләк бирсә, я ярдәм кулын сузса, кеше рәхмәтле булырга тиеш. Яки рәхмәтне белдерү, иң азы ул – рәхмәт сүзен әйтү, хәерле теләкләр теләп дога кылу. Һәм, һичшиксез, кеше ярдәменә рәхмәтле булмау – хәерле холык гамәленнән түгел. Шуңа күрә, гадәттә, без бер-беребезгә рәхмәт әйтәбез. Балаларыбызга берәрсе бер кәнфит бирсә дә, без аларны рәхмәт әйтергә өйрәтәбез, чөнки рәхмәтсезлек ул – әдәпсезлек, әхлаксызлык күренеше.

Үсеп җиткәч, ата-аналарыбызга карата да рәхмәтебезне белдерәбез. Картайган көннәрендә ярдәм кулын сузабыз, хәлсезләнеп авырсалар – карыйбыз, дәваларга ашыгабыз. Әлбәттә, бу – аларга карата безнең рәхмәтебез. Безне саклап, көч-куәт һәм мәхәббәт салып, гомер юлында яшьлек һәм исәнлекләрен жәлләмичә безне үстергәннәре өчен без аларга мәңге рәхмәтле! Һәм ул бурычыбыз аларга кайтарып бетермәслек.

Ә киресенчә, үсеп җиткәч, ата-ананы ташлап калдыру дөрес булырмы? «Ярый, сез мине үстердегез – хәзер мин үземчә, ә сез үзегезчә

яшәгез», –дип, аларны ташлау дөресме? Әлбәттә, дөрес түгел. Бу – битарафлык, кешелексез гамәл.

### Сорау: Ә Аллаһка карата кеше рәхмәтле булырга тиешме? Һәм ни өчен?

Хактыр ки, адәм баласы шулай ук Аллаһка шөкер кылучы булырга тиеш, чөнки, динебез өйрәткәнчә, бөтен галәм һәм барча җан ияләре Аллаһ тарафыннан яратылган. Ләкин, кызганыч, үткән заманаларда һәм хәзерге вакытта кешеләрнең күбесе, Аллаһның барлыгын кабул итсәләр дә, Аңа шөкер итү хакында уйланмыйлардыр.

Коръәни-Кәримдә Иблиснең сүзләре китерелә:

ثُمَّ لَآتِيَنَّهُمْ مِنْ بَيْنِ أَيْدِيهِمْ وَمِنْ خَلْفِهِمْ وَعَنْ أَيْمَانِهِمْ وَعَنْ شَمَائِلِهِمْ وَلَا تَجِدُ أَكْثَرَهُمْ شَاكِرِينَ ﴿١٧﴾

**«Аннан соң, ант итеп әйтәмен ки, аларның алларына, арка якларына, уңнарына, сулларына төшәчәкмен. Аларның күбесен Син шөкер итүчеләр арасында тапмаячаксың».**

«Әгъраф / Пәрдә», 7:17

Коръәни-Кәримнең төрле аятьләрендә, кешенең Аллаһка шөкер кылырга тиешлеге хакында сүз бара. Һәм «ни өчен без Аңа рәхмәтле булырга тиеш?» – дип сорау биргәндә, Аллаһы Тәгалә болай дип җавап кайтара:

ذَلِكُمُ اللَّهُ رَبُّكُمْ خَالِقُ كُلِّ شَيْءٍ ﴿٦٢﴾

**«Бөтен нәрсәне юктан бар итүче Илаһ – ул Аллаһтыр...»**

«Мөэмин», 40:62

Аллаһы Тәгалә Коръәни-Кәримдә әйтә:

وَلَقَدْ كَرَّمْنَا بَنِي آدَمَ وَحَمَلْنَاهُمْ فِي الْبَرِّ وَالْبَحْرِ وَرَزَقْنَاهُمْ مِنَ الطَّيِّبَاتِ وَفَضَّلْنَاهُمْ عَلَى كَثِيرٍ مِمَّنْ خَلَقْنَا تَفْضِيلًا ﴿٧٠﴾

**«Хактыр ки, Без Адәм балаларына хөрмәт кылдык. Аларны коры җирдә дә, диңгез-суда да йөрттек. Үзләренә тәмле-татлы ризыклар бирдек, янә дә аларны яратканнарыбызның күбесеннән өстен кылдык».**

«Бәни Исраил / Ягъкуб балалары», 17:70

Башка аятьтә Аллаһ болай дип әйтә:

كَيْفَ تَكْفُرُونَ بِاللَّهِ وَكُنتُمْ أَمْوَاتًا فَأَحْيَاكُمْ ۖ ثُمَّ يُمِيتُكُمْ ثُمَّ يُحْيِيكُمْ ثُمَّ إِلَيْهِ تُرْجَعُونَ ﴿٢٨﴾

**«Ий кешеләр! Аллаһка ышанмаска ничек булдыра аласыз? Сез дөньяга килгәнче мәет идегез, Ул сезне тергезде һәм Ул сезне үтерер, вә Ул сезне Кыямәт көнне тергезер, аннары Аңа хөкемгә кайтарсыз».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:28

Күз алдыбызга китерик әле: йөз ел элек без бар идекме? Юк. Петр I заманына без шаһит булдыкмы? Юк. Йөз елдан артык булган башка заманалар вакыйгаларына без шаһитлар идекме? Юк. Ә никтер кеше үзен мәңге яшиячәк сыман хис итә! Ул заманаларда хәзерге кешелек «беркем» һәм «бернәрсә дә» түгел иде, чөнки гомумән юк идек. Ә хәзер борыннар өстә…

Кешене Бар Итүчегә, кешенең яшәвенә Теләк Белдерүче Затка карата игътибарыбызны юнәлтергә вакыт юк, рәхмәт әйтергә теләк юк!

Коръәни-Кәримнең башка сүрәсендә Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

اللَّهُ الَّذِي جَعَلَ لَكُمُ الْأَرْضَ قَرَارًا وَالسَّمَاءَ بِنَاءً وَصَوَّرَكُمْ فَأَحْسَنَ صُوَرَكُمْ وَرَزَقَكُم مِّنَ الطَّيِّبَاتِ ﴿٦٤﴾

**«Җирне сезнең өчен яшәү мәйданы иткән дә, күкне дә сезнең өчен гөмбәз итеп ясаган, сезгә гүзәл рәвеш-кыяфәт биргән дә һәм сезне саф-пакь ризыклар белән ризыкландырган да – Аллаһ».**

«Мөэмин», 40:64

Галәмдәге һәрбер әйбернең булуына, яшәвенә үз шартлары бар: өй салу өчен эшче, махсус материал кирәк; мал табу өчен көч кую, һөнәрле булу кирәк; гыйлем алу өчен уку, гыйлем эзләү, сабыр итү тиешле. Димәк, шарт – беренчедән, нәтиҗә – икенчедән.

Шулай ук бу дөньяга килгәнчегә кадәр, кешенең яшәве өчен дә шартлар тудырылган иде инде. Ул да булса җир, һава, кояш, яңгыр, көн, төн, су, үсемлек, әти, әни һ.б. Безгә алар гадәти нәрсә, ләкин шуны истә тотарга кирәктер: кеше үзе аларны бар итүче, ясаучы тугел. Без алар белән кулланабыз гына. Бу шартлар булмаса, яшәү дә булмас иде. Димәк, яшәвебезгә файдалы шартлар тудыручыга карата без рәхмәтле булырга тиешбез.

Бу хакта Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

وَمَا بِكُمْ مِنْ نِعْمَةٍ فَمِنْ اللَّهِ

**«Сезгә нинди генә нигъмәт килсә дә, барысы да Аллаһтан».**

«Нәхел / Умарта Кортлары», 16:53

Башка сүрәдә Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

اللَّهُ الَّذِي جَعَلَ لَكُمُ اللَّيْلَ لِتَسْكُنُوا فِيهِ وَالنَّهَارَ مُبْصِرًا ۚ إِنَّ اللَّهَ لَذُو فَضْلٍ عَلَى النَّاسِ وَلَٰكِنَّ أَكْثَرَ النَّاسِ لَا يَشْكُرُونَ ﴿٦١﴾

**«Сез ял итсен өчен дип, Аллаһ төнне яратты, сез гамәл кылсын өчен дип, Аллаһ көнне яратты. Һичшиксез, Аллаһ кешеләргә карата рәхимлек Кылучы, ләкин кешеләрнең күбесе шөкер итмәүчеләр, рәхмәт кылмаучылар».**

«Мөэмин», 40:61

Әйе, кызганыч, бу хаклык көнкүрешебездә күзәтелә. Ә ничек кеше Аллаһка үзенең рәхмәтен белдерә ала соң? Әлбәттә, Аны тану һәм Аның әмерләрен үтәү, һидаять юлында булуы белән.

Шөкерана кылуны өч төргә бүлеп була:

Беренчесе – барча нигъмәтнең Бер Аллаһ тарафыннан булуын күңел һәм йөрәк белән тәсдыйк кылу. Шушы хаклыкны кабул иткәч, йөрәк шөкерана белән Аллаһка юнәлә.

Икенчесе – тел белән рәхмәт әйтү. Ягъни, Аллаһ Тәгаләгә хәмедләр кылу, Аны зикерләр белән зурлау. Шулай ук, кеше аркылы килгән нигъмәт өчен дә шушы кешегә рәхмәт әйтү – ул Аллаһка шөкер кылу белән тиңдер. Бу хакта Пәйгамбәребез S болай дип әйтте: «Кем дә кем кеше биргән нигъмәткә аңа рәхмәт кылмый икән, ул Аллаһка да шөкер кылмаучыдыр»[1].

Өченчесе – гамәл белән шөкер кылу. Димәк, гомернең кадерен аңлап, безгә бирелгән нигъмәтләрне дөрес юлда кулланып, гөнаһ кылулардан баш тарту. Өстебездә булган вазифаларны җиренә җиткереп, тырышып үтәүдер.

Гомумән, шуны аңлау мөһимдер: кеше, асылында ул – кол. Дөньяны барлыкка китерүченең колы. Без бар булуыбызга да без үзебез хуҗа түгел – Аллаһ хуҗа. Без булыйк әле, дип үзебез теләк белдермәдек, булырбыз дип тә белмәдек. Аллаһ теләге белән генә бар булдык. Кайчан туарга, җирнең кайсы ягында, кайсы ата-анада туып үсәргә – беребез дә сайламадык.

Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

---

1 Имам Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан

فَابْتَغُوا عِنْدَ اللَّهِ الرِّزْقَ وَاعْبُدُوهُ وَاشْكُرُوا لَهُ إِلَيْهِ تُرْجَعُونَ

**«Бәс, ризыгыгызны Аллаһ хозурында табарсыз. Аңа гыйбадәт кылыгыз, Аңа шөкер итегез. Сез бары тик Аның янына гына кайтарылачаксыз».**

«Гәнкәбут / Үрмәкүч», 29:17

Аллаһы Тәгалә һәрберебезгә дә Үзенең рәхмәтен вә бәрәкәтен бирсә иде. Әмин.

*Рафикъ хәзрәт Йосыпов,*

*Казан Ислам университеты мөгаллиме*

*22 декабрь вәгазе,*

*Рабигыль-ахыр аеның 4 нче көне, һиҗри исәп буенча 1439 ел*

# Иманның тәме

Галәмнәрне, безне юктан бар итеп яратучы, безгә бу дөньяны бүләк итүче Раббыбыз Аллаһы Сөбханәһү вә Тәгаләгә хәмде-сәнәләребез, барча мактауларыбыз булса иде. Аның сөекле бәндәсе, ахырзаман пәйгамбәре Мөхәммәд Мостафага s салават-шәрифләребез булса иде. Мөхтәрәм дин кардәшләребез, әс-сәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәракәтүһ!

Әнәс ибне Мәликтән риваять кылына, Пәйгамбәребез s үзеннән артта дөягә атланып баручы Мөгазгә d әйткән: «Әй Мөгаз!» Ул: «Әйе, Расүлүллаһ, тыңлыйм», – дип җавап биргән. Расүлүллаһ s яңадан: «Әй Мөгаз!» – ди. Мөгаз d : «Әйе, Расүлүллаһ, тыңлыйм», – дип җавап бирә. Расүлүллаһ s яңадан: «Әй Мөгаз!» – ди. Мөгаз d : «Әйе, Расүлүллаһ, тыңлыйм», – дип җавап бирә. Өченче тапкырыннан соң Расүлүллаһ s әйткән: «Чын күңелеңнән: «Аллаһтан башка гыйбадәткә лаеклы зат юк, Мөхәммәд – Аның илчесе», – дип шәһадәт кылучыны Аллаһы Тәгалә җәһәннәм утына хәрам кылыр». Ягъни, чын күңеленнән иман китергән кешене Аллаһы Тәгалә җәһәннәм утында яндырудан тыя.

Мөгаз d сораган: «Кешеләргә бу хәбәрне җиткереп, бәлкем аларны шатландырыргадыр?» Расүлүллаһ s : «Әгәр аны әйтсәң, алар шуның белән генә канәгатьләнер һәм изге гамәлләр эшләүдән туктар», – диде. Мөгаз d бу хәдисне гомеренең азагында гына, аны яшереп калудан гөнаһка батудан куркып кына әйтә.[1]

Монда Пәйгамбәребез s иман кәлимәсен әйткән кешенең җәннәткә керүе турында хәбәр бирә. Әмма бер нәрсәгә игътибар итик: монда сүз бу

[1] Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан

кәлимәне чын күңеленнән әйткән кешенең генә җәннәткә керүе турында бара. Безнең каршыда, әлбәттә, кешенең телдән әйтүе дә җитә. Әмма Аллаһ каршында ихлас күңелдән булганнары гына кабул була. Кешенең әйткән сүзе ихлас булсын өчен аның иманы ныклы булырга тиеш.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

قَالَتِ الْأَعْرَابُ آمَنَّا ۖ قُل لَّمْ تُؤْمِنُوا وَلَٰكِن قُولُوا أَسْلَمْنَا وَلَمَّا يَدْخُلِ الْإِيمَانُ فِي قُلُوبِكُمْ ۖ وَإِن تُطِيعُوا اللَّهَ وَرَسُولَهُ لَا يَلِتْكُم مِّنْ أَعْمَالِكُمْ شَيْئًا ۚ إِنَّ اللَّهَ غَفُورٌ رَّحِيمٌ ﴿١٤﴾

**«Бәдәви гарәпләре: «Иман китердек», – дип әйтте. Әйт син аларга: «Сез иман китермәдегез, ләкин: «Мөселманнардан куркып, яки файдаланып көн күрү өчен, тыштан гына ислам динен кабул иттек», – дип әйтегез. Әле күңелегезгә иманның әсәре дә кергәне юк, иман китерергә ниятегез дә юк, имансыз гына мөселман булып йөрергә теләгәнсез, ягъни мөселманнар белән гамәл кылып, аларны алдарга теләгәнсез. Әгәр, чынлап та иман китереп, ихлас күңел белән Аллаһка һәм аның Расүленә буйсынсагыз, мөселманнар белән кылган гамәлләрегезгә һич кимчелек ирешмәс иде, савабы, әлбәттә, югалмас иде. Чынлыкта, Аллаһ Ярлыкаучы һәм Рәхмәт итүчедер»**

«Хүҗүрат / Бүлмәләр», 49:14

Бу аятьтән күренгәнчә, телдән иман китерү генә әле бер нәрсә дә түгел, хәтта без иман китергән кешене мөэмин дип әйтсәк тә. Әлбәттә, бер кеше телдән иман китерсә, ул мөселман була. Бу – иманның шарты, әмма без кешенең күңеленә керә алмыйбыз. Шуңа күрә дә, үзләрен мөселман дип йөргән кайберәүләрнең диннән чыгуы, асылда, аның дингә кереп бетмәве, аның күңеленә иманның ныклап урнашмавы аркасында

була. Димәк, чын мөселман булуның чын мөселманнар үзләре генә аңлый торган бер билгесе бар.

Без беләбез, бөтен нәрсәнең дә тәме бар: ризыкның, суның, хәтта тимернең дә… Шуның кебек, иманның да тәме бар һәм иманның тәмен бер татыган кешене иманнан аеру мөмкин түгел. Пәйгамбәребез S әйткән: «Иманның тәмен шушы өч сыйфатка ия булган кеше генә тоя: кем Аллаһны һәм Аның илчесен башка барлык нәрсәләрдән дә ныграк ярата, кемне генә яратса да фәкать Аллаһ өчен генә ярата һәм ул, утка ыргытылырга теләмәгән кебек, яңадан җаһилияткә[1] кайтырга теләми»[2]

Беренче мөселманнар иманның тәмен татыган. Шуңа күрә алар диннәрендә нык булган, дөнья тәменә алданмаганнар. Иманның тәмен татуның беренче билгесе булып Аллаһы Тәгаләне һәм Аның илчесен башка барлык нәрсәләрдән дә ныграк ярату тора. Бу – әүвәлге мөселманнарга хас сыйфат. Беренче мөселманнар Аллаһны һәм Аның Расүлен S бөтен нәрсәдән дә ныграк яраткан. Шуңа күрә аларның һәрберсе Расүлүллаһ S аның үзен генә ярата дип уйлаган. Хәйбар сугышында мөселманнар ныгытманы (крепостьны) камап ала һәм берничек тә эчкә үтеп кереп яһүдләрне җиңә алмыйлар. Шунда бер кичне Расүлүллаһ S: «Мин, һичшиксез, бу байракны Аллаһны һәм Аның Илчесен яраткан һәм аның үзен дә Аллаһ һәм Аның илчесе яраткан кешегә бирәм», – дигән. Иртән кешеләр һәрберсе байракны Расүлүллаһ үзенә бирер дип уйлаган. Расүлүллаһ S байракны Гали ибне Әбү Талибка бирә һәм ул көнне мөселманнар җиңә. Кешеләрнең һәрберсе байракны үзләренә бирер дип уйлауларына килгәндә исә, аларның һәркайсы Пәйгамбәрне S шулкадәр ярата, башкалар да Пәйгамбәрне S шулай ук нык ярата алыр дип уйламый һәм, шул сәбәпле, Пәйгамбәр S дә аны гына шулай нык яратадыр дип уйлый.

---

[1] Исламгача дәвер – Ред.

[2] Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан

Бервакыт Әбү Бәкер d кешеләргә беренче тапкыр ачык рәвештә ислам диненә чакырып мөрәҗәгать итә һәм ул ислам диненә ачык рәвештә беренче дәгъват кылучы була. Бу – шундый көтелмәгән хәл була ки, Мәккә мәҗүсиләре, үзләре дә сизмәстән, Пәйгамбәребезгә s, Әбү Бәкергә d һәм башка мөселманнарга ташлана һәм аларны бик каты кыйныйлар. Бәнү Тәйем кешеләре тәнендә яшәү билгесе булмаган Әбү Бәкерне d өенә алып кайта һәм, киредән, ярсыган хәлдә Әл-Хәрәм мәчетенә китәләр. Алар: «Әгәр Әбү Бәкер үлсә, аны кыйнаган Гутба бин Рабиганы, һичшиксез, үтерәбез», – дип ант итә. Үлем хәлендә булган Әбү Бәкер аңына килә һәм аның беренче сүзләре нәрсә була? Аның беренче сүзләре «Аллаһ Расүленең s хәле ничек?» дигән сүзләр була. Менә, чын ярату ничек булырга тиеш!

Гамр ибне әл-Гастан риваять кылына: “Расүлүллаһ s иң начар кешеләргә дә ачык йөз күрсәтеп яхшы сүзләр әйткән, ул, шулай итеп, аларның мәхәббәтләрен яулаган. Миңа да якты йөз күрсәтеп матур итеп дәшә иде, хәтта мин үземне кавемнең иң яхшысы дип уйлый идем. Мин шунда: «Йә Расүлүллаһ, мин яхшыракмы, әллә Әбү Бәкерме?» – дип сорадым. Ул әйтте: «Әбү Бәкер». Мин тагын сорадым: «Йә Расүлүллаһ, мин яхшыракмы, әллә Гомәрме?». Ул әйтте: «Гомәр». Мин тагын сорадым: «Йә Расүлүллаһ, мин яхшыракмы, әллә Госманмы?». Ул: «Госман», – дип әйтте Мин Пәйгамбәребезнең s кыска җавапларында хаклыкны тойдым һәм миңа үземнең сорауларымны биргәнем өчен оят булып китте»[1].

Аллаһны һәм Аның Расүлен s яратуның ихласлыгы, сафлыгы әүвәлге мөселманнарны югары дәрәҗәләргә күтәрә, башка халыкларның ислам динен кабул итүләренә сәбәп була. Алар, бүгенге мөселманнардан аермалы буларак, бер-берсенең гамәл-гыйбадәтен тикшереп, кимчелек эзләп йөрмәгән, бәлки, белгәннәре белән гамәл кылганнар, белмәгәннәрен

[1] Имам Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан

араларында булган белгән кешеләрдән сораганнар һәм алардан килгән җавапка риза булганнар, дәлил таптырмаганнар.

Хәзер «саф ислам», «чын мөселманнар» дип сөйләүчеләр күбәйде. Бу бигрәк тә яшьләргә кагыла. Алар: «Мәзһәб дөрес түгел, безнең ата-бабалар динне дөрес тотмаган, дин традицион була алмый», – дип әйтергә ярата. Бүгенге әхлак, бүгенге үзара мөнәсәбәт белән безгәме соң аларны тикшерү?! Тарихка аз гына күз салсак, бабаларыбызның иманы көчлерәк булганмы, әллә безнеке көчлерәкме икәнлеген ачык күрербез.

Кайбер риваятьләргә караганда, безнең төбәкләргә ислам дине сахабәләр дәгъвәте белән тарала башлаган. Ничек кенә булса да, ул 922 нче елда Болгар дәүләтенең дәүләт дине буларак кабул ителә. Шул вакытлардан ук Болгар ханы, хәлифәттән килгән илчеләр, галимнәр белән бәхәскә кереп, дин мәсьәләләрен тикшерә, алар алып килгән шәфигый мәзһәбен кабул итмичә, хәнәфи мәзһәбен саклап кала. Бу факт ул чорда ук хан һәм аның әйләнәсендәге галимнәрнең хәлифәт галимнәре дәрәҗәсендәге зур белемгә ия булуларын күрсәтә. Болгар бабаларыбызның иманнары куәтле, ныклы булулары сәбәпле, аларны басып алган мәҗүси татар-монголлар да тиз арада ислам динен кабул итә һәм Идел буенда бөтен Европага тәэсир итәрлек дәрәҗәсе булган Алтын Урда ислам дәүләте барлыкка килә. Алар да бит безнең бабаларыбыз. Бәлки, бу чорда динебез зәгыйфьләнгәндер. Ул чорның тарихына күз салыйк.

Урта гасырларда Рим-католик чиркәвеннән Вильгельм Де-Брук исемле бер француз католик-миссионер үзләренең диннәренә өндәргә дип Балтыйк диңгезеннән Тын океанга кадәр җирне уза. Ул, үзенең максатына ирешә алмагач, безнең бабаларыбыз турында Рим папасына: «Бу болгарлар Мөхәммәднең S кануннарына башка бөтен халыкка караганда да ныграк ябышкан», – дип хисап бирә. Димәк, безнең бабаларыбыз иманның түмен тойган булган. Бу шулай булмаса, ислам дине, нинди генә

көчләүләр, чукындырулар булуга карамастан, бүгенге көнгә кадәр сакланып калмас иде.

Бик азларыбыз белә торгандыр: Алтын Урда ханы – Чыңгыз ханның оныгы – Бәркә хан Чыңгыз хан нәселеннән беренче булып ислам динен кабул итә, халифәтне канга батырган Хулагу җитәкчелегендәге монгол гаскәрләрен җиңә, шуннан соң Бей-барс белән берләшеп ислам дөньясының сакланып калуына, мөселманнарның дөнья тарихында яңадан бөек дәрәҗәләргә ирешүенә сәбәп була. Тарихыбызны белмәвебез безне башкалар алдында ким халык итеп тоярга мәҗбүр итә.

1263 нче елда мең кешедән торган Алтын Урда илчелеге Мисыр иленә килә. Безнең бабаларыбызны бөтен Каһирә халкы зур хөрмәт белән каршы ала. Бу вакыйга турында гарәп тарихчысы Ән-Нувәйри түбәндәгеләрне язып калдыра: «Каһирәдә һәм Мисырда бу илчелекне каршыларга чыкмаган бер генә кеше дә калмады. Бу көн иң бөек көн булды». Шуннан соң ике йөз ел дәвамында Сарай белән Каһирә иллешәр кешелек илчеләр белән аралашып тора.

Ул вакытларда безнең халык бөтен ислам дөньясы өчен кадерле кешеләр булып, ислам дөньясын яклаучы һәм саклаучылар буларак кабул ителгән. Бүген исә безне дөньяда фәкать урыс буларак кына беләләр.

Традицион ислам дигән сүздән куркырга кирәк түгел. Аны ислам дөньясында зур урын, дәрәҗә тоткан, дөньяда беренче булып Коръәнне типографик ысул белән бастырган бабаларыбыздан калган ислам динен тоту рәвеше итеп күз алдында тотарга кирәк. Ә диннең сафлыгына килгәндә исә, шулай ук, башка халыкларның дин тоту рәвеше белән чагыштырсак, бүгенге көндә дә башка халыклардан динебезнең сафрак булуын күрербез. Советлар илендә (дин тыелган, хәтта гарәп язуы да тыелган вакытта) безнең халык динен ташламады, кириллица белән язып булса да Коръәнне өйрәнде, ятлады, авылларда мулла бетмәде. Кириллица белән язуларны бүген генә тәнкыйтьләргә була, ә элек ул динебезне са-

клауга бер сәбәп булды. Карагыз: унбиш-егерме ел эчендә мәчетләр саны бер Татарстанда гына да мең дүрт йөздән артып китте. Аны бит дәүләт салмады, ә халык салды. Димәк, халкыбызда диннең тәмен югалтмаганнар, ул әле дә бар.

Иманның тәмен алда әйтелгән өч сыйфатка ия булганнар гына тоя ала: «Кем Аллаһны һәм Аның илчесен башка барлык нәрсәләрдән дә ныграк ярата, кем нәрсәне генә яратса да фәкать Аллаһ өчен генә ярата һәм ул, утка ыргытылырга теләмәгән кебек, яңадан җаһилиятькә кайтырга теләми»[1].

Пәйгамбәребез ﷺ болай дигән: «Мине үзенең ата-анасыннан, баласыннан һәм бөтен кешеләрдән дә ныграк яратмый торып сезнең берегез дә иман китерүчеләрдән булмас»[2].

Аллаһы Тәгалә әйтә:

فَلَا وَرَبِّكَ لَا يُؤْمِنُونَ حَتَّىٰ يُحَكِّمُوكَ فِيمَا شَجَرَ بَيْنَهُمْ ثُمَّ لَا يَجِدُوا فِي أَنفُسِهِمْ حَرَجًا مِّمَّا قَضَيْتَ وَيُسَلِّمُوا تَسْلِيمًا ﴿٦٥﴾

**«Раббың исеме белән ант итеп әйтәм, мөселманнар үзара бәхәсләшкән эшләре турысында: «Ий Мөхәммәд! Синнән хөкем иттермичә чын иманлы була алмаслар, алар синең хөкемеңә күңелләрендә шик калдырмаслар һәм синең хөкемеңә чын күңелдән риза булып мөсәлләм булырлар – әнә шул эшне эшләгәнгә чаклы камил мөэмин булмаслар».**

«Нисә / Хатыннар», 4:65

Бүген арабызда иманның тәмен татучылар бар әле, дип әйтсәк тә, кешеләрнең күпчелеге дөньялыкка баткан. Алар Аллаһы Тәгаләне телдән «Яратам» дип әйтсә дә, чынлыкта, иман аларның телләреннән ерак кит-

1 Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан

2 Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан

ми. Алда мисал итеп китерелгән аятьтә әйтелгәнчә, иман аларның кулларында дөнья алып барыр өчен кирәк булган уенчык, корал кебек кенә.

Аллаһы Тәгалә Коръән-Кәримдә кисәтә:

قُلْ إِن كَانَ آبَاؤُكُمْ وَأَبْنَاؤُكُمْ وَإِخْوَانُكُمْ وَأَزْوَاجُكُمْ وَعَشِيرَتُكُمْ وَأَمْوَالٌ اقْتَرَفْتُمُوهَا وَتِجَارَةٌ تَخْشَوْنَ كَسَادَهَا وَمَسَاكِنُ تَرْضَوْنَهَا أَحَبَّ إِلَيْكُم مِّنَ اللَّهِ وَرَسُولِهِ وَجِهَادٍ فِي سَبِيلِهِ فَتَرَبَّصُوا حَتَّىٰ يَأْتِيَ اللَّهُ بِأَمْرِهِ ۗ وَاللَّهُ لَا يَهْدِي الْقَوْمَ الْفَاسِقِينَ ﴿٢٤﴾

**«Ий Мөхәммәд, әйт: «Ий мөэминнәр! Әгәр сезнең аталарыгыз, кардәшләрегез, хатыннарыгыз, кәсеп иткән малларыгыз, арзан булудан курыккан сәүдәләрегез вә разый булып торган йортларыгыз Аллаһтан вә Аның Расүленнән һәм Аллаһ юлында сугышудан сөеклерәк булса, Аллаһтан газап килгәнне көтегез! Аллаһ, Аның хөкемнәренә хилафлык кылучы фәсыйкларны, әлбәттә, туры юлга салмас».**

«Тәүбә», 9:24

Кисәтеп кенә калмый, андый халыкка Аллаһы Тәгалә чик куя һәм шул чиккә җиткәч аларны башка халык белән алыштыра. Аллаһы Тәгалә әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا مَن يَرْتَدَّ مِنكُمْ عَن دِينِهِ فَسَوْفَ يَأْتِي اللَّهُ بِقَوْمٍ يُحِبُّهُمْ وَيُحِبُّونَهُ أَذِلَّةٍ عَلَى الْمُؤْمِنِينَ أَعِزَّةٍ عَلَى الْكَافِرِينَ يُجَاهِدُونَ فِي سَبِيلِ اللَّهِ وَلَا يَخَافُونَ لَوْمَةَ لَائِمٍ ۚ ذَٰلِكَ فَضْلُ اللَّهِ يُؤْتِيهِ مَن يَشَاءُ ۚ وَاللَّهُ وَاسِعٌ عَلِيمٌ ﴿٥٤﴾

**«Ий мөэминнәр! Әгәр сезнең арагыздан берәү хак динен ташлап мөртәт булса, Аллаһ алар урынына үзенә сөекле һәм Аллаһны сөюче кавемне тиздән китерер, алар мөэминнәргә йомшак күңелле, иман китермәүчеләргә каты күңелле булыр. Алар Аллаһ юлында көрәшер, ислам динен куәтләр өчен бөтен көчләрен куяр”.**

«Мәидә / Аш Яулыгы», 5:54

Без бүген иманның тәме булуын һәм иманның тәмен татыган мөселманнарның нинди дәрәҗәләргә ирешүләрен карап киттек. Ибне Габбас болай дип әйткән: «Аллаһ өчен ярат, Аллаһ өчен нәфрәтлән, Аллаһ өчен дуслаш, Аллаһ өчен дошманлаш, фәкать шулай гына Аллаһка якынаюга ирешеп була. Шулай булмаганда кол күп намаз укып һәм ураза тотып кына иманның тәмен татуга ирешә алмас».

Фудаил ибн Гыйад болай дип әйткән: «Бу дөньяда азга канәгать булмый торып, сезнең калебләрегез иманның тәмен татымас».

Аллаһы Тәгалә барчабызга да иманның тәмен тоеп, ике дөнья бәхетсәгадәтенә ирешүне насыйп итсен.

*Рөстәм хәзрәт Шәйхевәлиев,*

*Яр Чаллы шәһәре «Ак мәчет» мәдрәсәсе директоры*

*29 декабрь вәгазе,*

*Рабигыль-ахыр аеның 11 нче көне, һиҗри исәп буенча 1439 ел*

# Син әзерме?

Әлхәмдү лилләһи раббил гәәләмиин, вәс-саләәтү вәс-сәләәмү гәләә расүлинәә Мүхәммәд вә гәләә әәлиһи вә сахбиһи әҗмәгыйн. Безне юктан бар итеп бу дөньяга сынау өчен җибәргән, Үзенең иксез-чиксез нигъмәтләре белән нигъмәтләндергән бөек Раббыбыз Аллаһы Сөбханәһү вә Тәгаләгә мактау булсын, шушы дөнья мәдрәсәсенә олуг укытучы булып килгән Аллаһ илчеләренең соңгысы – пәйгамбәребез Мөхәммәдкә s саләт вә сәламнәребез ирешсен. Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтүллаһи вә бәрәкәтүһ!

Сөекле Пәйгамбәребез s бер хәдис шәрифендә шулай дип боера: «Дөньяда бер чит кеше, яки бер юлчы кебек яшә».

Бу хәдисне риваять иткән ибн Гомәр дә d : «Кич җиткәч – таң атканын, таң аткач та – кич җиткәнен көтмә, авыруың өчен – сәламәтлегеңнән, үлемең өчен дә тормышыңнан файдалан, вакытыңны бушка үткәрмә», – дип әйтә иде. Димәк, син юлчысың, кардәшем, һәркем кебек китеп барырсың, үлем һәм хисаптан котылу юк, никадәр яшәсәң дә, беркөнне син дә үләчәксең, кемне генә яратсаң да – беркөнне аларны калдырырсың, нинди генә гамәл кылсаң да, бер көн килер – кылган нәрсәңнең нәтиҗәсен күрерсең. Хисап вакыты якынлашыр – һәркем киткән кебек үк без дә китәрбез, китмичә калыр өчен көчебез дә, мөмкинлегебез дә юк!

Бу сәбәптән, санаулы көннәребез, санаулы сулышларыбыз беткәнче, төсләребез үзгәргәнче, мәчет ташына яшел япма белән яткырылганчы – мәңгелеккә барачак урыныбыз өчен ризыгыбызны әзерлик! Ризыкларның иң хәерлесе исә – тәкъвалык, ягъни Аллаһка ни дәрәҗәдә буйсынуыбыз.

Әй газиз кардәшем! Арабыздан китеп, һәркөнне кабер юрганы белән күмелгән кешеләрнең хәлләреннән гыйбрәтләник. Бәлки кәфенлек күптәннән әзерләнгәндер? Барачак җир – туфрактыр? Булачак өй – кабердер? Хисап бирәчәк урын – мәхшәр мәйданыдыр? Соңгы тукталыш – җәннәт яки җәһәннәмдер? Син исә җәннәткә лаеклы булырга тырыш!

Мөселман кардәшем! Малларына ышанып, Аллаһны оныткан күпме бәндәләр булды? Кайда соң алар хәзер, ул гөнаһ кылып, көлеп йөргән күзләр? Кайда соң ул яшьлекләренә алданып, ахирәткә күзләре сукырайган бәндәләр? Вакыт аларны эретмәдеме? Ләззәтле ризыклар ашаганнан соң кортларга азык булмадылармы? Маллары, балалары, дуслары аларны үлемнән коткара алдымы?

Аллаһы Сөбханәһү вә Тәгалә Үзенең китабы Коръәни Кәримдә әйтә:

أَيْنَمَا تَكُونُواْ يُدْرِككُّمُ الْمَوْتُ وَلَوْ كُنتُمْ فِي بُرُوجٍ مُّشَيَّدَةٍ ﴿٧٨﴾

**«Кай урында булсагыз да, сезгә үлем ирешер, әгәр күккә терәлгән, бик таза төзелгән кыл эчендә булсагыз да».**

«Нисә / Хатыннар», 4:78

Шәрәфле кардәшем! Бу кунак дөньясына килгән һәркем моннан китте. Чиратлары җиткәннәре бер-бер артлы соңгы юлга китәләр, чират безгә дә җитәчәк, бу бик ерак түгел, күз белән каш арасында. Үлем фәрештәсе юлда, вакыт үткән саен безгә якыная бара һәм көннәрдән бер көнне безнең яныбызга килеп, Аллаһы Сөбханәһү вә Тәгалә безгә әманәт итеп биргән җаныбызны алыр. Син моңа әзерме? Синең җаның чистамы? Син Аллаһы Тәгаләгә җаныңны чиста килеш тапшыра алырсыңмы?

Аллаһы Сөбханәһү вә Тәгалә Коръәни Кәримдә әйтә:

كُلُّ نَفْسٍ ذَائِقَةُ الْمَوْتِ ثُمَّ إِلَيْنَا تُرْجَعُونَ ﴿٥٧﴾

**«Һәрбер җан иясе үлем ачысын татыячак. Аннары да Безгә кайтарылырсыз».**

«Гәнкәбут / Үрмәкүч», 29:57

Бу дөнья – бер күпер. Бу күпернең башы – бишек, ахыры исә – кабердер. Моннан соң мәңгелек тормыш башлана. Бу юл дөнья исемле күпер өстеннән үтә, шуңа күрә без монда ахирәтебез өчен әзерлек ясарга мәҗбүр икәнлегебезне беркайчан да онытмыйк.

Башыңны ике кулың арасына куеп, уйлаганың бармы? Ни өчен бу дөньяга килдең? Ни өчен яшисең? Үлемнән соң нәрсә көтә? Гомереңне нәрсәгә әрәм иттең? Иртәгә синнән болар хакында сорасалар, нәрсә дип җавап бирерсең? Аллаһ каршында коллык вазифаңны җиренә җиткереп үтисеңме? Һәркөн биш вакыт намазыңны укыйсыңмы? Югыйсә, җомгадан-җомгага, бәйрәмнән-бәйрәмгә генә намазыңны үтисеңме? Уразаңны тотасыңмы? Әллә Рамазан ае кергәч, ашказаның авырта башлыймы? Зәкәтеңне түлисеңме? Әллә үзеңне җәһәннәмгә утын итеп әзерлисеңме? Гөнаһларыңа тәүбә иттеңме? Яисә син бу сорауларга мөселманнар сөйләмәгән сүзләр белән җавап бирмәкче буласыңмы? Син бөек хисап көнендә Аллаһы Тәгалә каршында үзеңнең кылган гамәлләрең өчен җавап бирергә әзерме?

Аллаһы Сөбханәһү вә Тәгалә үзенең китабы Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَمَا خَلَقْتُ الْجِنَّ وَالْإِنسَ إِلَّا لِيَعْبُدُونِ ﴿٥٦﴾

**«Без кешеләрне һәм җеннәрне гыйбадәт итсеннәр өчен яраттык».**

«Зарият / Таратучы», 51:56

Шулай булгач, син, мөэмин-мөселман кардәшем, Аллаһка коллык өчен яратылдың, гыйбадәт кылыр өчен яратылдың.

Расүлебез S : «Акыллы кеше – мәңгелек ахирәте өчен тырышкан кеше, кылган гамәлләренә фикерләп хисап ясар; ахмак исә – нәфес һәм теләкләренә иярер». Бу үлчәүгә күрә син акыллымы? Юкмы? Нәтиҗә яса!

Шулай булгач, газиз кардәшем, дөнья безне алдамасын. Аллаһ каршында булган вазифаларны оныттырмасын, безне һәм балаларыбызны, оныкларыбызны бөек динебез Исламнан ерагайтмасын. Аллаһ һәм Расүлуллаһ S мәхәббәтен, Коръән нурын күңелләребездән чыгармасын, вакыт белән үзгәреп юк булган дөнья зиннәте безне мәңгелек Фирдәвес җәннәтеннән мәхрүм итмәсен.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

أَفَلا تَذَكَّرُونَ

**«Һаман уйлап – фикерләмәсләрме?»**

«Нәхел / Умарта Кортлары», 16:17

أَفَلَا تَعْقِلُونَ

**«Һаман акыллыланмас释лармы?»**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:10

Шуңа күрә уйлап, фикерләп, Аллаһы Тәгалә биргән акылны Ул Үзе күрсәткән туры юлда файдаланып, хисап бирергә әзер булып тор!

*Рөстәм хәзрәт Хәйбуллин,*

*Буа районы «Мәлик» мәчете имам-хатыйбы*

*5 гыйнвар вәгазе,*

*Рабигыль-ахыр аеның 18 нче көне, һиҗри исәп буенча 1439 ел*

# Көнчелек турында

Ислам диненең төп максаты – кешедә күркәм сыйфатлар тәрбияләү. Шуңа күрә дә Аллаһы Тәгалә безгә шәригать кануннарын иңдергән. Әгәр без шушы илаһи кануннар буенча яшәсәк, фани дөньядагы һәм ахирәттәге тормыш бәхетле, тыныч, матур булачак.

Кешене бәхетсез итә торган сыйфатларның берсе – көнчелек. Бу сыйфат аркасында кеше үзенә һәм башкаларга зыян китерә. Белгәнебезчә, дөньяда беренче гөнаһ шул сыйфат аркасында эшләнде. Адәмнең а улы Кабил көнләшеп, үзенең бертуган кардәшен Һабилне үтерде.

Пәйгамбәребез s әйткән: «Ут утынны яндырган кебек, көнчелек изге гамәлләрне юкка чыгара»[1]. 100 елдан артык яшәгән бер хикмәтле кешедән: «Озак яшәүнең сере нәрсәдә?» – дип сораганнар. «Аллаһка шөкер кылып, көнчелек сыйфатыннан ерак булуда», – дип җавап кайтарган.

Икенче хәдис-шәрифтә болай дип әйтелгән: «Бер-берегездән көнләшмәгез, бер-берегезне алдамагыз, бер-берегезгә нәфрәтләнмәгез, артыгыз белән борылмагыз, кардәшләр булыгыз. Дөреслектә, мөселман икенче мөселманга кардәштер. Ул аны рәнҗетергә, ярдәмсез калдырырга, ялганда гаепләргә тиеш түгел. Аның намусына, малына һәм тормышына кул сузу – хәрамдыр. Тәкъвалык менә монда!» – дип әйтеп, Аллаһның Расүле өч тапкыр калебенә төртеп күрсәткән дә әйткән: «Әгәр берәү мөселман кардәшен кимсетсә, рәнҗетсә, аңа бу гамәл җитәрлек зарар булыр»[2].

---

1 Имам Әбү Давыд һәм имам Бәйһәкый хәдисләр җыентыгыннан

2 Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан

Динебез тарафынннан рөхсәт ителгән көнчелек бар, аны башкача ак көнчелек дип әйтәләр. Мондый көнчелек кешене изгелеккә этәрә, рухи яктан үстерә, камилләштерә. Бу хакта Пәйгамбәребез S болай дип әйткән: «Ике төрле кешедән генә көнләшергә ярый: беренчесе – Аллаһы Тәгалә аңа Коръән байлыгын биргән һәм шуның белән көн-төн мәшгуль булган кеше, икенчесе – Аллаһы Тәгалә аңа күп нигъмәтләр биргән һәм ул шул байлыгын изге юлда сарыф иткән кеше»[1].

Түбәндәге хәдисне истән чыгармаска кирәк!

Бер көнне сөекле Пәйгамбәребез S үзенең сәхабәләренә шундый сорау бирде: «Кем ул банкрот?» – диде. Сәхабәләр: «Безнең аңлавыбызча, бу сүз товарның, акчаның юклыгын аңлата», – дип җавап кайтардылар. Аллаһның Расүле S: «Минем өммәтемнән булган банкрот кеше шул булыр – кем Кыямәт көнендә укылган намазлары, тоткан уразалары, бирелгән сәдакалары белән килер, ләкин шуның белән бергә ул кемнедер орышкан, кемнедер хур иткән, хаксыз кемнеңдер малын кулланган, кемнеңдер канын түккән, кемгәдер суккан. Һәм шул начар гамәлләр өчен аңа үзенең изге гамәлләре белән түләргә кирәк булачак. Әгәр аның саваплары бетсә, ул рәнҗетелгән кешеләрнең гөнаһларын үзенә алачак. Шуннан соң ул җәһәннәмгә ташланачак», – дип әйтте[2].

Көнчелек сыйфатыннан пакьләнер өчен нишләргә кирәк?

– Дини гыйлемнәрне арттырырга;

– Аллаһның чиксез рәхмәте турында уйланырга;

– Изге, күркәм холыклы кешеләр белән дус булырга кирәк.

Аллаһы Раббыбыз Коръәндә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُواْ اتَّقُواْ اللّهَ وَكُونُواْ مَعَ الصَّادِقِينَ ﴿١١٩﴾

---

1 Имам Бохари һәм имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан

2 Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан

**«Әй иман китергән кешеләр, Аллаһ каршысында гөнаһ кылудан куркыгыз һәм тугры кешеләр белән бергә булыгыз»**

«Тәүбә», 9:119

Борынгылар әйткәннәр: «Яхшы белән юлдаш булсаң, җитәрсең син морадка, яман белән юлдаш булсаң, калырсың син оятка».

Аллаһы Тәгалә һәркайсыбызга үзебездә күркәм сыйфатлар тәрбияләргә ярдәм итсә иде.

*Нияз хәзрәт Сабиров,*

*ТҖ МДНнең дәгъвәт бүлегенең җитәкчесе ,*

*Апанай мәчете имам-хатыйбы*

# Редакция хаты

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтүллаһи вә бәракәтүһ!

Хөрмәтле имамнар, укучыларыбыз! Журналыбыз редакциясе сезне хезмәттәшлек итәргә чакыра.

Пәйгамбәребез s хәдисләрендә мөселманнарга булган гыйлемнәре белән уртаклашуның зарурлыгын әйтеп калдыра. Шулай ук имам Әхмәд: «Белем байлыкка охшаган: байлык күбрәк булган саен, аннан күбрәк зәкәт түләнә», – дип әйткән. Имам Гали d әйткән: «Белүче үз гыйлемнәре белән бүлешә барган саен, аңа яңа гыйлем чыганаклары ачыла бара, алар үсә, ныгый һәм аныклана. Башкаларны укытканда ул элек алган белемен ныгыта һәм яңасын ала».

«Шура» журналында вәгазьләрегез, мәкаләләрегез, әдәби әсәрләрегезне урнаштырырга теләсәгез, «Сорау-җавап» рубрикасында кызыксындырган сорауларыгызга җавап аласыгыз килсә, «Әңгәмә» сәхифәсе өчен интервью бирергә, редакция хезмәткәрләренә киңәшләрегезне җиткерергә теләгегез булса, **shura@huzur.ru** электрон почтасына яки 420111 Казан шәһәре, Лобачевский урамы 6/27 («Шура» журналына» дип) адресына хатлар юллый, **+7 (843) 598-09-42** номерына шалтырата аласыз.

Редакциягә килгән язмалар үзгәртелә ала, бастырылмаска мөмкин һәм кире кайтарылмый.



# Сорау – җавап

## 1. Сәҗдә вакытында ике аяк табаны да җирдән аерылса, намаз бозыламы?

**Җавап:** бу сорауга Мөхәммәд Әмин ибн Габидин үз китабында аерым бер бүлек багышлый. Ул бу мәсьәләгә карата өч фикер барлыгын әйтеп китә. Шуларның берсе буенча, сәҗдә вакытында аяк бармакларының җиргә тиеп торуы фарыз, икенчесе буенча – вәҗиб, ә өченчесе буенча – сөннәт. Ибн Габидин: «Күпләр бу сорауны дөрес аңламый. Дөреслектә фикер каршылыклары сәҗдә вакытында аякларның идәнгә тиюе шарт булып тору-тормавында», – дип әйткән. Ибн Габидин үзе сәҗдә вакытында аякларның идәнгә тиюе вәҗиб дип саный («Радд әл-мохтар»).

Ә сезнең соравыгызга килгәндә, сүз сәҗдә вакытында аякларның бер мизгелгә генә аерылуы турында бара. Ягъни сәҗдә кылганда бер мизгелгә генә аяк бармакларын җирдән аерган кешенең намазы бозылырмы? Һичшиксез, сәҗдә вакытында аяк бармакларын идәннән аерып алу намазны бозмый. Хәтта кайбер галимнәр, намаз укучы кеше сәҗдә вакытында аяк табаннарын идәнгә гомумән тидермәгән очракта да, намаз бозылмаячак, дигән фикердә булган. Әмма бу мәсьәләдә саклык принцибына нигезләнү дөресрәк булыр, чөнки мөселманга намаз кебек зур гыйбадәтне, аның хәтта кечкенә өлешләрен дә намус белән үтәп, тиешенчә кылу зарур. Ә Аллаһка яхшырак билгеле.

*Татарстан Республикасы мөфтие*

*Камил хәзрәт Сәмигуллин*

## 2. Бурычны кичерү зәкәт түләүгә санала аламы?

### Сорау: арендага алучыларымның берсе мохтаҗ һәм фатир өчен һәрвакыт та түли алмый. Ул түләмәгән аренда акчалары минем өчен зәкәт түләү булып санала аламы?

**Җавап:** зәкәт – ул мөлкәтебезнең бер өлешен Аллаһ Тәгалә тарафыннан билгеләнгән аерым кешеләргә тапшырудан гыйбарәт, милек белән кылына торган гыйбадәт. Зәкәтнең билгеләмәсеннән күренгәнчә, аның фарыз шарты булып фәкыйрь кешегә мал-мөлкәткә ия булу хокуклары тапшырылуы тора («Әл-Мухит Әл-Борхани»). Аренда өчен түләнмәгән акча бурыч булып тора. Ягъни бу очракта арендатор арендага бирүчегә бурычлы. Бурычны кичерү исә ия булу хокукларын тапшыру булып саналмый, ә фәкать аны юкка чыгара. Бурычны кичерү зәкәт түләү булып санала алмый. Бу мәсьәләне шулай хәл итәргә мөмкин: фатирның хуҗасы арендаторына зәкәт бирә, ә ул шушы акчадан аренда өчен булган бурычын түли. Нәтиҗәсе шул ук булса да, бу очракта фатир хуҗасы зәкәт түләгән булып саналачак, чөнки ул үз милкенең өлешенә ия булу хокукын (акча) арендаторга тапшыра. Ә Аллаһка яхшырак билгеле.

*Татарстан Республикасы мөфтие*
*Камил хәзрәт Сәмигуллин*

## 3. Хаҗи мосафир булып саналамы?

### Сорау: 15 көнгә хаҗга китүчеләр намазларын тулысынча укырга тиешме, әллә мосафир саналып, кыскартырга тиешме?

**Җавап:** Үзе яшәгән шәһәр яки авыл чиген үтеп, сәфәр кылу нияте белән 100 километрдан озынрак юлга чыгучы кеше мосафир булып саналачак. Әгәр бу кешенең барып җитәчәк урында 15 яки аннан да күбрәк көнгә калырга нияте булса, ул мокыйм булып саналачак. Шул сәбәпле, кемдер Мәккәдә 15 көнгә калырга ниятләсә, ул мокыйм булып саналачак. Әмма монда бер үзенчәлек бар: хаҗга 15 көнгә дип киткән кеше бу бар көнне дә Мәккәдә үткәрә алмаячак. Хаҗга киткәндә моны белергә кирәк. Тәрвия көнендә ул Минага юнәләчәк һәм анда төн үткәрәчәк. Гарафәт көнендә ул Гарафәткә барачак, ә кич белән Гарафәттән Моздалифәгә төшәчәк һәм янә монда төн үткәрәчәк.

Бу мөһим: әгәр сез, хаҗга киткәч, башта 15 көн Мәккәдә генә торып, аннан соң гына Мина һәм Моздалифәгә барсагыз, бу очракта сез мокыйм булып саналачаксыз. Ә әгәр сез Мәккәдә 15 көннән азрак торып, аннан соң башка урыннарга барсагыз һәм анда кунсагыз, сез мокыйм булмыйсыз, ә мосафир булып саналачаксыз. Ә Аллаһка яхшырак мәгълүм.

*Татарстан Республикасы мөфтие*

*Камил хәзрәт Сәмигуллин*

# Үрнәк затлар

# Гарифҗан Буави

Күренекле педагог, кабер ташлары кисеп ясаучы оста Мөхәммәдгариф Хәсән хаҗи улы Вәлиди (ташларда имза итеп куйган тәхәллүсе Гарифҗан Буави) турында матбугатта мәгълүмат юк дияргә була. Ул 1879 елда Буа шәһәрендә, дин эшлеклесе гаиләсендә туа, шундагы җәдид мәктәбендә белем ала, үзлегеннән рус теле һәм әдәбиятын өйрәнә. Без аны Буадагы атаклы Нургали хәзрәт Хәсәнов Әл-Мерзәви Әл-Болгари Әл-Буави мәдрәсәсендә укыгандыр, дип уйлыйбыз. Егет булып үсеп җиткәч, ул Әстерхан шәһәренә барып, анда Татар укытучылар мәктәбендә белем ала, укыту эшенә керешә. Аның Оренбург губернасындагы Әсәкәй дигән татар авылында һәм Царицын (бүгенге Волгоград) якларындагы, Бәхтияр, Иске Якуп һәм башка татар авылларында укытуы мәгълүм. Гарифҗан Буави балаларга дөньяви фәннәрдән – география, тарих, тел, әдәбият, арифметикадан белем бирә, укучыларны театр, музыка сәнгате элементлары белән таныштыра.

1920 елларда ул туган шәһәре Буага кайтып, анда Мулланур Вахитов исемендәге мәктәптә ана теле укыта. Күптөрле кул һөнәрләре белгән Гарифҗан Буави мәктәптә хезмәт дәресләре дә алып бара.


Шуңа өстәп, Гарифҗан Буави татар матбугаты битләрендә язма мирас та калдырган. Кызганыч, әлегә аның иҗади эшчәнлеге бик аз мәгълүм. Аның беренче мәкаләләре 1906 елда, «Казан мөхбире» гәзитендә дөнья күрә (9 апрель саны һ. б.). Шулай ук «Шура» журналының 1913 елгы саннарында (№ 4, 5, 8, 9) Гарифҗан Буавиның «Актүбә буйлары» исемле, андагы татар авыллары тарихына багышланган зур хезмәте басыла[1].

Буага кайтып тора башлагач, Гарифҗан Буави, үзенең ишле гаиләсен туйдыру өчен, кабер ташлары эшләү белән дә ныклап шөгыльләнә. Аның тарафыннан эшләнгән җыйнак кына, матур

---

1 Хезмәтнең бер өлеше алга таба китерелә.

өслүптә ясалган һәйкәлләр бүген дә Буа зиратында, шулай ук аның янындагы Түбән Наратбаш, Бикмураз авыллары каберлекләрендә күп күренә. 1981 елның көзендә шул зиратларны өйрәнгәндә, без Гарифҗан оста эшләгән йөзгә якын ташбилге барлыгын ачыклаган идек.


Буа шәһәре татар зиратында Г. Буави эшләп куйган кабер ташы. 1981 ел. М. Әхмәтҗанов фотосы.

Аның кулыннан чыккан ташбилгеләрнең текстлары бик гади, анда артык күп догалар юк, мәрхүмнәрнең исемнәре, гомер сөргән еллары күрсәтелә, күпчелек ташларда ике юллык поэзия үрнәкләре китерелә. Ясаган һәйкәлләренең күпчелегенә «гамәле Гарифҗан Буави» дигән имзасын куя. Аның эшләренең берсендә хәтта Г. Тукайның «Васыятем» шигыреннән бер строфа да язылган:

*«Кайт, и нәфсе мотмәиннәм!*
*Бар, юнәл, кит Тәңреңә;*
*Бирдең арканңны моңарчы,*
*Инде бир бит әмренә».*

Моннан тыш, Гарифҗан Буавиның ташларында, бай гына башка төрле поэтик үрнәкләр дә китерелә:

*1. «Мадам ки җан тәндәдер,*
*Бел форсатта: бу көн сәндәдер!»*
*2. «Әҗәл килде җиләктәй йәш чагымда,*
*Вакытсыз таш куйылды баш йагымда»* һ. б.

Ул татар эпиграфика сәнгатен пропагандалаучылар арасында алдынгыларның берсе иде.

Гарифҗан Буави 1946 елның 30 сентябрендә Буа шәһәрендә вафат булып, кабере шәһәрнең татар зиратында мәгълүм.

ИСКӘРМӘЛӘР:

1. Тукай Г. Әсәрләр. – Казан, 1985. – 2 т. – Б. 6.


2. Мәгълүматлар Буа шәһәр зираты ташъязмаларыннан һәм 1984 елда Гарифҗан Буавиның Казанда яшәгән кызы, врач Халидә Вәлидовадан (1913-1987) язып алынган иде. Шулай ук башка чыганаклар да файдаланылды.

*Марсель Әхмәтҗанов,*
*филология фәннәре докторы*

صاناالغان تل ایله یازا برگان. تتاکه ایلمینسکی‌لردن کوب ایلك بولماغان زمانده روسلر اوزلری موندی آورو ایله مبتلا ایدیلر.

ایندی بزگه بو اورنده خلفین نلك بو علمی خدمتلرده نیندی اصل (ایدییا) غه قاراب بارغانی، آزراق آنك خدمتلرینك پسیخالوغیاسی حقنده بر ایکی سوز ایتورگه کیرەك بولا.

آخری بار. احمد زکی ولیدی.



## آقتوبه بویلری

I

وولغه ایدلی بویندەغی «ساریستین» اسمنده، کوبیرنا قدر زور بر اویازد شهرینی کم بلمەس؟ مونه شول «ساریستین» دن بر آز جنوبکه توشکاچ وولغه، شرق جنوبی‌گه بورولوب «آسترخان» غه یونالور. «ساریتسین» دن اون چاقریم یوغاریده، وولغەدن کچیرەك بر تارماق شرق‌گەرەك آیرلوب آغا. بو تارماق کچگنه‌گنه ایدل بولوب ینه جنوب شرقی‌گه قاراب الوغ وولغه برله بر وضعیتده، «ولادیر» شهرینەچه باروب وولغەغه قوشولا، ولادیردن دخی بر کچیرەك تارماق کروب «آسترخان» ولایتی «کراسنی یار» شهرندن توبانده بحر خزرکه قویادر.

الوغ وولغه ایله، آندن آیرلوب آغا طورغان کچوك وولغەنلك آراسنده دخی برندن برینه آغا طورغان بر نیقدر یلغەلر بولوب ایکی یلغه آراسی عادتاً چلترلنوب بتکان.

مونه شول کچوك وولغەنی یرلی خلق «آقتوبه» دیب آتیلر. «آقتوبه» ایله وولغەنلك اراسندەغی بولونلق ۲۰–۳۰ چاقروم مقدارنده پچانلك واورمانلق بولوب، بیك کوب کوللرده بار. مونی «زایمش» دیب آتیلر.

زایمشده طبیعت‌نلك حاصل ایتدیکی ایمن، اوساق، تال آغاچلری ایله، سازین یاروملق غایت قاتی واوتکن قامش، بو یر خلقی ایچون برنچی معیشت اسبابی صانالا.

بونلردن باشقه، زایمشده اوسکان پچان، آقتوباده و کوللرده بولغان حسابسز ایری بالقلرنلك هر تورلیسی بولووی بو یرنلك برکاتینی دخی‌ده آرتدرا. سنەنلك آپریل چیسلاسنده روسیەنلك شمالی ولایتلرندن آروب آقغان قار صووی وولغه ایدلنی تاشیتقان

کبی: آقتوبەنی‌ده تاشیتوب، یاراخود یوررلك ایته. یلغه یارلری طولغاچ تیره یاقغه جایوله باشلی. بتون بولوننی (زایمشنی) صو باصا. آقتوبەنلك صول طرفنده بیش چاقروملر یراقده «سرای» شهری خانلری ضبط ایتکان تاولر ایله وولغەنلك اولك طرفنده تزلگان بیولك تاولر آراسی، ایکی آی قدر یاب یاقتی دیککز کبی ۳۰ چاقروم کیکلکده توتاش صو بولوب قالا. کوز آلدنده یالتراب طورغان صو ایله بعض قالقو یرلر هم اورمان آغاچلری ایله تال چبق باشلریغنه صودن قالقوب شاعرانه بر منظرد بولا.

آپریل ۱۵ یاخود ۳۰ لرنده صو طولوب یاراخود یوررلك تیردن بولسه شول کوندوك «ساریتسین» دن «آقتوبینسکی اوبشستوا» نلك یاراخودی کیلوب صول طرف تاو بویندەغی آوللرغه طوقتی. تاتار خانلری نلك بقیه‌سی بولغان، «تساریو» شهرینه یتوب، صو یولی آچیلا. طبیعتدن استفاده ایته بلگان آدملر خصوصاً «تساریو»، پریشیب دەگی روسلر اوشبو وقتدن یاخشی فایدەلر کوره باشلیلر. بارژالر ایله مال، نیفط، کومر، صال وباشقه حاجت نرسەلر کرتەلر، باقچه وبوستانلر ایچون بوالر، یاصاب صو طوتوب قالالر.

ایول چیسلاسنده بو صو کیموب اولگی حالده قالا. بو زمان «زایش» دە صو آستندن چغا، یام یشیل اولەنلر ایله اویصو یرلرنلك جیولوب قالغان صووی تیره قامشلر، آشغوب آشغوب اوسه باشلیلر، قامش آرالرنده قر اوردکاری و آلارنلك دشمنی بولغان یابالاقلر آری بری تورلی تاوشلر ایله آقرشوب اوچا باشلیلر. کوللرده بولنوب قالمش تورلی نوعدن بالقلر، اول یرلرنی، صو آستندن کیلوب دنیاغه چقغان جنت روشنه کرتەلر.

یرلی خلق بو «زایش» نی مقدمده دیکگز بولغان دیب دعوا ایته وبو فرضلرینه یرلرینك توزلی بولدیغنی کورساتوب اثبات ایتەرگه طریشالر. واقعا بو یرلرده صولر، پچانلر بارده توزلی و آچیدر. تاو بویلرنده قازلغان قوییلرنلك صولری تملی بولسەده توبەن طرفلرده بیك یاخشی توگل. اوشانداق تاودەغی اولەنلر حیوان ایچون یاخشی بولدیغی حالده زایش پچانی قاتیراق هم آچیراق بولا. تاو ایتەگندن صالنغان الوغ یولده قوری هواده یول اوستینی قار کبی آب آق توز قابلیدر.

ولادیمر شهرینه یاقین یرده «باستونچاق» کولندن میلیونلر پود ایله توز چغاریلوب روسیەنلك هر طرفینه یبارلدیکی هر کمنك معلومیدر. مونه ایندی، بو کبی توزلی یرنی هر یل تاتلی صو ایله صولاب، برنلك قوۀ انباتیەسینی یاکارتق ایچون الوغ وولغه نهری یاردم ایتەدر.

خلاصه: آفریقای شمالیده «نیل» یاغەسی قوملق یرلرگه

حیات بیرگان کبی بزنڭ وولغەدە آقتوبە بویندەغی اهالیگە حیات بیرە و آنڭ اوستینە، صودن انتشار ایتکان طبیعی صالقونلق، جاینڭ اسیلگنی تعدیل ایتە .

بو « زایش » نڭ قالقوراق اورنلرندە اوچەر بیشەر عدد برگە اوتورغان خاخول یورتلریدە بیك یش اوچری . بولر موندە ترلك آصراب . یچان چابوب ، یاشلچەلر اوسدروب کون کورەلر .

[1]

## مسلمان آوللری

« آقتوبینسکی اوبشستوا » نڭ کچردك پاراخودلری ، آقتوبە بویندەغی آوللرغە بارر ایچون ، هر کون توشدن صوڭ حرکت ایتەلر . اون چاقروم قدر وولغە ایلە کیلگاچ آقتوبە یرماغینە شرقغە تابا بورولوب کرەلر . اگردە بو وقت بز پاراخوددە بولسەق پاراخودمز ایڭ اول « بیزرودنوی » . صوڭرە « سیردنوی » و « زاپلاونی » نام روس قریەلرینە . ایڭ آخردە « پریشیب » اسمندە بیك الوغ روس قریەسندە طوقتار . « پریشیب » کە اوچ چاقروم یتماس بورون صول طرفدە بیوك بیوك تال آغاچلری آراسندە غایت خوش منظرەلی بر مسلمان قریەسی کورنوب قالا . آندە تورلی بویاولی اویلر ، تیمر وتاقتا هم قامش اوی باشلرنڭ آرالرندە بری ییدی ، و بری دورت و بری بر منارەلی توگەرەك باشلی کچیرەك فقط ظریف بر طرزدە یاسالغان مسجدلر کورنور . مونە شول آول « بختیار » آتالا . « پریشیب » دن آری دخی باشقە کچیرەك پاراخود یوروب ، « پریشیب » دن صوڭ مشهور تاریخی « سرای » شهرینڭ نیگزینە اوطورغان « ساریف » شهرینە طوقتی . صوكوب سنەلردە « کاپوستین » اسملی خاخول آولنەچە یوری . اما آندن صوڭ صو صای بولغانلقدن آرتق بارمیدر . ساریف شهرندە برمحلە مسلمان بولوب پینزە طرفندن کیلگان میشارلردر . مقدمدە بو خلق فقیرلر ایدی . صوڭغی سنەلردە « پلانتاتسیە » کسبنە یابشدقلرندن حاللری یاخشیلانغان .

« پریشیب » ایلە « تساریف » آراسندە ایکی محلەلی « مالایفکی » یاخود « مالای » اسمندە بر مسلمان قریەسیدە بار . آقتوبە بویندە اوشبو اوچ قریەدن باشقە مسلمان قریەسی یوق .

(آخری بار) .

عارفجان ولیدی .

## „ قازاقچە سوز جازوچیلار دقتنە „ سوز جازوچیغە (*)

بول کوندەگی آداملاردڭ سویلەسەتن تلدەرنڭ توبی مونارلانغان ساغمدای آلسقا بارب جوغالادی . قانچا قادالب قاراساقدە کوزمز اوغان جیتبەیدی . قای تلدگدە بولسا قایدان چغب قالای عمر چیككەنن هیچ کم آنق بلمەیدی . تلدڭ عمری اوزاق . اونڭ جاسی جلداب ایەس ، یوز جلداب ایەس ، مڭ جلداب سانالادی . سوندای اوزن عمرنڭ اچندە تورلی نرسەلار سبب بولب اوزگەرلمەگەن تل جوق : یا آزب اوزگەرلگەن یا آسب اوزگەرلگەن . ایل بوتاقداب اوسكەن ساین ، تلدە بوتاقداغان . بزدڭ تورك تلی اولدە بر تل بولب ، سونان سوڭ ایل بوتاقداب اوسكەندە، تلدە بوتاقداغان . توبری بر بولسادە ءتوسی باسقالانب تورك تلنڭ آراسنا تاراو - تاراو جلك توسكەن . سوندقدان بول کوندە نیچە بوتاق تورك توقمان ایل بولسا ، سونچا تاراو تاندە باسقالق بار . تلدڭ باسقالانوینا سبب بولغان - هر تورلی بوتەن جورتدارمین سبایلاس بولب آرالاسقاندق . توركدڭ بالالاری ءاوسب . آلدی - آلدینا تاراب هر تورلی خلقبین سبایلاس بولغان ، آرالاسقان تورلی جورتدڭ تورلی تلنەن تورك تانە جات سوزدەر جات دبسدار کرسب ، تل آراسنڭ برتە - برتە جگی اولغایغان . مقصود سول جکدی بتەب جوغالتو بولسا ، اوغان توزودی قیسق دیب ، دورسدی خطا دیب قکر جول مین کیلمەی ، تورا جول - مین کیلو کیرەك . چونكە دورسبین خطانی ، قیسقبین توزودی ، آیروغا جاراتقان کوکرەکدە کوز بار . خطا قایدا ، دورس قایدا - قارالق . دورس املامینەن خطا املانی آیروغا مینڭ اوءچە بولای قاراو کیرەك چغار دیمن : تل طبیعتنە قارای املانی اگغایلاومە ؟ جوق املا تورنە قارای تلدی اگغایلاومە ؟ مین اویلاءین املا جازو اوچون چغارغان نرسە ، جازو تل اوچون چغارغان نرسە . اولای بولسا تلدی بوزب املاگە اگغایلاو ایەس ، املانی تلگە اگغایلاو کیرەك . تلدڭ طبیعتنە قارامای زورلاب املاگە تاكب بایلاساق ، قتای قاتندارنڭ آیاغی بولب چغادی . تورك تلنڭ بارنە عمومی املا بولو کیرەك دیسەڭ ، توركدڭ قای بالاسندە آزباغان توتق تل ، توزو املا بولسا ، سونی آلارغا کیرەك . اصل تل ، توزو

(*) تاتارچە بلمەگەندكدەن قازاقچە جازدم . تاتار اوقوچیلارندان اول کیمچلگمە کیچو اوتنەمن . ا . ب .

# Мөфти Мөхәммәдьяр Солтан һәм аның балалары – нәселебез горурлыгы



Бу язмам бабамның әтисе – мөфти Мөхәммәдьяр турында.

Аек акыллы булган кеше бервакытта да үзенең нинди нәселдән булуы белән кызыксынмый калмый, мөмкин кадәр бабалары, әбиләре кем булган, кайда яшәгән һәм башка билгесезлекләргә җавап табарга тырыша.

Тарих укытучысы буларак, мин озак еллар авыллар тарихын өйрәнүгә һәм язуга вакытымны кызганмадым, бик күп шәҗәрәләр, язмалар белән танышырга туры килде. Әти ягыннан җиде бабамның да исемнәрен (нәсел агачын) белгәнгә күрә, әни ягыннан булганнарга бик әһәмият итмәдем. Чөнки моңа бик җитди сәбәпләр бар иде. Чыгышы буенча әнинең нәселе Солтановлар шәҗәрәсенә барып тоташа. Ә Солтановлар – дворяннар һәм мөфти нәселе. Совет власте елларында бу нәселдәге кешеләргә язмышның бик ачысын татырга туры килә. Репрессияләр, куылулар, мөлкәтне тартып алу, күп еллар буена эзәрлекләүләр нәтиҗәсендә әни һәм аның белән бертуган апа һәм абыйлар үзләренең шәҗәрәсен 80 еллар азагына кадәр яшереп килделәр. Үзләре турында сөйләргә курыктылар.

Әле хәтеремдә, әнием үзенең апасы белән хат алышканда гарәп графикасы нигезендә язышалар иде, чөнки хатлар һәрвакыт кемдер тарафыннан ачылган булып, кайдадыр тикшерү үткән, күрәсең. Әни белән

бертуган абый Шамил Солтанов (1982 елда вафат булды), апа Мөхтәрәмә Солтанова  сүз ара, кайчакта «безнең нәсел дворяннар булган» – дип әйтәләр иде. Шамил абыйның ничектер сакланып калган, Солтановлар шәҗәрәсе дә бар иде, ләкин миңа күчереп алырга рөхсәт итмәде. Андагы аерым исемнәр бик ачык исемдә калган һәм менә 30 ел вакыт узгач, бу шәҗәрә белән тагы очрашыргы туры килде.

М. Әхмәтҗановның «Татар шәҗәрәләре» китабында (32 бит) Туксаба шәҗәрәсе бирелгән, ул ике вариантлы (аерым исем әйтелешендә генә).

1 вариант: Туксабай углы Шаһвәли, Шаһвәли Углы Тәвкил, Тәвкил углы Тәңребирде, Тәңребирде углы Йулбирде, Йулбирде углы Акйул, Акйул углы Котлыш, Котлыш углы Күзәй, Күзәй углы Тотар, Тотар углы Чупан, Чупан углы Мәмәт, Мәмәт углы Солтан (Солтановлар шушы кешегә нисбәтән ителеп йөртеләләр), Солтан углы Габделҗәмил кантун, Габделҗәмил углы Баязит, Баязит углы Мөхәммәтшәриф кантун, Мөхәммәтшәриф углы Мөхәммәдьяр (1837-1915) (елы авторныкы). Шәҗәрә шуннан өзелә.

2 вариант: Мирза Мөхәммәдьяр бине Мөхәммәдшәриф, бине Байазид, бине Габделҗәмил, бине Солтан, бине Мәмәт, бине Чубан, бине Тотар, бине Күзәй, бине Котлап, бине Акйул, бине Йулбирде, бине Тәңребирде, бине Тәвкил, бине Сәвәләй, бине Туксабадыр.

Мондый искәрмәләр бирелә: Шәҗәрә үзенең патронимнары белән кызыклы. 1 вариант Ризаэддин Фәхретдиннең С.-Петербург фондыннан (ср. 131, оп 1 саклау берәмлеге 50, 40 бит), икенче вариант Ш. Мәрҗанинең «Мөстәфадел әхбар…» китабының 2 нче томыннан (312 нче биттә) алынды. Соңгысы Ш. Мәрҗанигә Мөхәммәдьяр мирза үзе күчереп җибәргән. Бу нәселдән татарлардан беренче музыка профессоры Саратов консерваториясе укытучысы Солтанов чыккан.

Туксаба нәселе хәзерге Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Мәчти (Наратлы) авылында яшәгәннәр. Хәзерге вакытта Актаныш районы Яңа Байсар авылында яшиләр.

Бу шәҗәрәгә мин күп кенә ачыклыклар һәм өстәмәләр кертә алам. Менә шуларның әһәмиятлеләре. Югарыда язылган шәҗәрәнең дәвамы (II вариант буенча) … мөфти Мөхәммәдьярның улы Арслангали, икенче улы Искәндәр, өченчесе Мөхәммәтсолтан (минем әни ягыннан бабай, 1937 елда кулга алына, билгесез юкка чыга), дүртенчесе Ислам, бишенчесе Солтангали. Мөхәммәтсолтанның балалары иң олы кызы Мәдинә (1898-1979), Мияссәр (1901-1967), Әхнәф (?-1970), Мөхтәрәмә (1907-1982), Солтанбәк (1910-1979), Шамил (1914-1982), Нәсия (1919-1955). Шамил абыйның уллары Илдус (1940-1988), Илгиз (1946), Камил (1949). Солтанов Илгиз һәм Камил бүгенге көндә Казанда яшиләр. Илгиз лаеклы ялда, ә Камилнең үз бизнесы бар. Төпчек кызы Солтанова Нәсия Мөхәммәтсолтан кызы (минем әни, авыр туфрагы җиңел булсын) 1939 елда Казан педагогия училищесын тәмамлап, Мөслим районы якларына килә һәм шунда укытучы Зарипов Сәйделгә кияүгә чыга. Аның балалары Роберт (бу язманың авторы) Лируза (Казанда яши), Ләлә (Азнакайда). Безнең әни бик иртә, каты авыру нәтиҗәсендә якты дөньядан китте.

Әхнәф, Мияссәр абыйның балалары һәм оныклары Копейск шәһәрендә, ә Солтанбәкнеке Фәрит, Вәкил, Рәйсә һәм аларның балалары Ижау шәһәрендә яшиләр.

Мөхәммәдьяр бине Мөхәммәдшәрифкә тулырак тукталып узыйк. Шәҗәрәдә күренгәнчә, Мөхәммәдьяр бабаларыннан килгән сословиесе ягыннан татар мирзасы (җир биләүче) булган. Әтисе Мөхәммәтшәриф кантун (ул чорда кантун дип хәрби-территориаль берәмлек башлыгын атыйлар) була. Аның җир биләмәләре (бик зур җимеш бакчаларын да кертеп) элеккеге Калинин (Пучы) районы, безнең күрше Бакалы районы төбәкләрен үз эченә алган. Мөхәммәдьяр төпле белем ала, Уфада «Галия» мәдрәсәсен тәмамлый (ул укыганда мәдрәсәнең исеме икенче төрле булган). Аннан соң Оренбург шәһәрендә Неплюев кадетлар корпусын бетерә. С.-Петербургта хәрби хезмәттә була. Отставкага чыгып, туган якларына

кайта һәм дини эшләр буенча шөгыльләнә башлый. Патша хәзрәтләре тарафыннан дворян сословиесе бирелә.

1856 елда Казан университетын тәмамлый.

1886 елның 2 гыйнварыннан мөфти итеп сайлана. Оренбург Мөхәммәд дине Мәҗлесе Екатерина II тарафыннан оештырылган оешмалар исәбенә кергән. Мөселман дине руханилары, әлбәттә, элек тә булган: «ахуннар» һәм «муллалар» дәрәҗәләре 1788 елның 22 сентябрь көнендәге әлеге Мәҗлесне оештыру турындагы Гали Фәрманга кадәр шактый вакыт элек төрки хөкүмәт фәрманнарында телгә алына. Бу урында «мөфти» сүзенең кулланышка кертү тарихына тукталып китү урынлы булыр. Һәрхәлдә, Дини Мәҗлеснең ачылуына кадәр мөселман дине руханилары урыс хөкүмәте оешмалары челтәренә кермичә яшәп киләләр һәм аларның элеккеге оешмалары да соңгысына һич тә туры килми. Мәсәлән, 1788 елгы Гали Фәрманга кадәр, Рәсәйнең көнчыгыш өлешендә мөселман дине руханилары арасында «мөфти» дәрәҗәсе бернинди хөкүмәт кәгазьләрендә дә очрамый, шулай булгач, Кырымнан тыш, Рәсәйнең нинди дә булса бүтән җирендә мөфтиләрнең яшәве турында мәгълүматлар юк.

«Мөселманнарның иң югары дини дәрәҗәсе булып кулланылучы «мөфти» сүзе белән патша хөкүмәтенең Кырымны яулап алганда танышкан булуы һәм Оренбург Мөхәммәд дине Мәҗлесен оештыру ниндидер дәрәҗәдә Кырым мөселман руханиларының идарә итү чалымнары чагылыш тапкан булуы ихтимал», – дип яза дин белгече, Кол Гали исемендәге халыкара премия лауреаты Әнвәр Хәйри.

Оренбург Мөхәммәд дине Мәҗлесенә исә, аерым катламга карамыйча, халык сайлап куйган, рухани дәрәҗәсенә лаеклы булырлык сынау үткән һәркем расланып, Дини Мәҗлес белән идарә итә ала.

Шулай итеп, Оренбург Мөхәммәд дине Мәҗлесен оештырганда кулланылган иң зур дини дәрәҗә булып мөфти вазифасы санала. 1788 елгы Гали Фәрманда бу вазифаның төгәл билгеләмәсе бирелмәгән, ә кыска

гына һәм анык булмаган рәвештә: «Дини Мәҗлестә беренче булып Ахун Мөхәммәдҗан Хөсәенов рәислек итсен! Без аңа чиксез мәрхәмәтебез белән мөфтилек дәрәҗәсе бүләк итәбез һәм елына бер мең биш йөз сум эш хакы билгелибез», – дип әйтелә.

1817 елда исә мөфти вазифасына мөселманнар тарафыннан кандидатлар сайлау тәртибе турында фәрман чыгарыла.

1857 елда басылып чыккан Законнар Җыентыгының өченче басмасында «Оренбург Мөхәммәд дине Мәҗлесенә буйсынган төбәкләрдәге руханиларның идарә итүе турындагы Уставы» да басыла.

Мөхәммәдъяр Солтанов Диния Нәзарәтенең 5 нче мөфтие.

Уставның эчтәлеге буенча Оренбург Мөхәммәд дине Мәҗлесе коллегиаль, ягъни бергәләп хәл итә торган җәмәгать урыны санала һәм аңа мәҗлеснең рәисе – мөфти һәм өч казый керә. Мәҗлеснең канцеляриясен сәркатиб, бүлек җитәкчеләре, тәрҗемәчеләр, журналист һәм канцелярия хезмәткәрләре тәшкил итәләр. Сакланып калган язмалардан күренгәнчә, Дини Мәҗлес үзенең беренче көннәреннән башлап ук үзенә буйсынган мөселман руханилары өстеннән күзәтү-тикшерү эше алып барган. Бу тикшерү-күзәтү чаралары бик катгый булган һәм аз гына гаебе барлыгы расланган имамнар, хатыйблар һәм хәтта ахуннар да вакытлыча эшләреннән алынганнар.

1836-1889 еллар эчендә 13927 кеше төрле рухани дәрәҗә алырга имтихан тапшыра.

Мәчетләр төзетү һәм аларга руханилар билгеләү эше белән шөгыльләнгәнлектән, Дини Мәҗлес, башка диннәр тотучыларны Дини Эшләре Департаментына мәхәлләләр, мәчет һәм аларда хезмәт итүче руханиларның саны турында да билгеле бер вакытта мәгълүматлар җыеп, җиткереп торырга да тиеш була.

Югарыда әйтеп кителгәнчә, Мөхәммәдъяр Солтанов 1886 елдан мөфти вазифаларын үти башлый. 1889 елда Оренбург Мөхәммәд дине

Мәҗлесенә караган барлык мәхәлләләрнең саны 4254 кә җитә: ике җенестәге мөселманнар саны – 3 миллион 405 мең 460, ахуннар саны – 65, хатыйблар, ягъни мәчеттә хөтбә-вәгазь сөйләүчеләр саны – 2734, мөдәрисләр, ягъни дин сабагы укытучы өлкән укытучылар һәм имамнар саны – 2621, мөәззиинәр саны – 2783 була.

1888 елда 1 нче дәрәҗә Станислав ордены, ә 1896 елда 1 нче дәрәҗә Изге Анна ордены белән бүләкләнә.

Дини Мәҗлескә караган губерналарда һәм өлкәләрдә булган мөселманнар һәм мәхәлләләр саны 1889 елда, ягъни Дини Мәҗлеснең эшли башлавына 100 ел тулган көннәрдә, түбәндәгечә күренә (хәзерге Татарстан җирләре кергән губерналар). Казан губернасының 845 мәхәлләсендә 311 мең 928 ир-ат һәм 297 мең 610 хатын-кыз. Самара губернасының 282 мәхәлләсендә 72 мең 739 ир-ат һәм 76 мең 652 хатын-кыз; Уфа губернасының 1396 мәхәлләсендә 493 мең 768 мең 768 ир-ат һәм 489 мең 17 хатын-кыз була. Шулай итеп, җан исәбе буенча беренче урынны Уфа губернасы алып тора, аннан соң Казан губернасы.

Мөфти вазифасын башкаручы Мөхәммәдьяр Мөхәммәдшәриф углы Солтановның Дини Мәҗлестә эшчәнлеге гаять киң кырлы була. Метрика кенәгәләре белән эш алып баруы үзенә буйсынган 4254 мәхәллә теркәлерлек итеп 2 шәр нөсхәдә шнурланып кенәгәләр әзерләүдән, элеккеге еллар өчен тутырылган метрика кенәгәләрен саклаудан һәм алардан бик күп төрле белешмәләр бирүдән гыйбарәт.

Дини Мәҗлес эш даирәсенең башка якларына карасак, аларның күпчелеге милек бүлү вакытында варислар арасында барлыкка килгән бәхәсләр, васыятьнамәләр, аерылышулар буенча алып барылган эшләрдән гыйбарәт.

Мөфти үзенең штатында булган кешеләр турында да кайгырткан. Мәсәлән, 1886 елның 4 нче июнендә 1723 номерлы фәрман белән, Дини

Мәҗлес әгъзаларына – казыйларга эш хакын елына 214 сум 28 тиен урынына 600 сумга кадәр арттырырга рөхсәт итә.

Мөхәммәдьярның үтенече буенча тагы елына 300 сум эш хакы белән штаттан тыш тәрҗемәче билгеләнә. Департаментның 1889 елның 22 февралендәге 528 номерлы тәкъдиме белән никахлардан җыелган акча исәбенә эш хакы өч казыйга һәркайсына 200 әр сум, сәркәтибкә, штаттан тыш тәрҗемәчегә, өч бүлек мөдиренә һәм керем-чыгым бүлеге мөдиренә һәркайсына 100 әр сум, журналистка 120 сум, ә канцелярия хезмәткәрләренә 800 сум арттырыла.

1890 елның 9 нчы гыйнварында игълан ителгән Гали Фәрман буенча, мөфти һәм Дини Мәҗлеснең казыйлары вазифаларын башкару тәртибенә үзгәрешләр кертелә. Моннан соң мөфти, Эчке эшләр Министры күрсәтүе буенча, – Император галиҗәнәбләре тарафыннан, ә казыйлар исә, мөфти күрсәтүе буенча, Эчке Эшләр Министры тарафыннан раслана башлыйлар.

Мөхтәрәмә апаның сөйләве буенча: «Әтинең (Мөхәммәтсолтан) кәгазьләр тартмасында бабайдан (Мөхәммәдьяр) калган дворянлык турында таныклыгы һәм ниндидер медальләре бар иде», – дигәне истә калган.

Дини Мәҗлеснең һәр хәрәкәте, һәр эше ныклы күзәтү астына алына һәм, әлбәттә инде, дини мәсьәләләр дә, гыйбадәт кылулар да, аларның эчтәлеге дә, иң югары дәрәҗәдән алып иң түбән дәрәҗәдәге каравылчыга кадәр хезмәткәрләр мәсьәләсе дә, сумыннан тиененә кадәр акча мәсьәләсе дә һәм башка бик күп төрле мәсьәләләр – барысы да Гали Фәрманнар белән билгеләнә, хәтта бу фәрманнарда күрсәтелмәсә, уйлаган уеңны белдерергә, әйтәсе килгән сүзеңне әйтергә дә ярамый торган хәлгә җиткерелә.

1911 елда Уфада (Дини Мәҗлес үзәге) Мөхәммәдьяр Солтановның мөфти булып эшли башлавына 25 ел тулу юбилеен уздыралар. Бу тантанада татар дөньясының бик зыялы кешеләре катнаша. «Гасырлар авазы»

журналының (1997 ел 1-2 саны, 231 бите) «Новые поступления из фондов Национального архива РТ» дигән бүлегендә шул юбилейда төшкән татар зыялыларының фотосурәте урнаштырылган. Бу сурәттә философ «Галия» мәдрәсәсе җитәкчесе Камали Зыя, меценат Акчурин Хәсән, казый Габаши, казый Мамлиев Нурмөхәммәт, мөфти Мөхәммәдьяр Солтанов, «Вакыт» газетасы редакторы публицист Фатих Кәрими һ.б. төшерелгән.

Мөхәммәдьяр Солтанов 1915 елда 78 яшендә вафат була. Уфадагы Җәмигъ мәчете кырына күмелгән. Өстендә чардуган бар.

*Зарипов Роберт Сәйдел улы,*

*Солтанова Нәсия Мөхәммәтсолтан кызы,*

*Азнакай районы, Урсай авылы*

# Мөслимә

# Балаларда компьютерга бәйлелек – аны ничек җиңәргә?

**Сорау: Минем ике балам бар. Улыма – 8, кызыма 6 яшь. Улым компьютер уеннары белән бик кызыксына. Ул икенче сыйныфта укый, дзюдо белән шөгыльләнә, әмма аны планшетындагы уеннары гына кызыксындыра. Ирем белән планшетын да алдык. Әмма ул бары берни эшләргә теләми. Тренировкаларына йөрергә дә теләми. Ардым, дип зарлана. Мәктәптә берәр җирем авырта дип, елап җибәрергә мөмкин, аны алып кайтырга туры килә. Ә өйгә кайткач бер җире дә авыртмавы, аның планшетта уйныйсы килүе ачыклана. Планшеты булмаганда телефонда уйный. Телефонын алып булмый, чөнки кайвакыт аңа шалтыратырга кирәк була. Моны күреп, кызым да шул уеннарга тартыла башлады. Нишләргә, киңәш бирегез. Компьютер уеннарыннан кала, баланы башка әйбер белән ничек кызыксындырырга?**

**Җавап:** Бисмилләһир-рахмәнир-рахим. Сезнең проблемагыз бүгенге көндә күп гаиләләр өчен бик актуаль. Бүгенге җәмгыятьне төрле гаджетларсыз (кесә телефоны, планшет, компьютер) күз алдына китерү авыр. Һәм күп кенә әти-әниләр аларны тәрбия процессында актив куллана. Алар аны дөрес максатларда кулланса (Коръән тыңларга, яңа нәрсәгәдер өйрәтә торган фильм карарга) ярый да, әмма, гадәттә, әти-әниләр балаларга башта мультфильмнар күрсәтә, аннан уеннар куя. Шул рәвешле алар балаларында компьютер уеннарына бәйлелек (кибераддикция) тудыра. Теләсә нинди электрон чарадагы бар төр уеннарга бәйлелек шулай дип атала. Компьютерга бәйлелек гадәттә 10 яшьтән алып 18 яшьлек яшүсмерләрдә барлыкка килә. Моңа шәхси компьютерларның киң таралуы, җиңел генә интернетка

керә алу, мәктәпләрдә укыту программаларының компьютерлаштырылуы, компьютерлы уен клубларының артуы этәргеч булып тора. Бу йогынтыга малайлар ныграк дучар, чөнки, кызлар белән чагыштырганда, Аллаһы Тәгалә малайларга ярышу, беренче булу теләген күбрәк биргән.

Компьютерга бәйлелек иртәрәк тә барлыкка килергә мөмкин. Башлангыч мәктәптә, яшь үзенчәлекләренә бәйле, баланың психикасы әле тотрыклы түгел. Бу яшьтә аның төп эшчәнлеге – уен – уку белән алыштырыла. Бала психикасының мондый торышы төрле бәйлелекләр (компьютерга гына түгел) барлыкка килүенең бер сәбәбе булып тора. Моннан тыш, даими рәвештә йогынты ясап торсаң, бала психикасы нәрсәгәдер бик тиз ияләшә. Сүз уңаеннан, шуңа да, Пәйгамбәребез S кушканча, баланы нәкъ 7 яшеннән намазга өйрәтү әһәмиятле.

Компьютер уеннары йогынтысыннан балада бик яшьли компьютерга бәйлелек туа ала, ул чынбарлыктан качарга тели. Бала үзенең шәхси үсешендә туктап кала. Компьютер белән кызыксынып, бала гадәти уенчыклар белән азрак кызыксына, һәрвакыт виртуаль уеннарга омтыла.

Балага ярдәм итәр өчен, иң беренче чиратта анда инде чыннан да бәйлелек (кибераддикция) барлыкка килгәнме икәнен билгеләргә кирәк. Балада компьютерга бәйлелек барлыгын билгеләргә ярдәм итә торган берничә билге:

– компьютер артында үткәргән вакытны билгели алмау;

– үзенең тотышын һәм һәвәслеген акларга тырышу;

– компьютерга бәйлелекнең мөһим симптомы: компьютер артында уйнаган вакытта бала буталчык хисләр – шатлык һәм үзен гаепләү – кичерә;

– ниндидер сәбәпләр буенча компьютер артында әзрәк уйнарга туры килсә, бала ярсый, агрессив була, йомыла;

– начар төшләр күрү, көчле курку кичерү;

– дуслары белән аралашудан баш тарту.

Психологлар шәхеснең психик торышына компьютер уеннарының тискәре йогынтысын күптән дәлилләде. Шулай ук компьютерга бәйлелек кичерүчедә физик кимчелекләр күзәтелә: күрү сәләте начарая, иммунитет төшә, баш авырту, тиз ару, йокысызлык, арканың сызлавы, беләзек сызлавы хас.

## Нәрсә эшләргә?

Балагызда әлегә кибераддикция булмаса, компьютер уеннарыннан аерылу җиңелрәк булыр. Әгәр бәйлелекнең билгеләре бар икән, түбәндәгечә эш итәргә киңәш ителә:

1. Кибераддикция – авыру. Шуңа күрә, теләсә нинди авыру вакытында кебек, Пәйгамбәребез S сөннәтенә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Аллаһка дога белән мөрәҗәгать итәбез.

2. Балагыз белән компьютер артында үткәрергә рөхсәт ителгән вакытны билгеләгез. Балага туктарга билге булачак таймер куярга тәкъдим итәргә мөмкин.

3. Аз вакытка булса да, компьютер уеннарыннан баш тартырга кирәк. Бөтенләй баш тартып булса, әлбәттә, тагы да яхшырак. Шул ук вакытта сез үзегез дә уйнарга тиеш түгел. Бала бүгенге җәмгыятьтә дә мондый күңел ачу чараларыннан башка яши ала. Әлбәттә, башта сезгә дә, аңа да барлыкка килгән буш вакытта нәрсә beлəндер шөгыльләнергә өйрәнергә кирәк. Вакыт узу белән, ин шә Аллаһ, сез моңа өйрәнәчәксез.

4. Баланы компьютер – альтернатив дөнья түгел, ә тормышыбызның бер өлеше генә, дип тәрбияләргә кирәк. Аңа компьютерның Аллаһ биргән җиңеллек (кирәкле мәгълүматны табу мөмкинлеге, укуда җиңеллек) һәм шул ук вакытта сынау икәнен дә аңлатырга кирәк.

5. Компьютерга бәйлелекнең иң яхшы профилактикасы – баланы компьютерга бәйле булмаган эшләргә җәлеп итү. Уен чынбарлыкны алыштырырга тиеш түгел. Компьютердан кала башка бик кызыклы һәм

файдалы шөгыльләрнең барлыгын күрсәтегез: спорт, иҗат, дуслар белән уен һ. б.

Балаларыгызга күбрәк вакыт һәм игътибар бүлегез, ул вакытта виртуаль дөньяга керү теләге калмаячак.

Ә Аллаһка яхшырак мәгълүм.

*Хәят Ибраһимова, психолог*

*annisa-today.ru сайтыннан тәрҗемә ителде*

# Фән

# Хәнәфи мәзһәбенең ысулы

Хөкем чыгарганда Имам Әбү Хәнифә һәртөрле иярүчәнлектән сак-ланган.

Моны аның остазы Хәммәд ибн Сөләйман яхшы аңлаган. Әбү Хәнифә аның белән бар сораулар буенча бәхәсләшә, һәрвакыт барын да бик җентекләп сораштыра, үзе һәрьяклап өйрәнмичә, бер генә фикерне дә кабул итмәгән. Коръән, сөннәт һәм сәхабәләрнең фәтваларыннан калганын нәкъ шушы рәвешле аңлаганга күрә, ул үзен шактый иркен хис итә; үзен тәбигыйннәрнең фикерләрен шик астына куярга хокуклы саный һәм дөреслеген тикшергәч, алар белән килешә. Шушыңа нисбәтле Ибн Габделбәр үзенең «Әл-Интика» әсәрендә Сәгыйд ибн Әбү Гарубнең мондый хикәятен китерә: «Мин Куфага килдем һәм Әбү Хәнифә белән очрашуларда катнаштым. Аларның берсендә ул Госман ибн Гаффәнне искә алып, аңа күп рәхмәтләр белдерә. Мин бу якларда аннан кала беркемнең дә кич һәм төнлә Госманга рәхмәт белдерүен күргәнем булмаганын әйттем». Күргәнебезчә, ул халыкка яки хакимнәргә ярарга тырышмаган, ярату яки күрә алмау хисләренең тәэсиренә бирешмәгән. Ул үзенә билгеле хак юл буенча тайпылмыйча алга барган.

Әбү Хәнифә үзенең ысулын һәм аны куллануны болай аңлаткан:

«Мин Пәйгамбәрдән S ирешкәннәрне тирән ихтирам итәм. Сәхабәләрдән килгәннәргә сайланып карыйм. Ә болардан тыш калганнарга килгәндә – алар да кешеләр, без дә кешеләр». Риваятьләрнең берсендә Яхъя ибн Мәгыйн Әбү Хәнифәнең Саури һәм тагы бер кеше белән сөйләшкәндә болай дигәнен әйтә: «(Әүвәл) мин Аллаһның китабына карыйм. Анда тапмасам, Расүлүллаһ S сөннәте буенча гамәл кылам. Анда да тапмасам, Пәйгамбәребез S сәхабәләренең сүзләренә карыйм һәм алардан үземә кирәкне алам. Әмма мәсьәлә Ибраһим, Шәгъби, Хәсән,

Гатага кадәр җитсә, мин алар кебек үк ижтиһад кылачакмын»[1]. Бу имам үзенең мәзһәбен төзегән ысул булып тора да инде. Әлбәттә, бу ул бөтенләй тәбигыйннәр фикерләрен игътибарга алмаган дигәнне аңлатмый. Ул фәкать аларның фикерләре арасыннан сайлап алган. Күпчелек очракта ул Гыйрак фикһы юнәлешенә нигез салучы Ибраһим Ән-Нәхагый карашларына өстенлек биргән. Хәтта болай дияргә мөмкин: ниндидер бәхәсле сорауда үз фикерен билгели алмаганда, ул Ибраһим Ән-Нәхагыйга ияргән. Кайберәүләр мөҗтәһидләр башкаларга ияреergә тиеш түгел дисә дә, әмма дөреслектә, мондый очракларда бар мөҗтәһидләргә дә ияру күренешләре хас. Хәнәфи фикһы ысуллары буенча соңгырак чор белгечләре бу принципларны тагы да төгәлрәк билгеләгән.

Аларга туры китерелеп, хәнәфи фикһының дәлилләре түбәндәге тәртиптә билгеләнә:

1. Коръән.
2. Мөтәвәтир[2], мәшһүр[3] һәм әхәд[4] хәдисләр.
3. Иҗмаг[5].
4. Кыяска[6] тулысы белән каршы килмәсә, сәхабәләр карашлары.
5. Кыяс, гореф, тәҗрибә һ. б.

Мөхәммәд Заһид Әл-Кәүсәри бу мәсьәләне башкача караган. Аның фикеренчә, хәдисләр таралышы ягыннан Гыйрак бер дә фәкыйрь өлкәләрдән түгел. Әмма Әбү Хәнифәнең хәдисне кабул итүгә таләпләре

[1] Зәһәби «Мәнәкыйб әл-Имам Әбү Хәнифә»

[2] Мөтәвәтир хәдис – Мөхәммәд пәйгамбәрдән S күп кеше тарафыннан ишетелгән һәм хәдис туплаучыга шушы күпсанлылык дәрәҗәсен югалтмыйча ирешкән хәбәр.

[3] Мәшһүр – мөтәвәтир таләпләренә туры килмәгән, әмма иснәд катламының һәркайсында өч тапшыручыдан килгән хәбәр.

[4] Әхәд хәдисләр – өстә саналган мөтәвәтир таләпләренә туры килмәгән хәдисләр һәм хәбәрләр. Аз кешеләр тарафыннан тапшырылган бу хәбәрләр өч төргә бүленә, һәм шуларның берсе булып мәшһүр хәдисләр тора.

[5] Иҗмаг – каралган сорау буенча абруйлы галимнәрнең ризалашуы, бердәм фикердә булуы яки хөкеме.

[6] Кыяс – охшашлык (аналогия) буенча хөкем итү.

башкаларныкыннан аерылып тора. Ул фәкать хәдисләр белән, аларны өйрәнү, истә калдыру һәм тапшыру белән генә кызыксынган мөхәддисләр рәтенә керми. Моның турында үзенең «Тәгниб әл-хатыйб» китабында (152-154 б.) Кәүсәри болай ди: «Әбү Хәнифәне аз хәдисләр белгән, хәдисләр белән килешмәгән, зәгыйфь хәдисләрне кулланган, дип фаразлаучылар имамнарның хәдисләргә нинди таләпләр куюын белми, һәм имам-мөҗтәһидләрнең белем дәрәҗәсен герләре бозылган үлчәүләрдә үлчи. Әбү Хәнифәнең ниндидер күрсәтмәне кабул итүгә карата формалашкан принциплары бар. Аны гаепләүчеләр бу принциплардан гомумән хәбәрдар түгел. Бу принципларның иң мөһимнәре түбәндәгеләр:

Имам Әбү Хәнифә көчлерәк дәлилләргә ия булган хәбәрләргә каршы килмәсәләр, ышанычлы кешеләр тапшырган хәбәрләрне игътибарга алган.

Әбү Хәнифә әхәд хәдисләрне фикһ чыганакларының барысын да җентекләп өйрәнгәннән соң чыгарган нигезләмәләре буенча бәяләгән. Әгәр әхәд хәдисләр бу нигезләмәләргә туры килмәсә, имам ике дәлилнең көчлерәгенә өстенлек биргән. Искә алынган нигезләмәләргә каршылыклы хәдисләрдән өстенлек биреп, ул бу хәбәрләрнең чыгарма булуларын истә тоткан. Тахавинең «Мәганил-әсәр» хезмәтендә бу темага күп мисаллар китерелгән. Монда сахих хәдисләр кире кагылмый. Киресенчә, мөҗтәһид фикеренчә, икенче дәрәҗәдәге һәм зәгыйфь хәдисләрдә генә каршылык бар.

Әбү Хәнифә әхәд хәдисләрне уртак хөкем һәм Коръән аятьләренең туры мәгънәсе буенча бәяли. Монда игътибар таләп итә торган бер үзенчәлек бар. Имам Әбү Хәнифә мондый мисал китерә: «Кәгъбә тирәли тәваф кылу намаз булып тора» хәдисе буенча, тәһарәтсез тәваф кылырга ярамый. Әмма «тәваф кылсыннар» аятендә «тәваф» сүзе төгәл һәм туры мәгънәдә кулланыла; һәм тәваф кылуны гына фарыз итә. Аңа өстәмә итеп тәһарәт алуны фарыз яки вәҗиб итми. Хәдис буенча түгел, ә аять

буенча гамәл кылырга кирәк, дигәндә, күз уңында түбәндәгеләр тотыла: аять катгый күрсәтмәне билгели, ә хәдис фараз ителгән турында сөйли. Бу аятьтә тәваф кылганда тәһарәтле булуның фарыз түгеллеге күрсәтелә. Хәдис фараз ителгәнне генә хәбәр иткәнгә күрә, ул фарыз күрсәтмә буенча аять белән бәхәскә керә алмый. Әмма хәдис тулысы белән кире кагылмый. Анда яхшырак күрелгән турында хәбәр ителгәнгә күрә, тәваф кылганда тәһарәт алу фарыз түгел, ә сөннәт булып тора. Ягъни аятьтә – фарыз, ә хәдистә сөннәт билгеләнә.

Әхәд хәдисләрне кабул иткәндә, Әбү Хәнифә аларның билгеле сөннәткә карашларда яки гамәлләрдә каршы килмәүләренә игътибар итә.

Әхәд хәдисне кабул иткәндә, Әбү Хәнифә аның аңа тигез булган хәдискә каршы килмәвен шарт итеп куя. Ике хәдис бер-берсенә каршы килгәндә, билгеле сәбәпләр аркасында ул бер хәдисне икенчесеннән өстен таба. Мондый очракларда хәдисне өстен куюның махсус сәбәпләре бар. Мисал өчен, хәдисне тапшыручыларның берсе факиһ була яки икенчесе белән чагыштырганда гыйлемлерәк булып тора. Әхәд хәдисне кабул иткәндә, Әбү Хәнифә шулай ук аны тапшыручының үзе тапшырган башка хәдисләргә каршы килмәвен өстәмә шарт итеп куя.

Ибн Раҗәб хәбәр итүенчә, әгәр Әбү Хәнифә ике хәдиснең берсендә дәлиле яки эчтәлегендә ниндидер аермалыклар тапса, саклылык күрсәтеп, бу өстәмәне кабул итмәгән (әгәр моны зарури итә торган башка сәбәпләр булмаса).

Әбү Хәнифә «гомуми бәлвә» (ягъни һәр кеше котылгысыз рәвештә көн саен очраша торган яки бик еш кабатлана торган фарыз һәм хәрам) турында сүз барганда әхәд хәдисләр буенча гамәл кылмаган. Мондый очракларда хәдиснең мәшһүр яки мөтәвәтир булуы лазем.

Әхәд хәдисләргә карата Әбү Хәнифәнең тагы бер принцибы бар – элек беркемнең дә бу хәдисне тәнкыйтьләмәве.

Җәза яки тыю мәсьәләләренә караган аермалыклы хәбәрләр булганда, Әбү Хәнифә җиңелрәк вариантны сайлаган.

Әбү Хәнифә буенча, хәдис тапшыручының хәбәрне ишеткән мизгеленнән башлап, тапшырганчыга кадәр аны яттан хәтерләү сәләте мәҗбүри шарт.

Тапшыручы хәдисне кемнән ишеткәнен хәтерләмәгән очракта, Әбү Хәнифә аның язуларын нигездә ышанычсыз дип тапкан.

Әбү Хәнифә әхәд хәдисләр арасында башка хәдисләр белән расланганнарына өстенлек биргән.

Әбү Хәнифәнең хәдисләргә карата принципларының берсе шуннан гыйбарәт: хәбәр сәхабәләр яки тәбигыйннәр яшәгән теләсә кайсы ил яки шәһәрдә кулланылганнарга каршы килергә тиеш түгел. Ләйс ибн Сәгъд имам Мәликкә язган хатында: «Кайбер соңгырак чор галимнәренең сүзләренә нигезләнеп, Әбү Хәнифә кабул иткән хәдисләрне дәлилләре ягыннан зәгыйфь дип санау дөрес түгел. Чөнки Әбү Хәнифә бу хәдисләрне тапшырган шәехләрнең дәрәҗәсен яхшы белгән. Нигездә, сәхабә белән аның арасында ике тапшыручыдан да артык булмаган», – дигән.

Әбү Хәнифәнең күп хәдисләр белүе аның фикһның төрле бүлекләрендә китергән дәлилләреннән ачыклана. Бу хәдисләр аның укучылары һәм башка мөхәддисләр тарафыннан тупланган 17 мөснәдтә урын ала. Моннан тыш, Хатыйб Әл-Багдади Шамга Әд-Дәракутни һәм ибн Шәхиннең «Әбү Хәнифә мөснәде» дип аталган хезмәтләрен алып килә. Бу ике мөснәд искә алынган 17 хәдис җыентыгына керми. Мүвәффәк Әл-Мәкки «Мәнәкыб» китабында: «Хәсән ибн Зияд әйтүенчә, Әбү Хәнифә дүрт мең хәдис тапшырган, аларның ике меңе – Хәммәдтән, калган ике меңе башка мөхәддисләрдән тапшырылган»[1], – дип яза.

Хәнәфи мәзһәбенең кайбер билгеле галимнәре:

– Зөфәр ибн Хөзәйл (Һиҗрәтнең 158 нче елында вафат);

[1] Кәүсәри, Мүвәффәк Әл-Мәкки «Мәнәкыб», 89-91 б.

– Хәсән ибн Зийәд Әл-Лөәлөй (Һиҗрәтнең 204 нче елында вафат);

– Гайсә ибн Габән (Һиҗрәтнең 220 нче елында вафат);

– Мөхәммәд ибн Сәмәга (Һиҗрәтнең 233 нче елында вафат);

– Һиләл ибн Яхъя Әр-Рагый (Һиҗрәтнең 245 нче елында вафат);

– Хассаф (Һиҗрәтнең 261 нче елында вафат);

– Әбү Җәгъфәр Әт-Тахави (Һиҗрәтнең 321 нче елында вафат);

– Ибраһим ибн Рөстәм (Һиҗрәтнең 211 нче елында вафат);

– Әбү Хафс Әл-Кәбир;

– Бишр ибн Вәлид (Һиҗрәтнең 237 нче елында вафат);

– Әбү Сөләйман Җүзҗани.

*Камил хәзрәт Сәмигуллинның*

*«Введение в ханафитский фикх»*

*китабыннан тәрҗемә ителде*

*Рәмзилә Шафикова тәрҗемәсе*

# Җәһәннәм мәңгелекме?

*(Дәвамы)*

Ибн Кайим фикеренчә, динсезләр Җәһәннәмдә ул юкка чыкканчыга кадәр булачаклар. Ә ул юкка чыккач, аның әһелләре Җәннәткә керер.

Бу сорауда Ибн Кайим түбәндәге аятьләргә нигезләнә:

﴿فَأَمَّا الَّذِينَ شَقُوا فَفِي النَّارِ لَهُمْ فِيهَا زَفِيرٌ وَشَهِيقٌ * خَالِدِينَ فِيهَا مَا
دَامَتِ السَّمَاوَاتُ وَالْأَرْضُ إِلَّا مَا شَاءَ رَبُّكَ ۚ إِنَّ رَبَّكَ فَعَّالٌ لِّمَا يُرِيدُ﴾

**«Әмма явыз бәхетсезләр утта булырлар, алар анда газапның катылыгыннан яман тавыш белән кычкырыр вә ыңгырашыр. Ахирәтнең җире вә күкләре даим булган хәлдә алар да Җәһәннәмдә мәңге калырлар, әгәр Раббың башканы теләмәсә. Дөреслектә, Раббың кылырга теләгән эшен кылучы».**

«Һуд», 11:106-107

﴿وَيَوْمَ يَحْشُرُهُمْ جَمِيعًا يَا مَعْشَرَ الْجِنِّ قَدِ اسْتَكْثَرْتُم مِّنَ الْإِنسِ ۖ وَقَالَ
أَوْلِيَاؤُهُم مِّنَ الْإِنسِ رَبَّنَا اسْتَمْتَعَ بَعْضُنَا بِبَعْضٍ وَبَلَغْنَا أَجَلَنَا الَّذِي أَجَّلْتَ
لَنَا ۚ قَالَ النَّارُ مَثْوَاكُمْ خَالِدِينَ فِيهَا إِلَّا مَا شَاءَ اللَّهُ ۗ إِنَّ رَبَّكَ حَكِيمٌ عَلِيمٌ﴾

**«Аллаһ Тәгалә Кыямәт көнне кешеләрне һәм җеннәрне һәммәсен бер урынга җыяр һәм: «Ий җен таифәсе! Үзегезгә ияртеп күп кешеләрне аздырдыгыз», – дип әйтер. Вә җеннәргә дус булган кешеләр: «Ий Раббыбыз! Без бер-беребездән файдаландык, ягъни җеннәр безне аздырып теләкләренә ирештеләр, без аларның вәсвәсәсе белән гөнаһлы эшләрне эшләп, нәфесләребез теләгәнне үтәдек, һәм шул рәвештә син**

**билгеләгән әҗәлләребезгә ирештек», – дип әйтерләр. Аллаһ әйтер: «Сезнең урыныгыз – Җәһәннәм уты, анда мәңге калырсыз, әгәр Аллаһ башканы теләмәсә!» Дөреслектә, Раббың – Хәким, Галим».**

«Әнгәм / Терлек», 6:128

لَّابِثِينَ فِيهَا أَحْقَابًا

**«Алар җәһәннәмдә күп заманалар торырлар».**

«Нәба / Хәбәр», 78:23

Әһлес-сөннәт галимнәре бу аятьләрне алда китерелгән (мәкаләнең беренче өлешендә) аятьләр контекстында аңлаган һәм тәфсирләгән. Алар Аллаһның Үз Шәфкате белән Җәһәннәмнән гөнаһлы мөселманнарны чыгарачагында, ә имансызларның анда мәңге калуында килешкән. Бу хакыйкать нигезле рәвештә дәлилләнә, һәм без алда атап үткән галимнәрнең хезмәтләренә мөрәҗәгать итсәк, аларның мәсьәләне җентекләп тикшереп, шик-шөбһәләргә урын калдырмавына инанырбыз.

Без исә Ибн Кайимнең ялгыш фикерләрен кире кага торган кайбер карашларга тукталырбыз.

Аятьләрдә кулланылган إِلَّا مَا شَاءَ اللَّهُ «әгәр Аллаһ башканы теләмәсә» сүзләрен إِلَّا مَنْ شَاءَ «бары шулар, кайсыларына карата башканы теләмәсә» дип аңларга кирәк. Бу очракта сүз Аллаһы Тәгалә Җәһәннәмнән коткарырга теләгән гөнаһлы мөселманнар турында бара.

Җәһәннәмнең мәңгелеге һәм имансызларның анда мәңгегә кертелүе турында сөйли торган күпсанлы аятьләр һәм хәдисләрнең барлыгын истә тотсак, һәм Изге Коръән аятьләренең бер-берсенә каршы килмәвен игътибарга алсак, димәк, китерелгән аятьләр нәкъ шушындый контекстта каралырга тиеш.

Шулай ук әлеге аятьтә:

﴿فَانكِحُوا مَا طَابَ لَكُم مِّنَ النِّسَاءِ مَثْنَىٰ وَثُلَاثَ وَرُبَاعَ﴾

**«...хатын-кызлардан күңелегезгә хуш килгәнен үзегезгә никах кылып алыгыз: икене, өчне һәм дүртне»** («Нисә / Хатыннар», 4:3) кулланылган مَا сүзен مَنْ дип аңларга кирәк.

Аятьтә кулланылган вакытның чиклелеге үлем һәм Кыямәт көнендәге кубарылу арасындагы вакытка күрсәтә. Мондый аңлатуны Ибн Җәрир Әт-Табәри китерә.

إِلَّا مَا شَاءَ اللَّهُ («әгәр Аллаһ башканы теләмәсә») «мүҗмәл», ягъни яшерен мәгънәгә ия булган гыйбарә, булып тора. Җәһәннәмнең мәңгелеге турында сөйли торган аятьләр һәм хәдисләр «заһир» булып тора, ягъни мәгънәләре ягыннан ачык, ә кайберләре «нәсс» – ачыктан-ачык дәлил. Шул рәвешле, «мүҗмәл» белән «заһир» кисешкән очракта, «мүҗмәл» «заһир» контекстында аңлатылырга тиеш, ягъни туры анык мәгънәгә ия булмаган гыйбарә анык мәгънәгә ия һәм ачык гыйбарәгә бәйле аңлатылырга тиеш. Димәк, шушы кагыйдә буенча, Җәһәннәм, андагы газаплар кебек үк, мәңгелек.

إِلَّا مَا شَاءَ اللَّهُ («әгәр Аллаһ башканы теләмәсә») Җәһәннәм әһелләренә генә түгел, ә Җәннәт әһелләренә дә карый. Димәк, Ибн Кайим фикерләренә иярсәң, Җәһәннәм генә түгел, ә Җәннәт тә вакыт ягыннан чикле. Алда әйтеп үткәнебезчә, мондый фикердә бары Җәһем бин Сафван гына була, ә аның карашлары белән әһлес-сөннәт галимнәре килешмәгән, һәм аларны ялгыш дип таныган.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә:

﴿وَأَمَّا الَّذِينَ سُعِدُوا فَفِي الْجَنَّةِ خَالِدِينَ فِيهَا مَا دَامَتِ السَّمَاوَاتُ وَالْأَرْضُ إِلَّا مَا شَاءَ رَبُّكَ ۖ عَطَاءً غَيْرَ مَجْذُوذٍ﴾

**«Бәхетлеләр Җәннәттә булыр. Алар җир вә күкләр даими булган хәлдә Җәннәттә мәңге калырлар, әгәр Раббың башканы теләмәсә. Бу һич бетми торган бүләктер»,** – ди.

«Һуд», 11:108

Аятьтәге «җир вә күкләр даими булган хәлдә» сүзләре Ахыйрәтнең җире һәм күгенә карый, ә планетабыздагы хәзерге атмосфера һәм литосферасына карамый. Димәк, киресен дәлилләргә тырышучылар Кыямәт көнендә җир һәм күкләр җимерелгәннән соң, имансызларның турыдан туры Җәннәткә эләгүләренә дә ышанырга тиеш. Ә бу, белгәнебезчә, хакыйкатьтән ерак.

Хәзер لَّابِثِينَ فِيهَا أَحْقَابًا «алар Җәһәннәмдә күп заманалар торырлар» («Нәба / Хәбәр», 78:23) аятен карап китик. Ибн Кайим аны үз фикерләренә дәлил буларак кабул итә.

Хәдисләрдә «хукуб» сүзе озынлыгы мең елга тигез вакыт аралыгы буларак шәрехләнә. Димәк, Ибн Кайим сүзләренә нигезләнеп, гади генә санап карасак, якынча 150 мең елдан соң Җәһәннәмгә эләккән имансыз бәндәләр инде Җәннәттә булырга тиеш. Шулай ук «алар Җәһәннәмдә күп заманалар торырлар» сүзләре «күпмедер вакыттан соң алар аннан чыгачак» дигәнне аңлатмый (Мостафа Сабри Әфәнди, «Исламның яңа мөҗтәһидләренең белемнәре», 108 б.).

Шулай ук, мондый аятьне башка, Җәһәннәмнең мәңгелеге хакында ачык сөйли торган, аятьләр контекстында карасак, без бернинди дә каршылыклар күрмәячәкбез.

«Хукуб» сүзе «озак еллар/күп заманалар» мәгънәсеннән тыш шулай ук «мәңгелек» яки «бетмәс» дигәннәрне белдерә ала. Шул рәвешле, ал-

дагы аятьләрнең мәгънәсен истә тотып, без бу аятьтән имансызларның Җәһәннәмдә мәңге булачакларын аңлый алабыз. Күргәнебезчә, әлеге аять башка аятьләргә каршы килми, киресенчә, Җәһәннәмнең мәңгелек дигән фикернең дөреслеген дәлилли.

Ләкин, ничек кенә булмасын, ялгышканнар аларның мәгънәләрен барыбер үзләренчә аңлата. Хакыйкать ачыктан-ачык, аны кабул итәргәме әллә ялгышучылар юлыннан барыргамы – һәр кеше үзе хәл итә. Аллаһы Тәгалә мондый кешеләрнең өлешен анык аңлатты:

﴿وَقُلِ الْحَقُّ مِن رَّبِّكُمْ ۖ فَمَن شَاءَ فَلْيُؤْمِن وَمَن شَاءَ فَلْيَكْفُرْ ۚ إِنَّا أَعْتَدْنَا لِلظَّالِمِينَ نَارًا أَحَاطَ بِهِمْ سُرَادِقُهَا ۚ وَإِن يَسْتَغِيثُوا يُغَاثُوا بِمَاءٍ كَالْمُهْلِ يَشْوِي الْوُجُوهَ ۚ بِئْسَ الشَّرَابُ وَسَاءَتْ مُرْتَفَقًا﴾

**«Янә әйт: «Ий кешеләр! Ошбу Коръән Раббыгыздан килгән хак сүзләрдер, туры юл вә гадел хөкемнәрдер, теләгән кеше Коръән белән гамәл кылып, мөэмин булсын вә теләгән кеше Коръән белән гамәл кылмасын да, кәфер булсын!» Коръән белән гамәл кылмыйча үзләренә золым иткән имансызларга Без ут хәзерләдек, аларны утның ялкыны вә төтене чолгап алыр, әгәр эчәселәре килеп интексәләр, аларга кайнарлыкта эрегән бакыр кебек сасы эрен суы эчерелер, ул су эчкәндә йөзләрен көйдерер. Ул нинди кабахәт эчемлектер вә ул урын нинди кабахәт урындыр!»**

«Кәһаф / Тау Тишеге», 18:29

Хәзер Ибн Кайим үзенең хаклы булуын дәлилләргә омтылып таянган сәхабәләргә бәйле мәсьәләләрне карап китик.

Турылыклы хәлифә Гомәрнең d: «Әгәр Җәһәннәмдә Әлиҗдәге ком кадәр вакыт уздырырга кирәк булса, аның әһелләре аннан чыгар иде», – сүзләренең мәгънәсе юри үзгәртелә. Аның сүзләре Җәһәннәм әһелләре

Җәһәннәмдә озак вакыт булып, мисал өчен, Әлиҗ дип аталган билгеле бер җирлектәге ком күплеге кадәр, аннан соң ут һәм газаплардан азат ителер, дигән сүз түгел. Гәрчә Ибн Кайим шулай дип аңлатырга омтылса да. Киресенчә, хәлифәнең сүзләре Җәһәннәмнең мәңгелеген ассызыклый: ком үзенең күләмендә чикле, әмма имансызларның Җәһәннәмдә булачак вакытлары берничек тә чикле түгел.

Шулай ук Габдуллаһ ибн Мәсгуд d тапшырган хәдистә дә:

عَنْ عَبْدِ اللهِ رَضِيَ اللهُ عَنْهُ قَالَ قَالَ رَسُولُ اللهِ صَلَّى اللهُ عَلَيهِ وَسَلَّمَ لَوْ قِيلَ لِأَهْلِ النَّارِ : إِنَّكُمْ مَاكِثُونَ فى النَّارِ عَدَدَ كُلِّ حَصَاةٍ فِى الدُّنْيَا لَفَرِحُوا بِهَا وَلَوْ قِيلَ لِأَهْلِ الْجَنَّةِ : إِنَّكُمْ مَاكِثُونَ فِى الْجَنَّةِ عَدَدَ كُلِّ حَصَاةٍ فِى الدُّنْيَا لَحَزِنُوا وَلَكِنْ جُعِلَ لَهُمْ الْأَبَدُ

«Җәһәннәм әһелләренә: «Сез монда җирдә вак ташлар күпме булса, шулкадәр булырсыз», – дип әйтелсә, алар сөенер иде. Әгәр Җәннәт әһелләренә: «Сез монда җирдә вак ташлар күпме булса, шулкадәр булырсыз», – дип әйтелсә, алар күңелсезләнер иде. Әмма алар анда мәңге булыр» (Тәбәрани, «Әл-Мүҗәммүл-кәбир», №10384, 10/179-180).

Димәк, Җәһәннәм яки Җәннәттә булу вакытының нindидер чиге юк.

Хәсән Бәсри бу хәдисне «мүнкатыг» дип билгели, ягъни аның иснәде өзелгән яки тулы түгел. Ә билгеле булганча, ул «мөрсәл» хәдисләрнең (ягъни хәбәрне Пәйгамбәрдән s турыдан туры ишетә алмаган тәбигыйн яки Пәйгамбәр s вафат булган вакытта әле бала булган сәхабә тапшырган) күпчелеген кабул итмәгән. Шул сәбәпле, Ибн Кайимнең Җәһәннәмнең мәңгелеген дәлилли торган аять һәм хәдисләрнең барлыгын белә торып, шушындый хәдисләргә нигезләнеп, киресен дәлилләргә омтылуы бик күңелсез.

Шуңа өстәп, әгәр бу сүзләрне Җәһәннәм әһелләренә карата кулланып булса да, алар фәкать гөнаһлы мөселманнарга карый: алар, монда күпмедер вакыт үткәреп, Җәннәткә кертеләчәк; һәм Ибн Кайимнең фикерләренә берничек тә бәйле түгел. Хәтта Гомәр d сүзләрен Ибн Кайим үзгәрткән вариантта кабул итсәк тә, аларны түбәндәгечә аңларга кирәк: «Әгәр Җәһәннәмдә Әлиҗдә ком күпме булса, шулкадәр вакыт үткәрергә туры килсә, йөрәкләрендә бер бөртек иман булган кешеләр аннан бер көндә чыгачак».

Ибн Кайим кулланган башка хәдисне Әбү Һурайра, Ибн Мәсгуд һәм Гамр бин Гас d тапшыра: «Шиксез, Җәһәннәмдә беркем калмаячак вакыт җитәчәк». Әмма галимнәр бу хәдис гөнаһлы мөселманнар турында, дигән фикердә килешә. Алар Җәһәннәмдә җәзаларын алачак, һәм, һичшиксез, Җәһәннәмдә алар арасыннан беркем калмаячак вакыт җитәчәк, чөнки Аллаһның рәхимлеге белән алар Җәннәткә кертеләчәк.

Моны Габдуллаһ ибн Мәсгуд d тапшырган башка сахих хәдисләр дә дәлилли, алар мәшһүр мөхәддис һәм факыйһ имам Әт-Тахавинең «Мүшкилүл-әсәр» һәм «Мүсәннәф» хәдис җыентыкларына кертелгән.

Имам Бәгави бу ике хәдисне дә «Һуд» сүрәсенең йөз җиденче аятенең тәфсирендә искә ала һәм: «Әгәр бу хәдисне әһлес-сөннәт карашы буенча дөрес дип кабул итсәк, түбәндәгечә аңларга кирәк: «Анда иманлы кешеләрдән берсе дә калмаячак. Калган имансызлар исә Җәһәннәмдә мәңге булачак», – дип ассызыклый.

Хәтта бу хәдисләрне Ибн Кайим буенча карасак та, бу барыбер Җәһәннәмнең кайчандыр юкка чыгачагын аңлатмый. Хәдисләрдә анда беркем калмаячак диелә, ә Җәһәннәмнең юкка чыгуы турында бер сүз дә юк. Һәм шул сәбәпле генә булса да, Ибн Кайим фикерләренең дәлиле булып тора алмый. Шулай ук, бар галимнәр, һәм Ибн Кайим үзе дә, Җәһәннәм булганчыга кадәр, имансызлар анда даими торачак, дигән фикер белән

килешә. Шул рәвешле, хәтта болай фикер йөрткәндә дә, Ибн Кайимнең фикерләре нигезсез һәм бер-берсенә каршы килә.

Хәтта Җәһәннәм әһелләренең анда мәңге булмаячагы турында сөйли торган хәдисләр булуы белән килешүне күз алдына китерсәк тә, алар «мәрфуг» булып саналмаячак. Ә бу очракта аларның мәгънәсе янә аятьләр һәм сахих хәдисләргә нигезләнеп аңлатылырга тиеш, ә алар исә нәкъ имансызларның мәңгелек Җәһәннәмдә мәңге булачаклары турында сөйли. Әгәр дә без ул хәдисләрне күпчелек аятьләрдә һәм хәдисләрдәге мәгънәдән аерылган мәгънәдә кабул итсәк, бу аларны зәгыйфь итәчәк. Аерым вак мәсьәләләрдә зәгыйфь хәдисләргә мөрәҗәгать итү рөхсәт ителсә дә, әмма мондый мөһим мәсьәләләрдә, киресен дәлилли торган аять-хәдисләр булган очракта, бу, әлбәттә, тыелган.

Шул рәвешле, алда саналганнар Ибн Кайим фикерләренең ялгыш һәм хаталы булуын күрсәтеп тора.

Кемнәрнеңдер бу аятьләрдә кулланылган «хүлд» һәм «әбәд» сүзләренә башка мәгънә бирергә омтылулары җинаять булып тора, һәм кешеләрне ялгыштыруны, хакыйкатьтән читләштерүне максат итеп куя.

Аларның мәгънәсен «Лисәнүл-гарәб» һәм «Әс-сыйхах» сүзлекләре ярдәмендә аңлатып карыйк. Монда «әл-хүлд» сүзе «бер урында даими рәвештә, аннан чыкмый тору» кебек аңлатыла. Сүз уңаеннан, Ахыйрәтнең бер атамасы – «Дәрүл-хүлд», чөнки ул мәңгелек.

Изге Коръәндә Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәргә S мөрәҗәгать итә:

﴿وَمَا جَعَلْنَا لِبَشَرٍ مِّن قَبْلِكَ الْخُلْدَ أَفَإِن مِّتَّ فَهُمُ الْخَالِدُونَ﴾

**«Дөньяда синнән элек һичкемне мәңге калучы кылмадык. Син үлеп тә, имансызлар әллә мәңге калырлармы? Барча кеше үлем ачысын татыр. Без сезне сырхау, ачлык кебек яманлык белән, вә сәламәтлек, байлык кебек яхшылык белән сыныйбыз, яки савап белән гөнаһ арасында сезне сыныйбыз, болар сезне фетнә**

**кылып сынау йөзеннән. Соңыннан хөкем ителергә Безгә кайтарылырсыз».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:34-35

Аятьне җентекләп карасак, «الْخُلْدَ» һәм «الْخَالِدُونَ» сүзләренең «үлемсезлек», «мәңге яшәүче» мәгънәләрендә кулланыуын күрербез. Ягъни Пәйгамбәргә S мөрәҗәгать итү «әгәр син үлемле булсаң, әллә үлемсез-ләр булырмы?» контекстында килә. Әгәр дә бу сүзнең мәгънәсен «озак вакыт» дип кабул итсәк, бу очракта хаталы фикер килеп чыгар иде: «Мөхәммәд! Дөньяда синнән элек һичкемне озын гомерле кылмадык. Син үлеп тә, имансызлар әллә озак яшәрләрме?»

Билгеле булганча, Нух пәйгамбәр a 950 елдан артык яшәгән. Шул сәбәпле, Коръәндә килгән «хүлд» сүзе «мәңгелек» мәгънәсенә ия.

Төгәлләп имам Синәнүддин Йосыф Әл-Әмәси Әл-Хәнәфинең (һиҗри буенча 1000 елда вафат) «Тәбигыйн әл-мәхәрим»дә (461 б.) әйткән сүзләрен китерәсе килә:

«Кыямәт көнендә имансыз гафу ителәчәк, яки Җәһәннәмгә кертелгәннән соң аннан чыгарылачак, яки аның җәзасы бетәчәк, дип әйтүче кеше Аллаһ пәйгамбәрләргә җибәргәннәргә инанмаган».

*Камил хәзрәт Сәмигуллин,*
*Татарстан Республикасы мөселманнарының*
*Диния нәзарәте рәисе, мөфти*

# Коръән турында гыйлем

*(Дәвамы)*

## Гомуми мәгънәле текстлар (аятьләр) һәм иңүнең конкрет шартлары

Бу мәсьәлә күбрәк фикһ (Ислам хөкемнәре һәм кагыйдәләре) өлкәсендә карала һәм, шулай ук, тәфсир эшенә дә кагыла.

Тәфсир һәм фикһ фәннәрендә «гомуми мәгънәле аятьләр (текстлар) һәм иңүнең конкрет шартлары» дигән махсус бер кагыйдә дә бар – бу кагыйдә аятьләрнең мәгънәләрен һәм иңү сәбәпләрен (шартларын) бергә тоташтырып карарга һәм, шулай ук, бу мәсьәләдә барлыкка килгән хаталарны да тикшереп төзәтергә ярдәм итә.

Аятьләр иңгәндә шундый очраклар да була – әйтик, бер конкрет мәсьәлә (сәбәп) хакында, конкрет шартларга һәм конкрет нәрсәгә (адресатка) карата ниндидер бер конкрет тематик аять иңә, әмма дә ләкин бу аять, махсус рәвештә шушы конкрет нәрсәгә төбәлгән булуына карамастан, үзенең эчтәлеге белән гомуми мәгънәле булырга мөмкин.

Башка төрле вариантлар да булырга мөмкин:

1. Әгәр дә аять берәр төрле конкрет мәсьәлә (сәбәп) хакында иңеп, фәкать шушы конкрет мәсьәлә белән генә бәйле булса һәм аның тексты гомуми мәгънәле булмаса – бу очракта әлеге аятьне «конкрет сәбәпле һәм адресатлы аять» дип атарга була.[1]

Мәсәлән, Аллаһы Тәгаләнең «Төн» дигән сүрәсенең:

**«Ул уттан гөнаһтан сакланучы тәкъва кеше читтә булыр. (Ул кеше) гөнаһтан пакьләнү нияте белән малын Аллаһ күрсәткән урыннарга бирер»,** – дигән аяте.

«Ләйл / Төн», 92:17-18

---

[1] «Әл-Иткан» (1/30)

Галимнәрнең бердәм фикеренчә, бу аять – фәкать Әбү Бәкергә d генә карата (аңа гына багышланып) иңгән аять. Шуңа күрә дә Фәхреддин Әр-Разый имам бу аятьне шуңа ук охшаш булган (әмма дә ләкин мәгънәсе һәм адреслануы белән икенче төрле булган) башка бер аять белән (Әбү Бәкерне d – Пәйгамбәребездән s соң иң яхшы кеше булуын раслый торган аять белән) – «Сезнең Аллаһ хозурында иң хөрмәтлеләрегез – иң тәкъвалы булганыгыздыр» («Хүҗүрат / Бүлмәләр», 49:13) чагыштырып күрсәтә.

Димәк, «Төн» сүрәсендәге мисал итеп китергән бу аятьне «гомуми мәгънәле аятьтер», дип санаучылар ялгышалар.

Бу аять Әбү Бәкердән d башка бер генә кешегә дә (гамәлләре белән Әбү Бәкергә d ничек кенә охшаш булуларына карамастан) кагылмый. Чөнки, галимнәрнең бердәм фикеренчә, бу аятьтәге «الأتقى» («әл-этка» – тәкъвалы) дигән сүзнең алдында торган «ال» («әл») дигән артикль монда мәсьәлә фәкать бер конкрет мәшһүр һәм тәкъва шәхес турында гына булуын күрсәтә. Шуңа күрә дә бу аятьне югарыда әйткән «гомуми мәгънәле аятьләр һәм конкрет иңү шартлары» дигән кагыйдә белән тасвирлап та булмый.

Ә инде «ال» («әл») артикленең икенче функциясенә (аның «кайсылар» дигән гомуми алмашлык сүз мәгънәсен бирү роленә) килгәндә, шуны әйтергә була: гарәп телендәге кагыйдә буенча, «ال» («әл») артикле белән «алмаштырылган» «кайсылар» дигән сүз أتقى («әтка» – «тәкъвалырак (башкаларга караганда)») өстенлек дәрәҗәле сыйфат-сүзе белән берничек тә яраклаша алмый.

Өстәмә итеп, шунысы турында да әйтергә кирәк – бу «الأتقى» дигән сүз аятьтә берлек санда бирелгән, чөнки аның «ال» («әл») артикле – кон-

крет объектны аерып күрсәтә торган билге булып тора. Ә сыйфат сүзнең өстенлек дәрәҗәсендә булуы – ул объектның бердәнбер һәм кабатланмас икәнлеген генә күрсәтә.

Димәк, бу аятьне «гомуми мәгънәле» дип атау нигезсез булып чыга.

Ә инде аның конкрет һәм төгәл адресатына килсәк – ул кеше d безнең барыбызга да мәгълүм.

2. Шулай ук кайбер конкрет сәбәп белән (яисә адресланып) иңгән аятьләр гомуми мәгънәле дә булырга мөмкиннәр. Мондый аятьләрне тикшергән очракларда исә фикһ белгечләре, тәфсирчеләр һәм башка галимнәр «иңү сәбәбенә бәйләнмәгән гомуми мәгънәле аятьләр» дигән кагыйдәгә нигезләнеп эш итәләр.

Монда, дәлил буларак, сәхабәләр, тәбигыйннәр һәм тәбигъ-тәбигыйннәр тарафыннан кайбер конкрет сәбәпле буларак иңгән аятьләрнең мәгънәләрен гомумиләштереп караганнарын китерергә була. Аларның аятьләргә карата мондый нәтиҗәләр ясаулары – табигый нәрсә булды һәм аларга моның өчен берәү дә шелтә белдермәде.

Бу мәсьәләгә карата Мөхәммәд ибне Кәгыйб болай диде: «Аять билгеле бер кешегә карата иңә, ә аннары соң ул барча кешеләргә дә кагыла торганга әверелә».

Нәҗдә әл-Хәнәфи Ибне Габбастан Аллаһы Тәгаләнең «Карак ирнең һәм карак хатынның кулларын кисегез...» дигән сүзләре хакында: «Бу аять нинди: махсусмы яисә гомумиме?» – дип сораган. Ибне Габбас аңа: «Гомуми», – дип җавап биргән.[1]

Шулай ук бу мәсьәләне Әз-Зәркәшинең сүзләре дә ачыклый: «Конкрет сәбәпләр белән иңгән аятьләр хакында галимнәр ошбу килешүгә килделәр: андый аятьләр, үзләренең беренчел конкрет сәбәбе (адресаты) белән бәйләнештә булуларына карамастан, шул ук вакытта алар шундый ук сәбәпкә (адресатка) охшашлы башка вәзгыятьләргә дә (адресатларга

---

1 «Әл-Иткан» (1/29-30)

да) кагылышлы булырга бик мөмкиннәр (мәсәлән: Сәләм ибне Сәхәр хакында иңгән аять; Һиләл ибне Үмәйя хакында иңгән «лиган» аяте; Гайшә турында бөһтан сүз чыгаручыларга карата җәза билгеләгән аять – болар барысы да барча кешеләргә дә кагыла торган аятьләр)».[1]

Бу – бәхәссез кагыйдә. Галим кешенең Коръәннең гомум мәгънәле текстларын чикләргә хакы юк.

Бу дөньяда барча кагыйдәләр (хөкемнәр) дә шулай барлыкка киләләр – күп очракта башта ниндидер бер конкрет сәбәпле кагыйдә (хөкем) барлыкка килә һәм соңыннан ул гомум кагыйдәгә (гомум хөкемгә) әверелә.

## Сәбәпчел шартларда иңгән вәхиләргә багышланган иң мәшһүр хезмәтләр

Күбесенчә, сәбәпчел шартларда иңгән вәхиләргә багышланган эзләнүләр белән абруйлы һәм берничә фән өлкәләрендә хезмәт иткән мөхәддисләр шөгыльләнгәннәр. Аларның арасыннан кайберәүләре тәфсир хезмәтләре дә язганнар һәм шул эшләрендә сәбәпчел шартларда иңгән вәхиләр мәсьәләсен дә караганнар – кемдер бу мәсьәләне фәкать бер тәфсир хезмәте кысаларында гына (фрагментар рәвештә генә) караган, ә кемдер исә, бу мәсьәлә буенча җитәрлек мәгълүматлар туплап, шулардан аерым бербөтен хезмәт тә булдыра алган.

Сәбәпчел шартларда иңгән вәхиләр турында беренче хезмәт төзегән галим булып Бохари имамның шәехе – имам Гали ибне Габдулла Әл-Мәдини санала (һиҗринең 234 нче елында вафат). Аннан соң бу Коръән фәне өлкәсендә башка хезмәтләр дә барлыкка килә башладылар. Әмма дә ләкин аларның хезмәтләрендә бу фән өлкәсен өйрәнүчегә бик тә мөһим булган бер нәрсә – хәдисләргә карата критик анализ ясау эше башкарылмады, ягъни, алар «сахыйх» хәдисләрне «зәгыйфь» хәдисләрдән аерып карамадылар.

1 «Әл-Борһан» (1/24)

Сәбәпчел булып иңгән вәхиләргә багышланган иң әһәмиятле хезмәтләрдән ике китапны атап әйтергә була:

1. «Иңү сәбәпләре (шартлары)» (авторы – имам, тәфсирче, нәхү фәне белгече һәм мөхәддис Әбү Әл-Хәсән Гали ибне Әхмәд Ән-Нисәбүри («Әл-Вәхиди», дип танылган); һиҗринең 427 нче елында вафат).

Бу китапта ул иснәдле хәдисләргә нигезләнә һәм, шулай ук, иснәдсез хәдисләрне дә китерә.

2. «Лүбәб ән-нөкул фи әсбәби ән-нөзүл» (авторы – имам һәм мөхәддис-хафиз Җәләледдин Габдеррахман Әс-Сүютый, һиҗринең 911 нче елында вафат).

Ул, Әл-Вәхидидән аермалы буларак, һәрбер китергән хәдисен хәбәрчесе белән бәйләгән – шуның белән укучыга уңайлык ясаган. Әмма ике нәрсәне исәпкә алмаган:

- хәдисләрне (ә алар арсында бик сирәк очрый торганнары да һәм онытылганнары да бар) үзе үк укучыларга тәкъдим иткән чыганакларга таянып «сахыйх» һәм «зәгыйфь»ләргә аермаган;

- сәбәпле иңгән күп кенә аятьләр турындагы хәдисләрне игътибарга алмаган. Моны раслау өчен аның ошбу китабын Ибне Кәсирнең «Коръән тәфсире» белән яисә аның үзе үк (Әс-Сүютый) язган «Әд-Дөрр әл-мансур» дип аталган икенче хезмәте белән чагаштыру да җитә.

Син «Әл-Лүбәб» китабында теге яисә бу аятьнең иңү сәбәбе турында бернәрсә дә әйтелмәгәнгә күрә, берүк: «Бу аять сәбәпсез иңгән икән» дип уйлый күрмә – ә бәлки, чынлыкта, ул аятьнең иңү сәбәбе бардыр, тик син аны башка чыганаклардан гына эзләп таба алачаксың.

## Вәхинең Мәккәдә һәм Мәдинәдә иңгән өлешләре

Бу бүлекнең исеме «вәхиләрнең иңүе фәкать территориаль фактор белән генә бәйләнешле һәм шуңа күрә дә бу мәсьәлә фәкать территориаль кысаларында гына өйрәнелә» дигәнне аңлатмый. Юк, киресенчә,

монда Коръәннең иңүе төрле яклардан карала. Чөнки Коръәннең иңүе Мәккә һәм Мәдинә шәһәрләре белән генә бәйләнмәгән бит. Шуңа күрә дә аны, ике кисәккә генә бүлеп, катгый рәвештә «Бусы Мәккәдә иңгән, ә бусы – Мәдинәдә», дип кенә карарга да ярамый.

Бу бүлек Коръән теле яңгырашының һәм аның сөйләм рәвешенең, стилистикасының гүзәллеген өйрәнүдә бигрәк тә зур роль уйный – аның ярдәмендә Коръән теле стилистикасының тирән нигезләре һәм шартлары (факторлары) ачылалар. Шулай ук бу бүлек ярдәмендә Коръәннең уникальлегенең (кабатланмаслыгының) тагын бер күрсәткече ачыла – аның «вакыт», «урын» һәм «шартлар» дигән фани дөнья төшенчәләренә карата бәйсез булуы һәм әйләнә-тирәнең әсире булмавы, аның бар нәрсәдән дә өстен булган хәлдә, иң биек югарылыктан барча кешеләргә дә, вакыт-урын-шартлар үзгәрешләренә дә карамастан, мөрәҗәгать итеп тора алуы.

## Коръәнне «мәккәнеке» һәм «мәдинәнеке» дигән төркемнәргә бүлү мәсьәләсендә төрле карашлар

Галимнәр Коръәннең аять-сүрәләрен Мәккә яисә Мәдинә шәһәрләре белән бәйләп бер-берсеннән аерып бүлү һәм атау мәсьәләсендә, ягъни «мәккәнекеләр» яисә «мәдинәнекеләр» булуын раслауда һәм аларны, берберсеннән аерып, ике төркемгә бүлеп атауда төрле карашларда булдылар. Гомуммән алганда, алар бу мәсьәләне чишүдә өч төркемгә бүленделәр:

1. Беренче гыйльми караш буенча, «мәккәнекеләр» дип мөселманнарның Мәдинәгә Һиҗрәт кылып күченеп китүләренә кадәр иңгән вәхиләр саналалар, ә «мәдинәнекеләр»гә исә – мөселманнар Һиҗрәт кылганнан соң иңгән вәхиләр керә. Бу – иң киң таралыш тапкан караш (ислам диненең ике халәтен (ике чорын) аерып күрсәткән Һиҗрәт вакыйгасы белән бәйләнешле булган караш – *тәрҗемәче искәрмәсе*).

Бу мәсьәләдә җентекләп башкарылган бик күп эзләнүләр булуы сәбәпле, без дә, үз чиратыбызда, «мәдинәнекеләр» дигән төшенчәне ачыклау һәм төгәлләү нияте белән, үзебезнең ошбу «мәдинәнекеләр» – Һиҗрттән соң иңгән барча вәхиләр» дигән гыйбарәбезне тәкъдим итәргә булдык.

Бу гыйбарәгә бинаән, «мәдинәнекеләргә» хәтта Мәккәне яулап алган елда иңгән вәхиләр дә һәм, шулай ук, Пәйгамбәребезнең соңгы «саубуллашу хаҗы» вакытында иңгән вәхиләр дә керә (әйтик, шул исәптән, менә бу аять тә: «Бүген Мин сезгә Үземнең рәхмәтемне тулысынча җиткереп тәмамладым – сезгә яраклы һәм файдалы булырлык итеп, динегезне камил рәвештә төзеп бирдем – сезгә Үземнең ризалыгым белән ислам динен ихтыяр кылдым» (5: 3).

Шулай ук «мәдинәнекеләргә» Мәдинә шәһәренең читләрендә һәм аннан ерак булган җирләрдә иңгән вәхиләр дә керәләр (әйтик, сәфәр яисә сугыш яулары вакытларында иңгән вәхиләр).

Йахъйа ибне Сәлламә әйтүе буенча: «(Һиҗрәт кылганчы) Мәккәнең үзендә яисә Мәдинәгә күчеп барышлый (Пәйгамбәребезнең S Мәдинәгә барып җиткәнче) иңгән вәхиләр «мәккәнекеләр» булып саналалар, ә инде аның Мәдинәгә барып җиткәннән соң юлда (сәфәрдә, яуда) иңгән вәхиләр – «мәдинәнекеләр»дән булып саналалар».

Бу хәбәрне бик тә әһәмиятле, файдалы һәм, шулай ук, фәнни яктан да җентекләп каралган дип бәяләргә була. Без аннан шундый нәтиҗә дә ясый алабыз – Мәдинәгә барышлый иңгән вәхиләр дә «мәккәнекеләр» булып саналалар.

2. Икенче гыйльми караш буенча, «мәккәнекеләр» булып фәкать Мәккә шәһәрендә генә иңгән вәхиләр саналалар. Алар арасына хәтта Һиҗрәт кылудан соң иңгән вәхиләр дә кертелә. Ә «мәдинәнекеләр» булып – фәкать Мәдинәдә генә иңгән вәхиләр саналалар.

Бу карашны «территориаль караш» дип йөртәләр (ягъни, вәхиләрне фәкать ике шәһәр (Мәккә һәм Мәдинә) территориясе белән генә бәйләп аералар).

Безнеңчә, бу карашның тарафдарлары вәхи иңү күренешенең күзгә күренә торган тышкы ягы белән генә чикләнгәннәр – алар, Мәккә территориясенә аның әйләнә-тирәсендәге барча җирләрне кертеп бетерүләренә дә карамастан, «мәккәнекеләр»гә хәтта Минада, Гарафәдә яисә Хөдәйбийядә иңгән вәхиләрне дә кертәләр, ә «мәдинәнекеләр»гә – Өхедтә яисә Сәлгадә иңгәннәрне кертәләр.

Әмма бу караштагы тарафдарларның бер җитешсез ноктасы бар. Аларның карашлары безне ошбу мантыйк кысаларында фикерләргә һәм ошбу нәтиҗәгә килергә мәҗбүр итә – аларның «мәккәнекеләр» һәм «мәдинәнекеләр» дип билгеләгән вәхи төркемнәреннән тагын ниндидер бер өстәмә һәм яңа («өченче» һәм, торышы буенча, урталыкта булган («Мәккә һәм Мәдинә төркемнәре» арасында торган)) вәхиләр төркемен аерып чыгарырга кирәк булачак. Һәм шул яңа булдырылган «өченче төркемгә» барча сәфәр һәм яу вакытларында иңгән вәхиләрне кертергә кирәк булачак (чөнки, алар күзлегеннән карасаң, бу вәхиләрне берничек тә ни «мәккәнекеләргә», ни «мәдинәләрнекенә» кертеп булмый бит). Димәк, шулай булгач, ул ике территориядән читтә иңгән вәхиләрне өстәмә «өченче төркемгә» туплап, шул (әле генә искә алган) «китек» урынга урнаштырасы гына кала инде…

3. Өченче караш буенча, «Мәккә вәхиләре» төркеменә фәкать мәккәлеләргә генә, ягъни Мәккә шәһәрендә яшәүчеләргә карата гына иңгән вәхиләр керә, ә «Мәдинә вәхиләре» төркеменә фәкать мәдинәлеләргә, ягъни Мәдинә шәһәрендә яшәүчеләргә карата гына иңгән вәхиләр керә.

Бу караш файдасына бөек сәхабә булган Ибне Габбасның d : «Әй кешеләр», дигән мөрәҗәгать итү сүзләре Мәккәдә иңделәр, «Әй

мөэминнәр» дигән мөрәҗәгать итү сүзләре Мәдинәдә иңделәр», – дигән сүзләре алына.

Әмма, шуңа да карамастан, без Ибне Габбасның хәбәрен бу карашка дәлил буларак итеп китерүне дөрес дип санамыйбыз. Чөнки, безнең фаразлавыбызча, Ибне Габбас үзенең бу сүзләре белән Коръәнне «мәккәнекеләр» һәм «мәдинәнекеләр» дигән ике төркемгә бүлеп, аларга махсус төшенчәләр бирергә җыенмаган – монда ул фәкать аларның я аерма билгеләрен ачыклап күрсәтергә теләгән яисә ул бу ике төрле Коръән мөрәҗәгатьләрен тәфсирләргә теләгән. Мондый мөрәҗәгатьләрне Коръәндә бик еш очратырга була.

Бу өченче карашны, алдагы ике караш белән чагыштырып караганда, «тар караш» дип кенә бәяләп була – чөнки монда Коръән мөрәҗәгатьләренең барчасы да фәкать билгеле бер конкрет урында гына яшәгән билгеле бер конкрет кешеләргә генә (мәккәлеләргә һәм мәдинәлеләргә генә) кагылышлы итеп карала. Коръәнне, мәккәлеләргә һәм мәдинәлеләргә мөрәҗәгать ителгән аятьләр белән генә чикләп, ике өлешкә берничек тә бүлеп булмый – чөнки анда барлык кешеләргә дә мөрәҗәгать итүләр бар бит.

Икенче һәм өченче карашларга тәнкыйть күзлеге аша караганнан соң, без беренче караштa торучы галимнәрнең позициясен дөреслеккә туры килә дип саныйбыз. Һәм, әйткәнебезчә, күпчелек галимнәр Коръәнне ике өлешкә бүлеп карау мәсьәләсендә нәкъ шушы караштa торалар да инде.

Беренче караш буенча, «мәккәнекеләр» һәм «мәдинәнекеләр» дип аталган төркемнәргә төрле вакытларда һәм төрле шартларда иңгән бик күп төрле вәхиләр керә: «яу вакытында»гылар һәм «мокыйм чагында»гылар, «төнге» һәм «көндезге»ләр, (Мәккәдән Мәдинәгә һәм, киресенчә – Мәдинәдән Мәккәгә) «хәбәр итеп җибәрелгәннәр», «Мәккәдә иңгән «мәдинәнекеләр» һәм «Мәдинәдә иңгән «мәккәнекеләр» һәм баш-

ка төрле вәхиләр. Галимнәрнең ошбу мәсьәләгә багышланган эзләнүләре аз түгел. Бу факт – аларның Коръәнгә карата гаҗәеп игътибарлы булуларын һәм бу эшләрне бик күп төрле юл һәм ысуллар белән башкара алганнарын раслыйлар.

Беренче гыйльми карашка нигезләнеп, «мәдинәнекеләр» дип аталган вәхиләр төркеменә 29 сүрә керә, ә калганнары – барчасы да «мәккәнекеләр» дип саналалар. Кайбер «Мәдинә сүрәләрендә» «Мәккә аятьләре» бар һәм, шулай ук, киресенчә – кайбер «Мәккә сүрәләрендә» «Мәдинә аятьләре» дә. Андый сүрәләр төркеменең атамасы сүрәнең иңә башлаган урыны белән билгеләнә: иңүе Мәккәдә башланган булса – «мәккәнеке» дип атала; иңүе Мәдинәдә башланса – «мәдинәнеке» була.

*(Дәвамы бар)*

*Нуретдин Гыйтырның*

*«Коръән турындагы фәннәр» китабыннан*

# «Әхмәдия» яисә «Кадиания» хәрәкәте

Аларның тарафдарларын әхмәдиләр (кадианияләр) дип атыйлар. Бу төркемгә нигез салучы – Мирза Гуләм Әхмәд Кадиани (1835-1908). Аның төрки чыгышлы булуы хакында мәгълүматлар бар, Һиндстанга XVI гасырда Сәмәркандтан күченгәннәр, бабалары Бабур тарафларыннан. Һиндстанда холерадан вафат булган.

Әхмәдия хәрәкәте XIX гасырның ахырларында барлыкка килә. Бу хәрәкәтнең формалашуы инглиз колониаль администрациясе, Лондон аналитикларының теләктәшлеге һәм катнашы белән барган, Һиндстан һәм Пакыстан бәйсезлек алгач, аннан куылган Әхмәдиләрнең җитәкчелеге Лондон шәһәрендә төпләнә.

Бу хәрәкәтнең барлыкка килүенә Һиндстанда хәнәфи мәзһәбендәге мөселманнарга каршы күтәрелгән христиан протестантлары һәм ваһһабчыларның активлыгы көчәю сәбәп булган. Шушы бәхәсләр һәм канлы көрәшләрнең нәтиҗәсе буларак барлыкка килгән әлеге секта, асылда исламга каршы бөтен көчләрнең эш нәтиҗәсе булып тора. XIX гасырның ахырларында ваһһабчылар үзләренең өндәүләре, үгетләүләре белән бары тик Һиндстанда гына уңышка ирешәләр, үз фикерләрен киң җәелдереп җибәреп, анда бик көчле таралалар. Аларның «җиһад» исеме астында хәрәкәт итүләре, талаулары, террор алып барулары иң беренче чиратта Һиндстандагы мөселманнарга юнәлгән иде. Нәтиҗәдә, гади мөселманнар, бу канлы башбаштаклыктан качып, инглизләр тарафыннан махсус оештырылган әхмәдия төркеменең «җиһадны бетерү» тәгълиматына таба борылалар (Мирза Гуләм Әхмәд Кадиани фикеренчә, мөселманнар инглиз оккупантларында бернинди дә каршылык күрсәтергә тиеш түгел). Шулай итеп, бу ике юнәлеш (ваһһабчылар һәм әхмәдиләр) тарихи яктан бик тыгыз бәйләнгән һәм уртак «конструктор»га ия.

## Әхмәдиләргә хас фикерләр

1. Әхмәдиләр фикеренчә, Әхмәд Кадиани бер үк вакытта мөселманнарның Мәһдие дә, Гайсә һәм Кришнаның икенче килүендәге гәүдәләнеше дә, соңгы илаһи хакыйкать белән бөтен кешелеккә Аллаһы Тәгалә тарафыннан җибәрелгән соңгы илче дә булып тора. Мирза Әхмәдне барлык пәйгамбәрләрдән дә өстен дип, аның иптәшләрен сәхабәләр, хатыннарын «Үммәһәтүл-мүэминин» (Мөэминнәрнең аналары) дип кабул итәләр. Шул рәвешле, алар Мөхәммәднең S соңгы пәйгамбәр булуын танымыйлар.

2. Аларның тәгълиматы буенча, кешеләр, үлгәч, яңа җан һәм тәнгә ия булалар, шул халәттә Кыямәт көнен һәм хөкем итүне көтәләр; аннары я Җәннәткә, я Җәһәннәмгә эләгәләр.

3. Кешеләр, нинди диндә булуларына карамастан, Җәһәннәмдә гөнаһларыннан чистаргач, Җәннәткә керү мөмкинлеген алалар[1].

4. Коръәнгә тәфсир кылуда акылга гына нигезләнүләре, үзгәрешләр кертүләре[2].

5. Әхмәдиягә иярүче хатын-кызларга гади мөселман кешесенә кияүгә чыгуны тыялар.

6. Әхмәдиягә иярүче ирләргә гади мөселман хатын-кызларын хатынлыкка алу ярый, чөнки алар гади мөселманнарны китап әһелләренә тиңлиләр.

7. Хаҗны Мәккәдә түгел, Һиндстанда урнашкан Кадиан авылына, Пәнҗәб, Кашмир җирлекләренә барып кылалар.

---

[1] Әхмәдиләрнең бу тәгълиматын Муса Бигиев тә хуплый. Бу хакта үзенең «Аллаһның рәхмәтенең абсолютлыгы» исемле китабында язып чыга, тик татар галимнәренең кискен каршылыгына очрый. Соңыннан тәүбә итүенә һәм бу фикерләрдән баш тартуына карамастан, татар руханиларының принципиаль позициясе аркасында, мөфти сайлауларында ул һәрвакыт бик аз тавыш җыйган.

[2] Әхмәдиләр Коръәнне рус телендә дә чыгаралар. Бу китап инглиз теленнән рус теленә тәрҗемә ителгән. Карагыз: Священный Коран. Двуязычное издание (переработанное). Подготовил Маулана Мухаммад Али (автор перевода с арабского языка на английский, вступительной статьи и комментариев). Перевод на русский язык подготовил доктор Александр Садецкий (проф. Университета Лаваля). Ахмадийа Анжуман Ишаат Ислам, Лахор, США, 1997.

Ислам илләрендә Әхмәдиләрнең дәгъватлары уңышсызлыкка очрый, чөнки мөселманнар Пәйгамбәребез Мөхәммәднең соңгы пәйгамбәр булуын, аннан соң бары ялган пәйгамбәрләр генә булырга мөмкинлекне беләләр. Шуңа күрә әхмәдия мөселманнарның белеме аз булган урыннарда уңышка ирешә. Хәзер алар Көньяк-Көнчыгыш Азиядә, Балтыйк буе илләрендә, Африкада актив эшлиләр.

Бөтендөнья Ислам Лигасының (Рабита әл-Галәм әл- Исләми) карары (декларациясе)

Бисмилләһир-Рахмәнир-Рахим. Бөтендөнья Ислам Лигасы һиҗри белән 1394 елының 14-18 рабигүл-әүвәлендә (1974 елның апрелендә) Согуд Гарәбстанының Мәккә Әл-Мүкәррамә шәһәрендә, мөселман илләре һәм оешмаларыннан 140 делегат катнашында үзенең ел саен уза торган конференциясен үткәрде. Конференция «Кадиания» хакында түбәндәге резолюцияне бертавыштан кабул итте:

«Кадиания» яки «Әхмәдия» – исламга һәм мөселман дөньясына җимергеч йогынты ясаучы, ялган юл белән үзен ислам төркеме дип атап, дөнья мәнфәгатьләре өчен ислам нигезләрен җимерүне ниятли һәм планлаштыра торган хәрәкәт. Аның ислам кагыйдәләреннән тайпылуы түбәндәгеләрдә чагыла:

1. Нигез салучысының үзен Пәйгамбәр дип атавы.
2. Коръән Кәримнең мәгънәләрен белә торып бозулары.
3. Җиһад бетерелгән дип игълан итүләре.

«Кадиания» иң башта ук Британия империализмы тарафыннан мөселманнар арасына кертелгән һәм аның байрагы астында чәчәк аткан. Бу хәрәкәт мөселман өммәтенә карата тулысынча ялгыш һәм намуссыз мөнәсәбәттә булган. Аның империализмга һәм сионизмга тугрылыклы булу ихтималы зур. Аның исламга каршы көчләр һәм тәгълиматлар белән тыгыз элемтәсе һәм хезмәттәшлеге түбәндәге бозык ысуллар белән башкарыла:

– кадиния хакында ялган фикерләр таратуны алып баручы гыйбадәтханәләр салу;

– исламга каршы нәрсәләрне укыта торган мәктәпләр, институтлар һәм приютлар ачу; төрле телләрдә Коръән Кәримнең аятьләрен бозып аңлата торган тәфсирләр бастыру.

Шушы хәтәр күренешләр белән көрәшү өчен, конференция түбәндәге чараларны тәкъдим итә:

1. Барлык мөселман оешмалары үз илләрендә кадианияләрнең бөтен хәрәкәтләрен игътибар үзәгендә тотарга; үз мәктәпләрен, институтларын, приютларын җитәрлек күләмдә булдырып, аларга мондый оешмалар ачарга юл калдырмаска; мөселманнарга кадианиянең хакыйкый йөзен күрсәтергә, начар ниятләреннән саклау өчен, төрле эш тактикаларын кыскача тасвирларга тиешләр;

2. Аларны кәферләр дип игълан итеп, ислам җәмәгатеннән куарга, изге җирләргә аларның аяк басу мөмкинлеген калдырмаска;

3. Алар белән бернинди дә мөгамәләгә кермәскә; социаль, икътисади һәм мәдәни яктан изоляциягә дучар итәргә тиешләр; Мөселманнарга алар белән никахлану, аларны мөселман зиратына күмү тыелган. Аларга кәферләргә шикелле мөгамәлә кылу кирәк;

4. Барча мөселман илләре Мирза Гуләм Әхмәд Кадианины Пәйгамбәр урынына куючы иярченнәренең эшчәнлеген чикләргә; аларны «мөселман булмаган азчылык» дип игълан итәргә; мәселмам илендә аларга бернинди дә җаваплы вазифа бирмәскә тиешләр;

5. Коръән Кәримгә керткән бөтен үзгәртүләрен мөселман җәмәгатенә игълан итәргә һәм яңадан нәшер итүне тыярга;

6. Аларга охшаган һәрбер төркемгә кадинияләргә карата кулланылган гамәлләр кулланырга тиеш.

*Камил хәзрәт Вәлиуллинның*

*«Исламдагы фирка һәм төркемнәр» китабыннан*

# Хәләл һәм хәрамга мөнәсәбәт

Исламда хәләл һәм хәрам мөселман шәригатенең унбер принцибы белән билгеләнә.

**Беренче принцип – әйберләрнең беренчеллеге**

Беренчел әйберләр, ягъни Аллаһ Тәгалә тарафыннан кеше өчен яратылганнар гөнаһ түгел. Ә инде беренчел булмасалар һәм беренчеллекләренә дәлилләр китерә алмасалар – гөнаһлы. Галимнәр әйберләрнең беренчеллеге турында нәтиҗәне изге Коръән сүзләренә нигезләп чыгаралар: «Улдыр ки, сезнең өчен җирдәге һәрнәрсәне яраткан» («Әл-Бәкара / Сыер», 2:29). «Аллаһның күктәге һәм җирдәге һәрнәрсәне сезгә буйсындырып, сезгә анык һәм яшерен рәхмәтен төшергәнен сизмәдегезмени?» («Локман», 31:20).

Мөхәммәд S әйткән: «Аллаһ кешеләргә бурыч итеп биргәннәрне һәм чикләрен билгеләгәннәрне югалтмагыз. Тыелганнарга кермәгез, әгәр нәрсәдер турында берни дә әйтелмәгән икән, аны да бозмагыз. Һәммәсе Аллаһ ихтыярыннан, шуны онытмагыз һәм бу турыда фикер алышмагыз»...

Әйберләрнең беренчеллеге билгеле әйберләр белән чикләнми, ә бәлки дини вазифалар үтәү белән бәйле булмаган эш-гамәлләрне дә үз эченә ала. Бу нәрсәләрне гореф-гадәт һәм кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләрен кору кагыйдәләре дип атыйбыз. Әйберләрнең беренчеллек принцибы бу гореф-гадәтләрне үтәүне дини кануннар тарафыннан тыелмаган хәләл дип таный. «Нәрсәләрнең тыелганлыгын Ул сезгә аңлатты инде» («Әнгәм / Терлек», 6:119).

Гадәтләр, үз-үзеңне тоту әдәбе һәм кешеара мөнәсәбәтләрне тәшкил иткән кагыйдәләр дини кануннарны яратучы тарафыннан таратылмаганнар. Аларны кешеләр үзләре тудырган. Кануннар Яратучы кешеләрне бары тик әдәпсезлектән арындырган. Әйберләрнең беренчеллеге принцибы – беренчел, ә гадәтләр – икенчел. Кешеләргә алар кирәк булган һәм

аларны кешеләр диннәренә яраштырганнар. Диндәге беренчеллекне Аллаһ кына закон иткән һәм бу беренчеллектә Аллаһ боерган нәрсәдән артык нәрсә юктыр. Аллаһ тыймаган гадәтләр хәләлдер: «Аллаһ сезгә тукланырга дип иңдергәннәрне күрдегезме? Ә сез аның кайсын тыйдыгыз, кайсын рөхсәт иттегез» («Юныс», 10:59).

Бу – төп нигез, кагыйдә. Әгәр бу шулай икән, без сату, бүләк итү, бурычка нәрсә дә булса алу һ.б.ш. кебек нәрсәләрне кешенең җәмгыятьтә үз-үзен тоту кагыйдәләре (нормалары) дип атыйбыз. Бу гамәлләр кешегә ризык, су, кием-салым кебек үк кирәк. Бу гамәлләргә карата шәригать хөрмәтчән һәм яхшы ниятле мөнәсәбәттә тора, ләкин әдәпсез, гөнаһлы һәм эшләнергә тиешле булмаган нәрсәләрне хәрам итеп таныган.

**Икенче принцип – нәрсә ул хәләл һәм нәрсә ул хәрам икәнне билгеләү хокукы бары тик Аллаһка хас**

Ни акыл кешеләре, ни хөкемдарлар, ни патша-солтаннар Аллаһ колларына бернәрсәне дә тыя алмыйлар. Моны бары тик Аллаһ Тәгалә генә эшли ала. Әгәр кем булса да болай эшли икән, димәк, ул үз вазифалары кысасыннан чыккан һәм шәригатьтә баш булу хокукына дошманча мөнәсәбәткә кергән. «Диндә Аллаһ кушмаганны алырга рөхсәт иткән иптәшләре бармы әллә аларның?» («Шура», 42:21).

«Алар үзләренә хуҗа итеп үз галим-голәмәләрен сайлаганнар, ә Аллаһны, аның Расүлен – Мәрьям улын читтә калдырганнар. Ә аларга бит бердәнбер тиңдәшсез Аллаһка гына гыйбадәт кылырга боерылган иде» («Тәүбә», 9:31).

Хәләл һәм хәрам хокукы белән рөхсәтсез файдаланганнар турында Аллаһ Тәгалә болай дигән: «Аллаһ сезгә тукланырга дип иңдергәннәрне күрдегезме? Ә сез аның кайсын тыйдыгыз, кайсын рөхсәт иттегез. Әйт: «Аллаһмы моны сезгә рөхсәт итте, әллә сез Аллаһка ялган ягасызмы?»(«Юныс», 10:59).

Хак Тәгалә әйтә: «Телләрегез ялган итеп тасвирлаганнар турында сөйләмәгез. «Бу – ярый, бу – тыела», – болар Аллаһ турында ялганлау өчен. Ә Аллаһка яла якканнар бәхетле булмаячаклар» («Нәхел / Умарта Кортлары», 16:116). «Нәрсәләрнең тыелганлыгын ул сезгә аңлатты инде» («Әнгәм / Терлек», 6:119).

**Өченче принцип – рөхсәт ителгәнне тыю һәм тыелганны рөхсәт итү Аллаһ теләге белән генә башкарыла**

Рөхсәт ителгәнне тыю мәҗүсиләрдә киң кулланылган. Шуңа күрә изге Коръән мәҗүсиләрнең һәм потчыларның гамәлләрен хупламый, чөнки алар кайбер рөхсәт ителгән эшләрне тыйганнар. Мәсәлән: Коръән тарафыннан рөхсәт ителгән кайбер игенчелек ризыкларын, йорт малтуарын, диңгез бүләкләрен ашамаганнар. Алар надан булганнар. Әгәр дөя биш дөя тудырса һәм соңгысы ата дөя булса, алар ул дөянең колакларын ертып, аңа атланып йөрүне тыйганнар һәм аңа йөк төяп йөртмәгәннәр.

Мондый дөяне үзләренең илләһләренә калдырганнар. Изге Коръән бу тыюны кире каккан. Аллаһ иңдергәнгә һәм Аның Илчесенә сыеныгыз, дип әйткәндә, алар: «Без аталарыбыздан калган нәрсәләргә дә канәгать», – дип әйтәләр. Аталары берни белмичә, туры юлдан бармаган булса да шулай буламы?» («Мәидә / Аш Яулыгы», 5:104). «Әнгам» сүрәсендә ризыкның кайсысы хәләл икәнлеге тәфсилләп аңлатылган (143-144 нче аятьләр).

**Дүртенче принцип – яман һәм зыянлыны тыю**

Укый-яза белмәгән Расүлебез – «Мөхәммәдкә S иярген кешеләргә рәхмәтебез ирешер, кулларындагы Тәүрат, Инҗил китапларында Расүлнең сыйфатлары язылганын табарлар, Мөхәммәд S аларны гөнаһлы эшләрдән тыяр вә саваплы эшләргә өндәр, яхшы-пакь нәрсәләрне аларга хәләл кылыр, зарарлы-пычрак нәрсәләрне аларга хәрам кылыр, аларда булган авырлыкны вә диннәрендәге каты хөкемнәрне бетерер, Расүлгә ышанып, аны зурласалар вә аңа ярдәм итсәләр һәм ул китергән һидаять яктылыгы булган Коръән хөкемнәренә иярсәләр, алар – өстенлек табучылар».

Исерткеч эчемлекләрнең хәрам икәнлеге турында Коръәндә болай диелә: «Йә Мөхәммәд! Синнән хәмер һәм отыш уены хакында сорашалар. Әйт: «Ул нәрсәләрдә зур гөнаһ бар һәм кешеләргә аз гына файдасы да бар, ләкин файдасына караганда гөнаһы һәм зарары зуррак». Янә синнән: «Сәдака кылып нәрсә бирик һәм күпме бирик», – дип сорыйлар. «Үзегездән арткан малны бирегез һәм гафу итегез», – дип әйт. Әнә шулай Аллаһ сезгә Үзенең аятьләрен ачык бәян итә, шаять, фикерләп карарсыз да аңларсыз!» («Әл-Бәкара / Сыер», 2:219).

«Йә Мөхәммәд, синнән сорыйлар, безгә нәрсәне аулау хәләл, дип. Син аларга әйт: «Аллаһ исеме белән бугазланган чиста хайваннар хәләл булды», – дип, «Янә киекләр аулау өчен үзегез өйрәткән ау этләрегез яки ау кошларыгыз тоткан хайваннар, кошлар ите сезгә хәләл булды. Аллаһ сезгә өйрәткән әдәпне ау этләрегезгә яки ау кошларыгызга өйрәтегез: алар тоткан киекләрен өзгәләмәсеннәр һәм ашамасыннар, үзегезгә алып килсеннәр! Сезнең өчен тоткан нәрсәләрен ашагыз, аучы хайваннарыгызны: «Бисмилләһи, Аллаһу әкбәр», – дип җибәрегез! Аллаһтан куркыгыз, үләксәне яки Аллаһ исеме әйтелмичә бугазланган хайван итен ашаудан сакланыгыз» («Әл-Бәкара / Сыер», 2:4).

**Бишенче принцип – хәләлнең хәрамда ихтыяҗы юк**

Хәрам булып түбәндәгеләр санала: алдан ант итүен сорау; рибачылык итү (акчаны процент белән бурычка бирү); һәвәсле уеннар уйнау яки дин турында бәхәсләшү нәтиҗәсендә кулга кергән акчаны файдалану; купшы ефәк, йон, мамык һәм җитен киемнәр кию; азгын тормыш рәвешендә яшәү; исерткеч эчемлекләр эчү һәм шундый матдәләр куллану. Аллаһ Тәгалә сезгә Үзенең хөкемнәрен ачык бәян кылырга һәм Коръән тәрбиясе белән әүвәлге чын хакыйкый мөселманнар юлына күндерергә һәм тәүбә итеп төзәлүебез бәрабәрендә сезне ярлыкарга телидер. Аллаһ – белүче һәм хөкемче. Аллаһ сезнең тәүбә итеп төзәлүегезне тели. Аллаһ сезгә тормышта һәм диндә җиңеллекне тели, ягъни җиңел яшәргә, динне

җиңел тотарга юл күрсәтә. Кеше, әлбәттә, зәгыйфь, көчсез итеп яратылды («Нисә», 4:26, 28).

**Алтынчы принцип – хәрам кылуга юл куйган нәрсә ул үзе дә хәрамдыр**

Ислам билгеләгәнчә, тыелган гамәл кылынса, шул гамәлгә илткән алшартлар һәм сәбәпләр үзләре дә тыюлы. Мәсәлән, азгынлык һәм фәхешлек хәрам икән, аларны булдырган нәрсәләр дә шулай ук хәрам. Алар арасында хатын-кызның әдәпсез кыяфәте, гөнаһлы гамәле, хатын-кызны ялангач сурәтләгән рәсем, йөгәнсез холык, кешенең үз-үзен тотуы һ.б.ш.

**Җиденче принцип – гөнаһта хәйләләү үзе гөнаһ**

Ислам билгеләгәнчә, хәрам кылуга этәргән алшартлар хәрам икән, хәрам кылуга илткән хәйләле адымнар да хәрам. Әгәр кешеләр әдәпсез сәнгать белән шөгыльләнәләр икән, димәк, алар аның аша саф булмаган акча эшлиләр. Исерткечләрнең исемнәрен алыштырсалар да, аны татымый калалар, дигән сүз түгел. Бу ике гамәлнең гөнаһлылыгы аларның гадәти һәм көн саен эшләнә торган булуында. Безнең көннәрдә әдәпсез биюне сәнгать диләр, аракыны – спиртлы эчемлек дип атыйлар, ә ришвәтчелек белән рибачылыкны файдалы һәм кирәкле эш, диләр. Ләкин моңа карап аларның асылы үзгәрми.

**Сигезенче принцип – яхшы ният хәрам кылуны акламый**

Ислам яхшы ниятләрне, изге гамәлләрне кадерли. Бу Ислам кануннарында чагылган. Кем булса да исән калу өчен, сәламәтлеген ныгытып, аннары Аллаһ каршында, Мөхәммәд Пәйгамбәр S өммәте алдында үз бурычын үтәү өчен, тыелган ризыкны ашый икән, бу очракта аның ашы һәм Аллаһка хезмәте мактауга лаек санала. Диндар кешенең һәр гамәле үзендә күпмедер ният йөртә. Әмма гөнаһлы гамәл һәрвакыт гөнаһлы, гәрчә аны кылган кеше нинди генә яхшы нияттә булса да.

Ислам яхшы гамәл кылу өчен гөнаһтан файдалануны рөхсәт итми. Киресенчә, Ислам нинди генә булса да яхшы гамәл кылынганда арынуга,

сафлануга омтылуны хуплый. Максатка ирешү өчен яхшы гамәл дә, яман гамәл дә ярый дигән принципны Ислам кабул итми. Хакыйкатькә фәкать арыну юлы белән генә ирешергә ярый.

**Тугызынчы принцип – әгәр гөнаһ кылудан сакланасыз икән, шикләнгән нәрсәдән тыелыгыз**

Әгәр теге яки бу гамәлне кылыр алдыннан диндар кеше аның хәләл яки хәрам булуыннан шикләнә икән, монда шуны белергә кирәк ки: ният белән гамәл арасында мөһим булган элемент – шикләнү бар.

Ислам диндар кешене, әгәр ул шикләнсә һәм кыласы гамәлнең гөнаһ булуыннан курыкса, ул эштән тыелырга куша. «Аллаһ сезгә нәрсәләрнең хәрам икәнен ачык аңлатты» («Әнгәм / Терлек», 6:119).

**Унынчы принцип – хәрам һичнинди искәрмәләрсез һәркем өчен гөнаһтыр**

Ярамаган эш һәм гамәлләрне тыю һәр мөселман өчен мәҗбүридер. Ислам хәләл белән хәрамда гарәп һәм гарәп булмаган халыкларны аермый. Аклар өчен яки негрлар өчен аерым-аерым тыелган эшләр юк. Шулай ук җәмгыятьнең аерым төркемнәре өчен: галимнәр, патшалар, аксөякләр өчен махсус рөхсәт ителгән нәрсәләр юк. Ислам һәм аның канун-законнары һәммә кешеләр өчен дә уртак һәм бертөрле. Аллаһ һәркем өчен бер. Аллаһ кешеләр өчен хәләл иткән нәрсә – ул яраклы һәм гөнаһсыз дип санала. Ә Аллаһ хәрам дип таныган нәрсә – кыямәт көненәчә һәркем өчен тыелган. Мәсәлән, урлау хәрам санала һәм бу урлаучының мөселман булуына яки булмавына карамый. Шулай ук әйбере урланган кешенең дә нинди диндә булуына карамый.

«Әлбәттә, Без сиңа Коръәнне хаклык өчен иңдердек, кешеләр арасында Аллаһ теләгәнчә гадел хөкем итмәклегең өчен. Шулай булгач, һәрбер хәлдә хыянәтчеләрне яклап, алар файдасына дәгъвачы булмагыл!

Янә Аллаһның ярлыкавын сора! Әлбәттә, Аллаһ ярлыкаучы, рәхмәт кылучы. Янә үзләренә хыянәт иткән кешеләрне һәм ялганчыларны яклап

тартышма, аларның эшен дөрескә санама! Аллаһ хыянәтче, гөнаһлы кешеләрне һич тә сөйми. Хыянәтче кешеләр урлаган әйберләрен яки башка яман эшләрен кешеләрдән яшерәләр, ләкин Аллаһтан яшерә алмаслар.

Йә сез, ошбу хыянәтче, ялганчы монафикъларны яклаучылар! «Аларның гаебе юк», - дип хакка каршы тартыштыгыз дөньяда. Ахирәттә аларны яклап, Аллаһ белән кем тартышыр? Яки аларны химәя кылыр өчен кыямәт көнендә алар файдасына кем вәкил булыр? Юк! Аларны яклаучы булмас!» («Нисә / Хатыннар», 4:105-109).

Коръәндә шулай ук мондый нәрсә дә ачыкланган. Әгәр кайбер кешеләр башка кешеләргә карата хыянәтне яраган нәрсә дип санасалар да, бу – барыбер гөнаһтыр.

**Унберенче принцип – нужа хәрам кылуны рөхсәт итә**

Ислам тыелган гамәлләрне һәм хәрамга этәргән нәрсәләрне төгәл билгеләгән. Ислам тормыш кыенлыкларын, кешенең җитешсезлекләрен исәпкә алмаучан һәм диндарларга артык кырыс таләпләр куйган кебек тоела. Ләкин бу алай түгел. Ислам кайбер тыюларны тотмаска рөхсәт итә, ләкин үзенә үлем янаган тормыш таләбе генә моңа сәбәп була ала. Мәсәлән, Ислам үләксә, кан, дуңгыз ите һәм «бисмиллаһ»сыз бугазланган малны ашауны тыя. Әмма тормыш бу таләпне бозарга мәҗбүр итсә, бу – гөнаһ түгел. Бу турыда Коръәндә болай дип әйтелгән: «Әлбәттә, Аллаһ сезгә үлгән хайван итен, бугаз канын, дуңгыз итен һәм Аллаһтан башка затның исеме белән бугазланган хайван итен хәрам кылды. Берегез һич ашарга тапмаса, ачка үлү ихтималы булганда, җан саклау өчен җитәрлектән артыгын ашап, чиктән үтеп китүдән башка ашаса, гөнаһ юктыр. Мондый хәлләрдә Мин ярлыкаучымын, рәхимлемен» («Әл-Бәкара / Сыер», 2:173).

*Габделхак хәзрәт Саматовның*
*«Шәригать: вәгазь, хөкем, фәтва,*
*җавап-саван, киңәшләр» китабыннан*

# Мирас

# Мәрҗанинең хаҗ сәфәре

## Мәдинә. Мәккә. Хаҗдан кайту.

*(Дәвамы. Башы 17 нче санда)*

Болар арасыннан шәех Габделҗәлилнең кайбер шигырьләрен дә язып алган. Шәех Мозаһһарны ишанлык юлында кардәш булган шәехләреннән саный («Мокаддимә», 28 б.). Әдип мелла Зыяэддин Мәрҗанинең ихлас дусларыннан булып, аның хакында шигырьләре дә бар, Мәрҗанинең төрле китапларында исеме әйтелеп үтелгән. Шәйхел-ислам Хәсән Фәһими хакында «Вафийәтел-әсляф»та ошбу сүзләрне яза: «Хәсән бине Госман Фәһими Теркиннең иң зур галимнәреннән, солтанның укытучысы, ике мәртәбә шәйхел-ислам булып торган, соңында Мәдинәгә сөрелгән. Бу зат илә Мәдинәдә кабат күрешеп, мәҗлестәш булдым. Мәдинәдән Мәккәгә барганда икебез бертигез булып, юлда да сөйләшеп бардык, һәммә сүзләреннән күп китап укыганлыгы, һәр нәрсәдән хәбәрдарлыгы күренеп тора иде. Бу затның кулына «Нәзурә», «Хикмәте бәлига», «Әлма-из-зәлял фи шәрхил-Җәлял» китаплары төшеп, бик яратып, ләззәт илә укыган. Русия эчендә яшәүче татарлар арасында да никадәр зур галимнәр җитешкән, дип сөйләп йөргән. Татарның хаҗи вә галимнәреннән үзенә очраган кешеләрдән дә һәрвакыт сорашып торган, ике арада хәбәрләшүләребез дә бар иде. Ошбу Хәсән Фәһими хәзрәтләре сиксән яшенә ирешеп, 1298/1881 елда вафат булды».

Мәдинәдән Мәккәгә сәфәре хакында Мәрҗани ошбу сүзләрне яза: «Без Мәдинәдә вакытта Димәшкъ кәрваны килде. Аларны каршы алырга бөтен Мәдинә халкы вә Мәдинәдә булган гаскәрләр, һәм Мәдинәнең хакиме Сафа паша да чыккан иде. Каршы алу мәҗлесе бик мәһабәт вә олуглык белән оештырылган иде. Гаскәрләр туплар атып, музыка уйнап

каршы алдылар. Сафа паша илә күрештем. Хәзерләнгән мәҗлескә утырып, кофе белән сыйлады.

Ошбу Димәшкъ кәрваны илә бергә без дә Мәккәгә сәфәр иттек. Кәрванда хаҗ әмире Сәгыйдь паша иде. Кәрван илә байтак гаскәрләр булып, алар туктау-китү өчен һәм һәр намаз вакытлары өчен туп атып бардылар. Кичләрен каравыл тордылар.

Без Зөлхоләйфә (Зөлхоләйфә бу көндә «Биәр Гали» дип билгеледер) исемле урында ихрам кидек. Безнең илә бертигез дамелла Фәхреддин ән-Норлатый, Ташбилге имамы мелла Әхмәдсафа, Бүздәк имамы мелла Һидайәтулла һәм барча Иран хаҗилары ихрам киде. Мелла Фәхреддин, Мәдинәдә сөйләшкәндә, минем сүземне кабул иткәне юк иде. Ләкин гамәлдә безгә иярде.

Күпчелек кешеләр Зөлхоләйфәдә ихрам киюне бөтенләй туктатып тора, ул шафигый хаҗиларының хаҗ кылырга керешү урыны дип шикләнеп карыйлар. Мәдинә халкының күпчелеге димәшкълеләрнең ихрамга керү урыны булган Җөхфә турысында Рабигъ исемле авылда ихрамга керәләр икән.

«Мәккә юлында бик күп авыл вә станцияләрдән үттек» (Мәрҗани бу станцияләр вә авылларның исемнәрен, ике арада ничә сәгать вә ничә минут барганнарын, күпчелек авылларның төзеклекләрен яза барган. Без исә болардан кайберләрен кыскартып кына күчерәбез).

«Юлда Җәдидә исемле урыннан уздык. Анда бик күп хөрмә бакчалары бар. Бу авыл яныннан үткәндә, гаскәрләр җыелып, кулларына мылтык алып, музыка уйнап үттеләр. Ошбу көн бик кызу булды. Кап эчендә булган каты шәмнәр эреде. Тазлар тота алмаслык булып кызды.

Юлда Бәдергә җиттек. Бәдер диңгезгә якын булганлыктан, гарәпләр балыклар китереп сатып йөрделәр. Бәдердән узгач, уң якта булган таулар бетте. Сул якта булганнары ерагайды. Аяк асты комлык булды. Җил илә диңгез һавасы килә иде.

Аннан соң Рабигъка җиттек. Ире вә хатын-кызы, барчасы кәрванга каршы чыкканнар иде. Гаскәр музыка уйнап, туп атып керде. Рабигъ зур авыл булып, гүзәл хөрмә бакчалары, яхшы таш йортлары вә базары бар. Мәдинә халкының күбесе монда ихрамга керәләр.

«Биөр Гасфан»да (Гасфан коесы) булдык. Суы бик яхшы һәм күп икән. Гарәпләр, Расүлүллаһ S төкергән кое, диләр.

«Фатыйма үзәне» исемле урынга җитүгә, күк күкрәп, яшен яшьнәп, азрак яңгыр яуды. Мәккәгә иң якын соңгы тукталыш иде. Аннан китеп, Мәдинәдән чыкканнан 13 нче көндә (7 Зөлхиҗҗәдә) Мәккә-и Мөкәррәмә, Аллаһ шәһәренең изге жире вә Ислам кыйбласына кердек.

«Мәккәгә баргач, иң элек тиешле булган хаҗ эшләрен вә гыйбадәтләрен үтәп, дүрт көннән соң, өченче Зөлхиҗҗәдә ихрамнан чыктык. Иран хаҗилары Гарәфәттә бездән бер көн артык торып, унберенче Зөлхиҗҗәдә ихрамнан чыктылар. Гарәфәт, Мөздәлифә кеби урыннарда булганда, Шәриф Габделмоталлаб хәзрәтләре солтанәт вә мәһабәт йөрде. Барган урыннарында туплар атылып, гаскәрләр уйнап каршы алдылар».

«Мәккәдә вакытыбызда мәшһүр урыннарны вә мәшһүр кешеләрнең каберләрен барып күрдек. Расүлүллаһ вә хәзрәти Гали вә хәзрәти Фатыйманың туган урыннарын, хәзрәти Әбүбәкер вә хәзрәти Хәдичә йортларын, ислам диненең башында Расүлүллаһ торган вә хәзрәти Гомәр ислам кабул иткән Әркам бине Әбел-Әркам йортларын барып күрдек. Бер көн кич ястүдән соң, Кәгъбәтулла эченә кереп, ике рәкәгать намаз укып, дога кылу бәхетенә ирештек. Кәгъбәнең багана вә диварларын карасам да, әдәплелек аркасында түшәменә карый алмадым.

Мәккә-и Мөкәррәмәдә голәмә вә олуг шәхесләрдән байтак кешеләр илә күрешеп, кара-каршы сөйләшеп утырдык. Бер көн энем Садреддин, вә мелла Зыяэддин әт-Тархани вә башка берничә кеше илә бергә «Изһарел-хак» авторы шәйхе Рәхмәтулла бине Хәлил әр-Рахман әл-Һинди хәзрәтләренә бардык. Бик шатлык вә разыйлык илә кабул итеп, байтак

сөйләшеп утырды. Чәй илә сыйлады. Бик хуш мәҗлес булды. «Сәййди» сүзе илә дәшеп сөйләште. Үз әсәрләреннән бер нөсхә «Изаләтел-әүһам» һәм биш нөсхә «Изһарел-хак» китабы бүләк итте. Артык нөсхәләрне лаеклыларына бүләк итәрсез, диде. Тагын да утырырга теләп, кичектереп торуны сораса да, безнең сәфәр вакытыбыз якынлашу сәбәпле, рөхсәт сорап чыктык.

Мәккәдә вакытыбызда Мөхәммәд бине Әхмәд әл-Кунияви, «сезнең илә сөйләшеп утырырга омтылдым» дип, үзе эзләп килеп сөйләшеп утырды. Казан вә Бохара галимнәре вә башка хәлләр хакында күп нәрсә сорашты. Хәрәмәйндә хаҗ вакытында кичтән әүвәл шәм яндыралар. Бәйтуллаһта төн буенча яндырылып, иртә намазыннан соң гына сүндереләдер. Мәккәдә иртә намазын башта шәфигыйлар, аннан соң мәликиләр, аннан соң хәнбәлиләр, соңыннан хәнәфиләр укыйлар. Хәнбәлиләр бик аз. Мәккәдә генә иртә намазын үзләре җәмәгать булып укыйлар. Башка намазларда хәнәфиләргә ияриләр. Мәликиләр дә күбрәк намазларны хәнәфиләргә ияреп укыйлар. Мәликиләр камәт сүзләрен берәр генә әйтеп, намазның аягүрә үтәлә торган өлешендә кулларын җибәреп торалар. Шәфигыйлар да камәт сүзләрен берәр генә әйтеп, күкрәк астына кулларын куялар, тезләргә таянганда һәм тезләрдән күтәрелгәндә кулларын күтәрәләр, кычкырып укыла торган намазларда «бисмилләһ»не кычкырып әйтәләр, иртә намазында икенче рәкәгатьтә тезләнүдән соң «Кунут» догасын кычкырып укыйлар. Иран халкының ничек намаз укулары үткәндә язылды».

Монда күренәдер ки, Мәрҗани хәзрәтләре Мәккә вә Мәдинә кеби исламның мәркәзе булган урында дүрт имамның аерым-аерым җәмәгать булып намаз укуларына, гыйбадәт рәвешләрендә дә бик аз гына аерма булуга игътибар иткән. Мәрҗани аларның аерылып укуларын яратмый, бөтен яклардан җыелган мөселманнар бергә җыелып, һәрвакыт бер имам артында намаз укулары тиеш иде, дип сөйли торган булган.

Бу мөнәсәбәттә «Мокаддимә» китабында да ошбу сүзләрне яза: «Яңа гадәтләрдән бере Мәккә вә Мәдинәдә дүрт мәзһәбкә дүрт мәкам булуыдыр. Бу эш Һиҗрәттән 815 елда башланып, шуннан бирле дәвам итеп килә. Бу эш диндә шәригать кушкан җыелып уку вә җәмәгатьне күбәйтү хикмәтенә каршыдыр».

Монда кадәр язылганнар илә Мәрҗани хәзрәтләренең хаҗы вә Мәккәдә булган йомышлары тәмам булып, кайтырга хәзерләнә башлаганнар. Кайтулары хакында Мәрҗани яза: «Мәккәдә унөч көн торганнан соң, сәфәргә хәзерләнеп, Мәккә белән саубуллашып аерылдык. Бер сәгать чамасы җәяү бардык. Икенче көнне Җиддәгә җитеп, Госманлы дәүләтенең «Кайсарийә» исемле пароходына утырып хәрәкәт иттек.

«Турсина»га җитүгә, хаҗиларны карантинга чыгардылар. Без икенче класска утырган идек. Безне чыгармадылар. Ике көннән соң кузгалдык. Юлда бер кызылбаш (фарсы), безнең бүлмәбезгә кереп, үзенең Коръәнен ачып, бер аяте Кәримәнең тәфсирен сорады. Аңлатканны кабул итеп чыгып китте. Бу зат үз мәзһәбләренчә намазны яхшы кайгыртып, догаларны дөрес укып, Коръән аятьләрен кирәкле урыннарда укыганлыгыннан галим кеше дип исәпли идем. Бездән ни өчен сораганының сәбәбе мәгълүм булмады.

Юлда Сүәйес, Исмәгыйлия, Порт Сәйедтән үттек. Исмәгыйлиянең гүзәл бакчалары, Порт Сәйеднең матур бинаалары игътибарыбызны җәлеп итте. Юлда, диңгез буенда бик күп бакча вә авыллар күренеп калалар».

«Измиргә җитүгә, янәдән карантинга чыгардылар. Безнең пароходыбызда сәламәтлек өстенлек итсә дә, бездән алда килгән бер инглиз корабында, хаҗиларга бозык диңгез сулары эчереп килүләре, ал арны яңгырдан сакламаулары сәбәпле, хаҗиларга суык тиеп, кайберләре авырганлыктан, карантинга чыгарганнар. Аларны чыгарганнан соң, безнең «Кайсарийә» пароходындагы хаҗиларны да карантинга чыгардылар.

Монда да кайбер кешеләр илә мин чыкмый калдым. Ике көннән соң без кузгалдык. Инглиз пароходы унбер көн торган дип ишеттек.

Юлда вакытыбызда 14 нче мөхәррәмдә ай тәмам тотылды. Без «Хөсүф» («Ай тотылу») намазы укыдык. Безнең илә бергә булган кызылбашларның да Хөсүф намазы укулары мәгълүм булды. Айның тотылу һәм ачылуын бинокль берлә карап тордым.

Безнең күрше бүлмәдә Мөхәммәд исемле бер кызылбаш имамы бар иде. Кыяфәт вә киеме гарәпкә охшаса да, теле төрки иде. Үзе, шәфигый мәзһәбендә, дигән иде. Ләкин сөнниләргә дә, шәфигыйларга да катнашмады. Бервакыт «Мокаддимәти ибне Хәлдун» укып утырганын күрдем. Миннән «бу китап сездә бармы?» дип сорады. «Нөсхәсе бар» дигәнемә «монда сәхабәләр үзара килешмәүчелеге хакында бер сүз бар, шуны төшенә алмадым» дип миңа күрсәтмәкче булып актарса да, таба алмады. Бу кеше үзен зур тота, азрак гыйлеме дә булырга охшады.

Сәфәребезнең егерменче көнендә сәламәтлек илә Истанбулга килеп җиттек. Аннан Казанга телеграм бирдек».

Мәрҗани хәзрәтләре хаҗдан кайтканда Истанбулда фәкать дүрт көн торган. Иптәшләре кайтырга ашыкканнар. Мәрҗани дә, алардан каласы килмичә, кайтырга мәҗбүр булган. Мәрҗани үзе дә: «Истанбулда кайбер йомышларым да калды. Берничә көн калсам, солтан хәзрәтләре илә дә күрештермәкче булганнар иде. Ләкин, солтан берлә күрешәм дип, юлдашларымнан калуны кирәкле дип күрмәдем, кайтырга читен булыр дип уйладым», – дип сөйләгән. Ошбу дүрт көн эчендә Истанбулның кайбер мәдрәсәләрен барып күргән. Тарих, җәгърафия, математика фәннәреннән китаплар сатып алган. Әүвәлге мәгариф министры Мөниф паша, Шәриф Гаун, Әхмәд Әсгадь, шәех Сөләйман әфәнде вә болардан башка берничә затлар илә күрешкән. Күрешүләре вә утырып сөйләшүләре хакында ошбу сүзләрне яза: «Хаҗдан кайтканда Мөниф пашага очрап, озак сөйләштем. Күркәм мәҗлесле, бик инсафлы, камил зат икән. Биш

төрле тел илә сөйләшергә оста икәнен сөйләде. Гарәп, фарсы телләре илә үз телләре кеби җиңел сөйләшергә сәләтле икәнен без дә күрдек. Сигез вә дүрт яшендә булган угыллары да фарсыча беләләр икән. Безнең алдыбызга китереп, алар илә фарсыча сөйләшеп карады. Олы углына фарсыча: «Әфәнденең кулын үп», – диде. Углы килеп кулымны үпте.

Пашаның йортында зур аю аяк үрә басып тора иде. Русия императоры аткан аю, диде. Император Төркиянең Петербургтагы илчесе Хәлил пашага бүләк итеп, Хәлил паша Мөниф пашага бүләк иткән, имеш. Йортының түбән катында аш ашадык, югары катында кофе вә чәй эчтек. Йорт җиһазлары бик мәһабәт, гаять гүзәл булып, бик нәфис эшләнгән алтынлы өстәл вә урындыкларны күреп хәйран калдык».

«Йортында мәрмәрдән эшләнгән бер хатын сурәте күрдек. Безнең белемебезне сынар өчен булса кирәк: «Бу сурәт ни бәһа торыр?» – дип сорады. Соңыннан үзе: «Ясаучысы нәфис сәнгатькә оста кеше. Шунлыктан ясаган сурәте дә җиде мең сум тора», – диде. Безнең илә күбрәк гарәпчә вә фарсыча, кайчак төркичә сөйләште. «Сиррил-ләййал фил-кальб вәлиб-даль», «Бразилия сәяхәтнамәсе» исемле китаплар бүләк итте. Мин дә кайбер әсәрләремне бүләк иттем. Без анда вакытта паша хозурына кереп чыгучы берничә могтәбәр вә олуг затларны күрдек. Шулардай берсе солтан Габделмәҗиднең кияве, диделәр. Паша илә бик яхшы сөйләштек. Киткән вакытыбызда: «Нинди китап хаҗәт булса да, хат илә аңлатсагыз, тоткарлыксыз җибәрербез», – диеп ишеккә кадәр озата килде.

Шуннан соң пароход илә Одессага, аннан тимер юл илә Нижнийгә, аннан почта аты вә чанасы илә Казанга сәфәр иттек. Нижнийдән чыканыбызны телеграм берлә Казанга хәбәр иттек. Юлда Зөя вә Ослан-га бик күп дуслар вә шәкертләребез каршы алырга килгән иде. 1298 ел, 30 мөхәррәм/1880 ел, 20 декабрьдә икенде алдыннан Казанга кайтып җиттек. Беренче мәчет ихатасында дуслар, юлдашлар вә шәкертләр берлә

күрештем. Мәчеткә кереп, нафилә вә икенде укып, йортыбызга кайтып, туганнарым берлә сәламәт күрештем».

*Мәрҗани хәзрәтләре хаҗ сәфәре хакында ике җыентык язган. Берсе фәкать Мәккә вә Мәдинә хакында булып, өстенә «Рихләти әзлиләнам илял-бәйтил-Хәрам» дип язып куйган. Җыентыклардан икенчесе, мөхтәрәм Ризаэддин хәзрәт тарафыннан сайлап алынып, «Рихләтел-Мәрҗани» исеме белән 1898 елда басылган иде. 120-130 бит чамасы булган җыентыкларында халык өчен зур әһәмияте булмаган нәрсәләр дә язылып, аларны мәҗмугабездә тулаем бастыру мөмкин булмаганлыктан, алардагы әһәмиятле нәрсәләрне сайлап вә кайбер хатирәләр өстәп, хаҗ сәфәре хакындагы ошбу мәкалә язылды.

*Шәһәр Шәрәф*

*1332 ел, 23 зөлкагъдә/1914 ел, 13 октябрь*

*«Мәрҗани» фәнни-популяр җыентыгыннан*

# Пәйгамбәрләр тарихы

### Һуд а

Йәмән диярендә Хадрамаут дигән җиргә якын җирдә Гад кавеме бар иде. Бу кавем Аллаһка гөнаһлы булдылар, потларга сәҗдә кылдылар. Бу халыкка Аллаһы Тәгалә Һудны а пәйгамбәр итеп җибәрде. Һуд а боларны хак дингә чакырды, могҗизалар күрсәтте иде. Ил хатыннары бала тудырмады, чишмәләренең сулары киселде, хайваннары үлеп бетте. Өч ел бик каты ачлык булды. Шулай булса да, бу халык хәзрәти Һудка ышанмадылар, бик азы ышанды. Соңра ул халыкка Аллаһы Тәгалә ачуланып, аларны бер каты җил белән һәлак кылды. Хәзрәти Һуд үзенә иман китергән кешеләр белән Мәккәгә китеп, гомерен Аллаһка гыйбадәт илә Мәккәдә кичерде. Кабер шәрифе Мәккәдәдер.

### Хәзрәти Салих а

Хәзрәти Салих а Шәм белән Хиҗаз арасында Хиҗер дигән урында булган сәмүд халкына пәйгамбәр булды. Сәмүд кавеме дә гад кавеме кебек туры юлдан чыгып, потларга гыйбадәт кылалар иде. Хәзрәти Салих а бу халыкны күп еллар иманга чакырды, бик азы иман китерде, соңра бер көн хәзрәти Салихны оятлы итик дип («хак пәйгамбәр булсаң могҗиза күрсәт») диделәр. Хәзрәти Салих «Нә истәрсез?[1]» – диде. Бер каты ташны күрсәттеләр, шул таш эченнән бер дөя чыгар, эчендә баласы да булсын, диделәр. Аллаһның әмере буенча шул таштан дөя чыкты һәм бала тудырды. Моны күргәч, дәхи бераз кеше иман китерделәр. Салих а кавеменә дөяне бугазламагыз диде. Салихка а дошман кәферләр дөяне бугазладылар, баласы анасы чыккан таш эченә качты. Ул халыкны Аллаһы Тәгалә күктән бер тавыш җибәреп һәлак кылды. Салих а үзенә

---

[1] Ни теләрсез?

иман иткән кешеләр белән котылып, Мәккә-Мөкәррәмәгә барып, гомерен шунда үткәрде. Салих а бик ак йөзле, мәһабәт кеше иде. Хәзрәти Салих а илле яшендә икән вафат булды.

## Хәзрәти Ибраһим а


٧

ایکنچی باب

حضرت ابراهیم علیه السلام

ابراهیم علیه السلام طرفاندن منك سکسان بر یل صوڭ بابل یرنده طوغدی
اول وقتلرده بابلده توره تورغان کلدانیلر یولدزغه عبادت قیله‌لر
ایدی الله تعالی آلارنی حق دینگه کوندرمك ایچون ابراهیم علیه السلامغه
پیغمبرلك بیردی واوتز کاغد کتاب بیردی.
حضرت ابراهیم قومینی هم بابل ننك حاکمی بولغان نمرودنی حق دینگه
اوندادی حضرت ابراهیمگه اشانمادیلر بابل حاکمی نمرود بیك الوغ اوت
یاقدیروب حضرت ابراهیمنی مانجنیق برله اوتقه آتدی الله تعالی پیغمبرنی
ساقلادی اوت الله ننك حکمی برله بر بخشی باغچه بولدی بو معجزه‌نی کوروب
بعضیلر ایمان کیتوردیلر حضرت ابراهیم اوزی ننك ایو جماعتاری برله
حران طرفلرینه آندن مصرغه مصردان شامغه کیتدی آندن صوڭ الله ننك
امری برله مکه‌گه باروب اوغلی حضرت اسماعیل برله کعبهٔ معظمه‌نی یاصادی
سنت قیلمق میوق کیسمك استره توتوق صاچ وصقال تارامق مسواك توتمق ترناق
کسمك مسافرلرگه حرمت ایتمك حضرت ابراهیم ننك سنتاریدر قبر شریفی
قدس شریف یاننده خلیل الرحمن دیگان اورنده‌در،

Ибраһим а туфаннан мең сиксән бер ел соң Бабил җирендә туды. Ул вакытларда Бабилдә тора торган кәлдәниләр йолдызга гыйбадәт кылалар иде. Аллаһы Тәгалә аларны хак дингә күндерер өчен Ибраһимга а пәйгамбәрлек бирде вә утыз кәгазь китап бирде.

Хәзрәти Ибраһим а кавемен һәм Бабилнең хакиме булган Нәмрудны хак дингә өндәде. Хәзрәти Ибраһимга ышанмадылар. Бабил хакиме Нәмруд бик олуг ут яктырып, хәзрәти Ибраһимны мәнҗәникъ[1] белән утка атты. Аллаһы Тәгалә пәйгамбәрне саклады, ут Аллаһның хөкеме белән бер яхшы бакча булды. Бу могҗизаны күреп, бәгъзеләр иман китерделәр. Хәзрәти Ибраһим үзенең җәмәгатьләре белән Хиран тарафларына, аннан Мисырга, Мисырдан Шамга китте. Аннан соң Аллаһның әмере белән Мәккәгә барып, углы хәзрәти Исмәгыйль белән Кәгъбә-и мәгъзуманы ясады. Сөннәт кылмак, мыек кисмәк, истирә тотмак, сач вә сакал тарамак, мисвәк тотмак, тырнак кисмәк, мосафирларга хөрмәт итмәк – хәзрәти Ибраһимның сөннәтләредер. Кабер шәрифе Коддус шәриф янында, «Хәлилүр-рахмән» дигән урындадыр.

## Хәзрәти Лут а

Хәзрәти Лут Ибраһимның а кардәшедер. Хәзрәти Лут Ибраһим а илә бергә Шамга, аннан Мисырга барды. Ибраһим а Фәләстыйнга кайтканда, хәзрәти Лут садум халкын хак дингә өндәргә җибәрелде. Садум халкы адәм балаларыннан ул вакытка кадәр һич кеше кылмаган кабахәт эшне кылалар иде. Хәзрәти Лут аларны иманга өндәде, ул кабахәт эшләрне ташлатырга бик тырышты. Кавеме хәзрәти Лутны тыңламадылар, кабахәт эшләрен арттырдылар. Хәзрәти Лут Аллаһтан сорады: «Йә Рабб, бу залим халыкның арасыннан коткар», – диде. Аллаһның әмере белән хәзрәти Җәбраил боларның шәһәрләрен астын-өскә әйләндереп һәлак кылды. Өсләренә күктән ташлар яуды. Хәзрәти Лут үзенә иман иткән кешеләр

1 Мәнҗәникъ – катапульта.

белән араларыннан чыгып, хәзрәти Ибраһимның янына килде, гомерен шунда үткәрде.

### Хәзрәти Исмәгыйль а

Исмәгыйль а хәзрәти Ибраһимның улыдыр. Хәзрәти Ибраһимның хатыны Сараның баласы булган. Хәзрәти Сара үзенең Һаҗәр исемле җариясенең баласы булмасмы дип, хәзрәти Ибраһимга биргән. Һаҗәрдән бер улы булган, исемне Исмәгыйль куйган. Хәзрәти Сара Һаҗәргә ачуланды, аның белән бергә торырга сабыры калмады. Хәзрәти Ибраһим Аллаһның әмере буенча, хәзрәти Исмәгыйль илә анасы Һаҗәрне Мәккәгә илтеп куйды. Хәзрәти Исмәгыйль Мәккәдә үсте, ул вакытта Йәмәннән килгән Җүрһүм халкы Мәккә тирәсендә торалар иде. Хәзрәти Ибраһим аларга катышты, алардан кыз алды, уникегә кадәр баласы дөньяга килде. Хәзрәти Исмәгыйль үзе гыйбрәни[1] иде, гарәпчә сөйләшә иде, үзеннән соң килгән гарәп мөстәгрибә[2] халыкның әгълә[3] бабасы булды. Аллаһы Тәгалә Исмәгыйльне а Йәмән вә Гамәлика халкына пәйгамбәр итеп җибәрде. Хәзрәти Исмәгыйль кавемен хәзрәти Ибраһимның шәригатенә илле елга кадәр өндәде. Исмәгыйльнең а балалары бик күп иде, корәеш халкы хәзрәти Исмәгыйльнең балаларыдыр. Исмәгыйльнең а балалары Мәккә тирәсенә җәелделәр, кайсы җиргә барсалар да, өстен булдылар, Гамәлика халкын торган җирләреннән сөреп чыгардылар. Хәзрәти Исмәгыйль йөз утыз дүрт яшендә вафат булды. Кабер шәрифе Хиҗер дигән җирдә, анасы Һаҗәр янындадыр.

---

1 Гыйбрәни – еврей.

2 Мөстәгрибә – арабист.

3 Әгълә – бөек.

## Хәзрәти Исхак ә

Һаҗәрдән Исмәгыйль тугач, Сара бик кайгырды. Аллаһы Тәгалә Сарага да бер ул бирде, Исхак исемле куйды. Хәзрәти Исхак атасы хәзрәти Ибраһимга ә бик охшыйдыр иде, күргән кешеләр хәзрәти Ибраһимнан аермаслар иде. Аллаһы Тәгалә Исхакны ә атасы Ибраһим дөньяда вакытта Шам халкына пәйгамбәр итеп җибәрде. Исхакның ә Гыйс вә Ягъкуб исемле ике улы булды. Ягъкубның ә ләкаб[1] исеме Исраил иде, шуның өчен балаларына вә балаларының балаларына «бәни Исраил» дип әйтелде. Гыйс хәзрәти Исмәгыйльнең кызын алды, бик күп балалары булды. Гыйснең балалары Рум вилаятенә җәелделәр, хәзер дә Рум вилаятендәге халык бар да Гыйснең сибтләредер[2]. Кабер шәрифе Кудс шәрифкә якын җирдә, атасы Ибраһим ә янындадыр.

*(Дәвамы бар)*

*Галимҗан Баруди, 1899 ел*

---

1 Ләкаб – кушамат.

2 Сибт –онык, нәсел.

# Кием-салым

Белгән кеше бар микән: бу татар мөселманнарның киеменең формасы кай заманадан бирле калган икән? Татарда бар кием: күлмәк, ыштан, камзул, казаки, җилән, чапан, чикмән, кыска тун, өч билле тун, толып, чалбар, бишмәт, читек, кәвеш, башмак, бүрек, такыя, кәләпүш. Бу киемнәрнең бәгъзесе бар, башка халыкта һичберәүдә күренми, һичбер халыкның киеменә охшамый. Бу якын-тирәдәге халыкларда ирләр күлмәге күбрәк озынлыгы тезгә җитәр-җитмәс буладыр, җиңел ситсадан яки бүздән, һәркем үзенең теләгәненә күрә; әмма ирләр ефәктән күлмәк-ыштан кимиләр вә гайре киемнәр һәм кимиләр; ефәк кием кимәк шәригатьтә ирләргә дөрес түгел. Әмма кәләпүшне ефәктән тегеп кияләр, зарар юк. Ирләр ыштаны һәм ситсадан яки башка нәрсәдән, һәрничек фабрикада сугылган нәрсәдән була. Күбрәк ситсадан кияләр, балаклары киң һәм озынлыгы тубыкка чаклы була. Ыштанның төбе киң була һәм бөрмә дип әйтәләр, шул бөрмәгә тасмадан бау тагыла. Шул тасма бау белән ыштанны җыеп бәйлиләр. Ирләрдән бик аз булыр ак ыштан кигән кеше. Ләкин ишанлык дәгъвасын кыйлган бәгъзе ахмаклар – мин аларны әйтәмен салкын ишан дип – алар ак кәләпүш, ак ыштан кияләр. Моның хакында үз алдына бер фасыл язармын. Бәгъзе кешеләр ак күлмәк кияләр, Бохардан яңарак кайткан кешеләр; якасыз була, урыс күлмәгенә охшагандай – аны сарт күлмәге дип әйтәләр.

Дәхи камзул дигән бер кием бар. Ул камзулны һәртөрле материядән тегәләр, кемнең күңеленә ни-нәрсә ошый. Ул камзул бик кыска була, җиңсез була. Иң астан кия торган киемдер, күлмәк өстеннән, урысларның жилеты урынына. Якалы була, алдан төймәлиләр биш йә алты төймә белән, һәм кесәләре була. Ул камзулның тагы бер төрлесе була кыска җиңле, җиңе терсәгенә җитәр-җитмәс. Ул камзул күп кешедә әдрәстән йә бикасаптан була.

Дәхи казаки дигән кием попларның полукафтаны кебегрәк була; озын була, тездән түбән, тубыкка чаклы, һәртөрле нәрсәдән. Элгәре күбрәк әдрәстән, бикасаптан буладыр иде; инде бу еллар башка яхшы нәрсәдән, пустау кебек вә гайре заграничный заттан була. Ул казаки өч билле, озын җиңле була, төймәләре тапастан яки көмештән, һәркемнең теләгәненә күрә: ике якта ике кесәсе була һәм сәгать кесәсе була. Янә шул казакиның арасына мамык салып тексәләр, бишмәт дип әйтәләр. Ул бишмәтнең казакидан аермасы юк формада. Тирәсенә ефәк тасма йә йон тасма тоталар. Бу бишмәтне, казакины һәрбер төрледән тегәләр. Буй-буй нәрсәдән яки бер генә төследән. Вә дәхи җилән дигән киемнәре нанке һәм лачтек вә гайре йон, мамык материялардән тегәләр. Пустаудан булса, чикмән дип әйтәләр. Җилән белән чикмәннең формасы билсез була, озын якалы. Бәгъзе кешеләр чикмәннең, җиләннең тирәсенә ефәк ышнау тоталар яки тасма тоталар йә йон тасма тоталар, хәленә күрә һәм охотасына күрә. Әмма бу чикмән һәм җилән буй-буй нәрсәдән булмый, элгәре җиләнне, чикмәнне әдепле итеп тегәләр иде; инде бу елда әдепле җилән, әдепле чикмән һичкемдә юк. Әмма чапан асыл Бохар киеме, сартлардан чыккан кием. Ул чапан әдрәстән, бикасаптан, саранчыдан, бәнаристан була. Ул һәм җилән шикелле эчле-тышлы була, әйләнәсенә җияк тоталар ефәктән. Ул җияк ышнур кебек нәрсәдер. Ул чапан бу йортның голямасының киемедер. Күбрәк мулла җәмәгате кия һәм байлар кия мәҗлескә барганда, мәсҗеткә барганда; һәм голямага, мулла җәмәгатенә килешә торган киемдер. Махсус өйдә кияр өчен генә бер башка төрле кием юк. Ниндәен кием булса да өйдә кияләр, вакытына карап: өй җылы булса, камзулчан өйдә утыра, суык булса, кыска вә кечкенә тун киеп казакичан утыра. Бәгъзе кешеләр бар, өйдә башмак киеп йөриләр, идәннәренә палас җәйгән булса да.

Тун һәм шулай төрле формада була: кыска тун (бил астыннан) була яки түбәнрәк, тезгә чаклы. Аннан озын, тубыкка чаклы булса, аны кыска тун дип әйтмиләр, өч билле тун дип әйтәләр; кесәсез була, толып уры-

нына киеп йөри торган тун; әйләнәсенә камчат яки кама тоталар, тышы пустау яки башка төрле йон материя була һәм элгәрерәк әдрәс, бикасап була торган иде, хәзер әдрәс, бикасап истигъмальдән чыгып тора бара. Ул өч билле тунны һәм казаки кебек алдан биш төймә, алты төймә белән төймәлиләр. Ул тун һәм һәркемнең хәленә күрә төлкедән яки бәрәннән була. Инде бу заманда толыпны тегәләр шалевый якалы, пустау тышлы итеп. Мөселман татарларның гадәте: азрак хәле яхшырак булса. Кием-салымы күп була, байларны әйтмәймен дә. Гомумән, татарлар кием күп булганны яраталар, киемгә күп акча сарыф кыйлалар. Кыйммәтле киемнәр була. Бәгъзе кешеләр бар – унар тун була торгандыр, һәркайсы кием икешәр була, әлбәттә. Хәтта бер кешенең егерме биш баш киеме була торгандыр, күлмәк-ыштаннан башка. Күп кеше аякка кия торган киемне күп тота: башмак икешәр-өчәр кием, кәвеш һәм шулай, читек һәм икешәр-өчәр кием була.

Күп кешенең шулай һәрбер төрле киемнән икешәр-өчәр кат була бәйрәмлек киемнәре белән. Читек астыннан күп кеше кыш көне оек башы кия яки, булмаса, киндердән чолгавы була кат-кат. Итек киючеләр бик сирәк була байлардан; итекне күбрәк түбән дәрәҗәле кешеләр кияләр. Ул татар кәвеше урыс кәвешеннән башкарак була формасы. Ул кәвешне читек өстеннән кияләр. Бәһасе төрлечә була: бер тәңкәдән өч тәңкәгә чаклы. Була күҗүлдан. Читек һәм күҗүлдан була. Читекнең үкчәсенә сауры куеп тегәләр, тазага килә. Кәвеш үкчәсенә һәм сауры куялар. Бистә халкыннан башала юк оек-чабата кигән кеше.

Дәхи башка кия торган киемнәр һәм төрлечә була. Инде бу заманда күбрәк такыя кияләр, ука белән эшләтеп, бәһасе өч тәңкәдән йөз тәңкәгә чаклы була, һәркемнең хәленә күрә. Яхшы эшлиләр, энҗеләр, кыйммәтле ташлар утыртып, һәм бертөрле кешеләр кәләпүш кия. Ул кәләпүш асыл Бохардан, сартлардан чыккан нәрсә. Ул кәләпүш фарсыча сүз: кәлә – баш мәгънәсендә, пүш – япмак мәгънәсендә; баш капкачы дигән кебек

була. Ул кәләпүшне башка бертөрле ефәк материядән, хәтфәдән ясыйлар, әйләнәсенә ука тотып. Ефәк чуклы була түбәсендә. Аны һәм яхшы итеп эшлиләр, ул кәләпүшне әдрәстән, бикасаптан, ситсадан вә һәртөрле материядән.

Бүрекнең һәм чиге юк бәһасендә. Камчат бүрекнең яхшылары бик кыйбат була. Яхшы камчаттан тегәләр, тышына кыйммәтле хәтфә белән, эченә ефәк яки төлке затыннан яхшы нәрсә куялар. Ул камчат биш тәңкәдән ике йөз тәңкәгә чаклы була. Кияләр тагы каракүл бүрек, данадар бүрек, һәркем хәленә күрә. Ул бүрекне яланбашка кимиләр, такыя яки кәләпүш өстеннән кияләр. Элгәрерәк башка кия торган колакчын дигән нәрсә бар иде, инде бу заманда һичкемдә колакчын күренми.

Дәхи бәгъзе кешеләр бар, эшләпә кияләр; ләкин бәгъзе мөселманнар вә бәгъзе мутаука ак кәләпүш муллалар эшләпә кигәнне яратмыйлар. Ул эшләпә һәм төрле була: бер төрле ак эшләпә бар – мужиклар кия, вә дәхи француз эшләпәсе, Мәскәү эшләпәсе бар. Ләкин ул муллалар яратмый эшләпә кигәнне. Алар танымайлар нинди эшләпә икәнен. Дөрес, китапларда күренә, мәҗүс эшләпәсен кисә кәфер булыр, дигән; ул кию хәрам булган эшләпә бу эшләпә түгел. Шул ак кәләпүш муллалар нинди эшләпә икәнен белмиләр. Бу эшләпә хосусында минем байтак зур рисаләм бар. Ул муллалар эшләпә кигән кешене кагалар белмәенчә.

Чалбар һәм кияләр. Ул чалбар ике төрле була. Махсус татар чалбары була, урыс чалбарына башкарак; төбе бик киң була, балак очлары таррак; бу чалбарны балагын чыгарып йөреп булмый. Инде бу заманда урыс брюкасы кияләр. Балакны чыгарып йөри күп кешеләр. Моннан мөкаддәм биш-ун еллар балак чыгарып йөрү юк иде, ул чак миннән башка балак чыгарып йөргән кеше юк иде.

Һәртөрле халыкта булса кирәк, хатын-кыз киеме белән ирләр киеме бер төрле түгел. Ирләр киеме белән хатыннар киеме арасында күп аерма бар. Инде хатын-кыз киемнәре менә: күлмәк, ыштан, читек, башмак,

кәвеш, камзул, тун, кесәбикә, яулык, шәл, бүрек, чәч тәңкә, ука изү, тәңкә изү, хәситә, яка чылбыры, алка, беләзек, йөзек; вә гайре киемнәр һәм кыз-хатында күп, әмма болары бигрәк мәшһүрләре. Инде бу заманда хатыннар күлмәге һәрбертөрле материядән була, һәркемнең теләвенә күрә төрле төстән.

Әмма, гомумән, татар мөселманнар вә аларның хатыннары яраталар бигрәк ачыграк, матуррак булганны. Бәгъзе мөселманнар бар чемкара киемне мәкруһ күрәләр. Инде хатыннар күлмәге бик озын була, җиргә чаклы, аякны капларлык; шәригать буенча хатыннар киеме шулай кирәк. Хатыннар күлмәгенең итәге ике кат була. Элгәре күлмәкнең итәге башка төстән була торган иде, инде күлмәге белән бертөсле була. Ситса булса, унике аршын яки унөч аршын ситса кирәк, һәркемнең буена күрә. Бәгъзе хатыннарның күлмәге өчәр кат итәкле була, бигрәк купшы булса (ләкин өч кат итәкле күлмәкне бәгъзеләр яратмыйлар, чөнки трактирдагы кызларның күлмәге шулай була), һәм ефәк күлмәк, йон күлмәк булсын, формасы бәрабәр була. Ул күлмәкнең изүләре була укадан, яки тәңкә тезәләр. Ул ука изүне ясыйлар пырзумиттан кат-кат итеп, ягъни бер рәт була сары ука, бер рәт була ак ука, янә лента; һәйбәтләп түгәрәкләп изү тирәсенә ясыйлар; яки бер кат ука була, аның янына лента, ул лента өстенә көмеш тәңкә тезәләр, янә аның янына бер кат лента тоталар. Аннан башка янә муенга кия торган нәрсә бар, яка чылбыры, диләр. Әүвәле укадан яка ясыйлар. Ул каты була, аны тамак астына китереп каптырмалыйлар. Каптырмасы була көмештән, дәхи аңар асалар: көмештән ясаган чылбыры була. Ул чылбыр башларына көмеш тәңкә тагалар, һәркем хәленә күрә; яки тәңкә булмаса, көмештән бер төрле нәрсә ясыйлар, челтәр, дип әйтәләр. Асыл хатыннарның бу украшениеләре чуваштан калган түгел микән? Чуваш хатыннарының шуның кебегрәк нәрсәләре була. Дәхи хатыннар тирәсендә бар чәч тәңкәләре, чулпы диган нәрсә. Артка чәч буена лента өстенә яки бер тасма өстенә тәңкә тезәләр, һәркем хәленә күрә,

полтинниктан була, четвертактан була, җилкәдән, пожалый, билгә чаклы. Ул тәңкәне бәгъзе баераклар алтынга маналар; ул тәңкәләрнең башына ясыйлар көмештән ахак каш утыртып: аны чулпы диләр; бөтенешәр тәңкә тагалар...

Әмма хатыннар ыштанының ирләр ыштаныннан аермасы юк. Бәгъзе хатыннар бар, күлмәк астыннан кернәлин кияләр. Ләкин кисәләр дә, мөселманнарга килешә торган түгел, һәм күп мөселманнар яратмайлар. Ул килешер иде башларына зур шәл ябынып йөрсәләр, әмма алар чапан бөркәнеп йөриләр: килешми, сыерга камыт киерткән кебек була.

Янә хатыннарның камзул дигән киемнәре бар. Ул камзулны тегәләр бик яхшы штуфтан, хәленә күрә. Баераклары штуфның бик яхшысын алалар; эченә төлке тамагы яки гайре нәрсә куялар, һәркем үзенең күңеленә охшаганча. Камзулның әйләнәсенә тоталар бик яхшы камчат, киңлеге ике бармак, өч бармак иллесе. Тагы ул камчат янына тоталар кыйммәтле ука, шулай киң була. Бәгъзе кешеләр бар, салкын эчле итеп тегәләр. Ул камзул җиңсез була, озынлыгы тезгә чаклы.

Хатыннар туны һәм төрле материядән була. Тышы, эче һәм төрле мехтан була. Формасы һәм ирләр туны кебегрәк өч билле; мәгәр китекле яка була, яки шалевый була. Якасына камчат яки кондыз куялар. Бәгъзе кешеләр бар, марҗа туны кияләр, ягъни урыс хатыннары кебек салоп итеп тектерәләр. Ләкин күп кешедә юк, бөтен Казанда җиде, сигез, ун кешедә бардыр, хатыннары салоп кияләр бик олы җиргә кунакка барганда. Янә хатыннарның кесәбикә дигән киемнәре бар, белмәймен кайдан чыккандыр, яңарак чыккан кием. Тышы әдрәс, йә бикасап, яки башка бер төрле материядән була, мамык белән сырган. Җиңе кыска була. Әйләнәсенә тиен тоталар.

Дәхи хатыннарның башка кия торган киеме була – бүрек. Ул бүрекнең кырпуы камчат була. Түбәсен ука белән, энҗеләп, кашлар утыртып чигәләр, бик кыйммәт төшә, бәһасенең чиге юк. Дәхи бәгъзе хатын-

нар күп вакытны калпак кияләр, ефәк калпак була. Гадәттә фабрик эше, бәрхетле калпак диелә. Биш тәңкә, алты тәңкә була простое. Шул калпакны янә төзәтәләр энҗеләр, тапаслар белән, кыйммәт төшә. Ул калпакка ука чачак һәм ука чук тагалар, бик арзан тормый. Дәхи ул калпакны ясыйлар кыйммәтле бәрхеттән. Кыз-хатын бар – бик осталар калпак ясарга. Бик кыйммәтле калпак эшлиләр Казан кызлары, энҗе белән кыйммәтле ташлар утыртып.

Дәхи хатыннарның читеге ирләр читегеннән башка була. Ул хатыннар читеген яхшы сәхтияннән каеп тегәләр ефәк белән яки ука белән, төрле төсле сәхтияннәр кыстырып тегәләр. Гадәти читек була байларда өч тәңкәдән ун тәңкәгә чаклы; әмма һәркемнең хәленә күрә була; илле тиен көмешлек читек һәм була, мин аны әйтмәймен, моннан соңрак әйтермен. Әүвәл байлар киемен сөйләрмен.

Хатыннар күп вакытны башмак кияләр җәй көне. Ул башмакны һәм бик яхшылап ука белән энҗеләр, ташлар утыртып ясаган була. Биек үкчәле башмакның очы очлы була. Дәхи кәвеш һәм кияләр, кыйммәтле була; төрлечә эшлиләр ука белән каеп, кыйммәтле ташлар утыртып. Вә дәхи бәгъзе хатыннар бар: урыс хатыннары кия торган кәвешне, ярты итекне кияләр, һәркем үзенең теләгәненә күрә, мәслихәтенә карап.

Менә инде күреп тор, бер хатынны яки кызны киендерермен. Аның киеме кыйммәткә төшәр микән?

Менә гадәти байларның хатыны киенә кунакка барса: әүвәл кия ыштан, ситсадан була, яхшы, бер тәңкә ярым; ефәк күлмәк кия, уртача бай булса – 25 сум; күлмәк изүе тора, ким булса – 10 сум; янә артында чәч буена чәч тәңкәсе ука чугы белән – 20 сум; янә муенына кия яка чылбыры; бик аз исәпләгәндә – 15 сум; әмма яка чылбыры бу заманда ташланып бара, яки муенга энҗе чук кияләр. Янә кия хәситә дигән нәрсә, иңбашыннан китереп култык астыннан бәйли, кыйммәт төшә; бик яхшы булса, йөз тәңкә тора. Янә камзул кия, гадәти байларның 2 йөз тәңкә тора. Янә энҗеле кал-

пак яки простой гына калпак – 10 тәңкә; бүрек булса – кыйммәтрәк. Энҗе белән төрләп ясаган колак алкасы, ким булса, 25 тәңкә, янә башына ябына шәл, арзан булса – 5 тәңкә (яки ефәк шәл – 15 тәңкә, ким булмас). Янә тун кия – атлас тун, гадәти төлке карны эчле яки корсак карны, ким булса – 50 тәңкә; аның өстеннән чапан ябына – 15 тәңкә; аягына читек гадәти 3 тәңкә генә булсын; кәвеш кисә – 2 тәңкә. Барлыгы – 481 сум 50 тиен!

*Каюм Насыйри,*

*«Сайланма әсәрләр» китабыннан*

*ТКН, 2006*

# Ашау-эчү

Аш дигән сүз күп мәгънәдә истигъмаль кыйлына: аш бар мотлакан ашый торган нәрсә мәгънәсендә; һәрни булса да ашарга ярый торган нәрсә. Мәсәлән, балчыкны аш дип әйтеп булмый, ташны аш дип әйтеп булмый. Вә дәхи аш бар, казанда вә гайре нәрсә эчендә пешкән ашый торган нәрсә; шурпалы, кирәк шурпасыз. Дәхи аш бар бер билгеле вакытта хәзерләнгән ашый торган нәрсә, урысча – обед. Вә дәхи аш бар зыяфәт вә сый мәгънәсендә: фәлән кеше ашка чакырды, ул ашка китте, диләр.

Һичничек булса да булсын, бу аш бик күптөрле буладыр. Иң кирәкле аш – икмәк, ит, шурпа. Әмма гадәти ашларның берничәсен хәтерегез өчен язаек. Менә инде баеракларда аш ни-нәрсәдән хәзерләнә: ит, май, су, тоз, дөге, ярма, он, җимеш, каз ите, үрдәк ите, тавык ите (балыктан аз хәзерлиләр), алма, йомырка, кишер, кабак вә башка нәрсәләр. Йорт ашы була, күбрәк вакыт ит, токмач, яисә ит, салма, яисә пилмән. Әгәр кунак чакырылса, зыяфәт өчен күптөрле аш хәзерләнә. Бер чибәр генә бай кеше кунаклар чакырып сыйламак булса, гадәти аш – иң әүвәл пылау китерәләр. Пылауны казанда пешерәләр. Ул пылау ике төрле була. Әйтәләр, сарт пылавы вә дәхи берсе гадәти Казан халкының пылавы. Казан халкы күбрәк бу рәвешчә хәзерли: әүвәл пешкән итне бик һәйбәтләп турый, дөгене коры суда пешереп ала; аннан соң кайнар казанга сала май, казан астында азрак эссе күмер булсын. Әмма май, сары май яхшырак, куй һәм ярый. Аннан эрегән майга тураган итне сала. Ит өстенә вак кына турап кишер, суган сала, йөзем җимеше сала, аның өстенә пешкән дөгене сала. Шулай булсын: итләр, суганнар, кишерләр бары да дөге астына кереп калсын. Аннан соң казанны каплап дәмләп куялар. Кайнар казанда пылау бер сәгать йә сәгать ярым тора. Казаннан бушатып алалар, бик яхшы аш була. Аннан соң токмач, йә салма, йә пилмән китерәләр. Әмма бу ашлар һәркемгә билгеле, бу ашлар хакында бернәрсә язмасак та белерсез.

Аннан соң бәлеш китерәләр яки гөбәдия китерәләр. Бу бәлеш һәм гөбәдия карап торырга бертөрле формада. Әмма бәлешне хәзерлиләр бөккән кебек, ләкин түгәрәк була. Әүвәл камырны җәяләр, камыр өстенә дөге салалар, чи ит турап салалар, тоз, борыч азрак салалар да шул җәелгән камыр белән төреп бөккән кебек итеп ясыйлар. Табага куеп мичтә пешерәләр. Әмма гөбәдия дигәне һәм бәлеш кебек түгәрәк буладыр. Ләкин гөбәдиягә итне турап салмайлар, чабып салалар бик вак итеп аска, аның өстенә корт салалар, аның өстенә йомырканы пешереп, төеп салалар, май салалар. Бәлеш кебек итеп камыр белән төрәләр; зиядә хуп нигъмәт була.

Дәхи күбрәк пилмән пешерәләр зыяфәт өчен вә һәм йорт өчен. Ул пилмәнне һәркем белә ни рәвеш ясалганын; моны язарлык эш юк. Һәм токмач пешерәләр кунак өчен һәм өй өчен: гадәти аш, моны һәркем белә. Вә дәхи салма аш була, бу һәм һәркемгә билгеле. Ләкин бу салма күбрәк шәкертләр ашыдыр. Бу салма ике төрле хәзерләнә. Мәдрәсәдә шәкертләр салма пешерәләр, менә болай: вак итеп итне турап казанга салалар. Ул ит пешеп килә, камырны басып, әнәчәсен ясап, салманы уч табанында ясап, казанга салалар. Казан кайный тора, салган бер салма пешә тора. Салманы салып бетергәч, суган турап салалар, булса, кишер турап салалар, вакытына күрә. Әмма йортта хатын-кыз пешергәндә салманы бу рәвешчә пешерәләр һәм ясыйлар: әүвәл итне вак кына чабып салалар һәм кисәкләп салалар, салманы кунада ясыйлар. Бу шәкерт салмасыннан күп вак була. Янә була өйрә. Бу өйрә төрлечә, һәрбертөрле ярмадан була, һәм дөгедән була. Әгәр тавык ите пешерсәләр, шурпасына салма салалар яки дөге өйрәсе итәләр. Ул тавык шурпасында пешкән дөге өйрәсенә сөт салсалар, тәме һәм артык була, бик яхшы була.

Вә дәхи хәзерлиләр үрдәк бөккәне. Ул үрдәк бөккәнен ясыйлар бу рәвешчә: үрдәкне бөтен хәлеңчә дөге эченә күмәләр, ул чи үрдәк була. Аны табага куеп мичтә пешерәләр. Әмма ул бөккәннең сыйфаты, формасы урыслар пешерә торган бөккәнгә күп башка була. Бөккәнне ике төрле итеп ясыйлар:

бөккәннең тышын өстәге яктан бөгәләр, моны әйтәләр безнең Зөя округында өстәл бөккәне дип. Янә бер төрлесе бар, кыек бөккән дип әйтәләр, ул ярты түгәрәк була да яныннан бөгәләр, ул бөккәнне күп нәрсәдән пешерәләр. Кабактан пешерәләр: ул кабакны вак итеп турап, дөге белән катыштырып бөккән итеп ясыйлар, табада пешерәләр, аңар май һәм салалар, пешкәч һәм май сибеп ашыйлар; бик яхшы аш була. Кишердән һәм бу рәвешчә итеп пешерәләр, йомыркадан һәм шулай пешерәләр. Әмма балыктан бөккән пешергән кеше бик сирәктер; булса да, юк, дисәң дә ярар.

Ул бөккәннең бер төрлесе бар: вак кына була, табада пешерәләр, чәй янына китерәләр. Бу һәм төрле нәрсәдән була. Ләкин моның исеме башка була, моны сумса дип әйтәләр. Вә дәхи салкын була бер төрле аш, каз итеннән яки күркә итеннән; кыяр турап, керән белән серкә сибеп ашыйлар. Вә дәхи алма бәлеше була, алмадан пешерәләр. Бу һәм урыс пешерә торган бөккән формасы түгел.

Күбрәк алма бәлеше түгәрәк була. Шикәр сибеп пешерәләр. Яхшы була. Янә хәзерлиләр паштет алма катыннан яки җиләк катыннан.

Янә бер төрле аш бар – как-төш дип әйтәләр. Ул как-төш дигәннәре шул: әүвәл камырны басалар йомырка белән, сөт белән, май белән катыштырып. Ул камырны вак итеп әнәчә ясыйлар. Аны пычак белән вак итеп кисәләр, эрбет чикләвегеннән артык зур булмый, аны казанда кайнаган майга салып алалар. Май эчендә пешкәч, бик яхшы була; моны бавырсак дип әйтәләр. Шул бавырсакны бер подноска өеп катыралар бал белән, өстенә конфет сибәләр; бик яхшы нәрсә була. Аны чәй янына куялар. Вә дәхи кош теле дигән аш һәм шул рәвеш пешерәләр. Ләкин аны әүвәл токмач камыры кебек басалар, кыек кисәләр, май эчендә пешерәләр һәм чәй янына китерәләр.

Вә дәхи була бутка һәркемгә мәгълүм. Әмма бутка – сала халкының иң олуг ашы. Моның бәяны (үз) урынында – түбәндә килер.

*Каюм Насыйри,*

*«Сайланма әсәрләр» китабыннанТКН, 2006*

# Милли матбугатыбыз

## Табагат. Басмачылык.

Басмачылык исемен ишетмәмеш вә басылмыш китапларны күрмәмеш бер кеше ошбу көнебездә булмаса кирәк. Ачык, китап басмак рәвеше, ихтимал ки, күп адәмнәргә мәгълүм түгелдер.

Басмак – табагат бер нәрсәдә булган рәсемнәрне икенче бер нәрсә өстенә төшермәктән гыйбарәттер. Һәрбере ялгыз-ялгыз буларак куелмыш әлифба хәрефләрен бер җиргә китереп тезәрләр, соңыннан да шуның өстенә кара сөртеп, кәгазьгә басарлар, ошбуның сәбәбеннән йөзләр, меңнәр илә нөсхәләр вөҗүдкә [барлыкка] китерерләр. Фәкать сукырлар өчен басылмыш китапларның басмалары кара сөртмәктән мөстәгъни [башка] булып, үзләренә башка ысуллары бардыр.

Басмачылык иң элек мәртәбә Чиндә [Кытайда] барлыкка килмештер. Риваятьләргә күрә, чинлылар милади алтынчы карында [гасырда] (Расүл әкрам гасырыннан мөкаддәм [элек]) китап баса башламышлардыр. Фәкать болар иң элек кабер ташларында күрелдеге рәвешчә агач тәхтәләргә сүзләрне калкытып язалар вә шуларны буяп кәгазьләргә басарлар иде[1], әмма бу көндә исә хәреф җыймак ысулы илә басмакталардыр.

Японнар басмачылык һөнәрен чинлеләрдән үгрәнмешләр вә моны да хәйли тәрәккый итмешләрдер [шактый үстергәннәр]. Соңрадан чин ысулы күп урыннарда мөнтәшир булды [таралды].

Уникенче карын милади ахырында Италия, Испания вә Сәҗилиядә чин ысулы илә басмачылык шаигъ булмыштыр [барлыкка килә]. «Тәүрат әл-фикъраэ» исемендә булган Тәүрат ошбу ысул белән 1400 илә 1430 миладилары арасында табгы булынмыштыр. Моннан соң латинча дәхи [тагын]

[1] Монда сүз ксилография ысулы, ягъни язуны яки рәсемне тактага гравюралап язып, аны кәгазьгә төшерү турында бара. – *Төз.*

дини бер китап табгы ителенеп таралды. Ауропада иң элек басылмыш дини китаплар ошбулардыр.

Ошбу ике әсәр басылдыгыннан аз көннәр үткәч, Ауропада яңа ысул булган хәреф матбагалары мәйданга килде. Күбрәк кемсәләр моның сәбәпчесе Германиядә Манисә [Майнц] шәһәрендә дөньяга килмеш булган Гутенберг дияр булсалар да[1], ул түгел, бәлки Иоһанн Фуст[2] дигәннәр дә бардыр. Бәгъзеләр Бэтрэс Шоффер[3] иде диярләр. Гутенберг исә 872/1468 дә 68 яшь хөдүдендә вафат булмыштыр. Һәрхәлдә, басмачылык һөнәре 1462 елга кадәр башланды вә моны белүчеләр үзләреннән башка һичкемгә белдермәделәр.

Җәдидә матбагалары 1465 тә Италиядә, 1469 да Румда, 1469 да Парижда, 1474 тә Англиядә, 1475 тә Испаниядә күрелә башламыштыр. 1500 дә бөтен Ауропада 1500 микъдарында матбага хисап ителенер иде.

Ауропада матбугат, хосусан [аеруча] яңа ысул чыктыгы вакыт, христиан руханилары гаять катгый сурәттә каршы тормышлар вә бөйлә шәйләрнең [мондый әйберләрнең] гөнаһ идеген дин исеменнән игълан итмешләрдер. Обсаля шәһәренең папасы Трулль нам кемсә [исемле кеше]: «Дарелфөнүннәрдә [университетларда] укылмакта булган гыйлемнәр бөтен-бөтенгә христиан мәзһәбенә хилафтыр, матбагачылык та Алла каршында иң бөек җинаять булып, бөйлә бер эш иҗат иттеге өчен Гутенберг сихерче вә кәфердер!» – дияр иде.

## Гарәби хәрефләр илә басма

Гарәби хәрефләр илә басмачылык, иң элек мәртәбә буларак, Италиядә Бендик (Бәндәкыя) [Венеция] шәһәрендә булмыштыр (1510-1514 еллар-

---

1 Иоһанн Гутенберг тарафыннан беренче басма китап – Библия 1445 елда басыла – *Төз.*

2 Иоһанн Фуст (1400-1466) – беренче немец китабы бастыручылардан. – *Төз.*

3 Петр Шёффер (1425-1503) – беренче немец китабы бастыручылардан. Иоһанн Гутенберг типографиясендә төп эшче булган. Аңа кадәр кулъязмалар күчереп язу белән шөгыльләнгән. – *Төз.*

да). Моннан соң башка шәһәрләргә дә таралды. Мизамир Давыд 1516 тарихында Җәнүһтә табгы булынды. Сәгыйд әл-Фиюһи тәрҗемәсе булган гарәби Тәүратны яһүдиләр 1551 дә Истанбулда бастырдылар. Истанбулда булган ошбу матбага мәзкүр Тәүрат нөсхәсеннән башка икенче бер китап басмыш, үзенең дә исем вә хәбәре тәмам онытылмыштыр. Фәкать бөйлә хәлнең булындыгы бу көндә булган бәгъзе матбуг нөсхәләр шәһадәте илә генә мәгълүмдер, һәрхәлдә, моннан соң Ауропада гарәби хәреф илә китап басылынырга башлады.

Рум шәһәрендә 1591 дә Инҗил вә 1593 тә өч җөзьэдә [бүлектән] вә бер җилдтән [томнан] торган вак хәреф илә Әбү Гали ибне Сина хәзрәтләренең «Әл-канун» нам әсәре вә 1671 дә Тәүрат басылды.

Дөньяда иң элек басылмыш Коръән шәриф уналтынчы гасыр әүвәлендә Вендик [Венеция] шәһәрендә Паганный тарафыннан табгы ителмеш нөсхәдер. Фәкать папа әмере илә ошбу Коръән бер нөсхәсе булсын калмаксызын яндырылмыштыр. Шуның өчен моның бит хисабы вә хәреф һәм кыйтгасының рәвеше вә басмасының елы беленми калмыштыр. Моннан соң Ауропада ике җирдә Коръән шәриф басылды. Бере 1694 тарихында А. Гинкельман тарафыннан Һамбургта [Гамбург] вә икенчесе дә Л. Мараччи тарафыннан латинча тәрҗемәсе вә рәддиясе [текстка тәнкыйть] илә бергә Падуя шәһәрендәдер [1698 елда].

Әмма гарәби әсәрләрнең латинча тәрҗемәләре ошбу еллардан күп элек табгы булынмыштыр. Мисля имам Әбелкасыйм әз-Зөһрәвинең «Әттәсриф» исемендә булган әсәренең тәрҗемәсе Вендек шәһәрендә 1445 тә вә Ибне Синаның «Канун»ы тәрҗемәсе 1476 дә, Разый әсәрләренең тәрҗемәләре 1482 дә, Гали бине Габбас әл- Әһвәзи әл-Мөлки әсәрләренең тәрҗемәләре 1492 дә басылмышлардыр.

Яһүдиләр тарафыннан Тәүрат табгы иттергән матбаганың хәбәре бөтен-бөтенгә онытылдыгы сәбәпле, Истанбулда матбага зоһури 1129/1717 тарихыннан соң игътибар ителенер. Иң элек буларак хәреф илә Истанбул-

да табгы ителгән әсәр Сыхах Җүһри тәрҗемәсе булган «Вәнкули» исемле мәшһүр китаптыр. Ошбу әсәр ике бөек, җилд вә бөек кыйтгаларда буларак 1729-1730 миладида мөҗарәле Ибраһим әфәнде мәгърифәте илә басылмыштыр.

Һиндстанда иң элек басылмыш гарәби әсәр «Нәҗүм әл-фиркан» булып, 1811 дә Калькутта шәһәрендә хәреф илә табгы булынмыштыр.

Мисыр мәмләкәтендә иң элек заһир булган [барлыкка килгән] матбага Наполеон илә берлектә бармыш матбагадыр[1]. Фәкать ошбу матбага ташбасмадан гыйбарәт иде. Моннан соң һәрникадәр хәреф матбагалары да иҗат ителде исә дә, Наполеон чыктыгы соң һәрбере таралып юк булып бетмешләрдер. Моннан соң Мөхәммәдгали паша 1818 тарихында ошбу көндә иң шөһрәтле матбагалардан булган «Болак» матбагасын вөҗүдкә китереп, беренче дәфга буларак 1822 дә гарәби вә Италия лөгате хакында булган лөгать китабын бастыртмыштыр (266 биттә).

Моннан соң Һинд, Тунис, Фарсы, Марракәш, Зәнҗәбар вә гайре урыннарда күп матбагалар заһир булды.

Бу җиргә кадәр язмыш сүзләр милли матбугатыбыз хакында сөйләнәчәк бәхәсләргә мөкаддимә [кереш] иде, шимди асыл максудыбыз булган «Милли матбугатыбыз» хакында киләчәк баб язылыныр.

## Махсус бер мәкалә

Дөньяда мәүҗүд [бар] булмыш вә мәүҗүд булачак шәйләр мөтәсәлсил булып [бер-бер артлы] килмеш сәбәпләрнең нәтиҗәләредер диярләр. Ошбу кабилдән безнең милли матбугатыбызда бер кач еллардан бирле сузылып килмеш сәбәпләрнең сәмрәсе [җимеше] иде.

Әгәр дә ачык сурәттә басылып таралмыш вә һәркем тарафыннан укылмыш вә аңлашылмыш милли тарихыбыз тугрысында бер китап булса иде, ошбу «Милли матбугатыбыз» бәхәсләренең күп җирләрен без шуңа

1 Наполеон Бонапарт Мисырны 1798-1801 елларда яулап алырга омтыла. – *Төз.*

нигезләнеп вә яки укучыларның һәрберенең мәгърифәтләренә игътимад әйләмәк [таяну] илә канәгать әйләр идек. Фәкать арабызда дидекебез кеби китаплар һәнүз [һаман да] юктыр. Бер кач адәмнең белмәсе дә гомум өчен кяфи [җитәрлек] түгелдер. Ошбу сәбәптән безләр бу җирдә асыл максуддан бер тарафка чыгып, ошбу «Махсус мәкалә»не язарга мәҗбүр булдык.

Казан шәһәре руслар тарафыннан забыт ителдеге соң [яулап алынгач], әтрафында [тирә-якта] булган ихтиляллар [баш күтәрүләр] 5-6 елларга кадәр вә икенче гыйбарәт илә типтәрләрнең Волганың мәшрикъ тарафына күчеп бетүләренә вә башкорт җирләрендә урынлашуларына кадәр дәвам итте. Типтәрләр тәмам һиҗрәт иттекләре соң, Казан вилайәте мөхарәбәләрдән [сугышлардан], ихтилаллардан саф буларак калып, русиялеләр моны исә тәмам иркенлек үзерендә идарә итәргә керештеләр.

Мөселманнар үзләре хәким булдыклары вакыт, һәрбер дингә хөррият биреп, вөҗдан вә игътикад [инану] эшләренә бөтенләй тыкшынмаслар иде. Дәште Кыпчак хөкүмәтенең шөһрәтле вә көчле вакытларында да хан сарайларында тулып тормакта булган рус кызларыннан вә рус егетләреннән бер фәрд булсын арзуларыннан [теләкләреннән] башка диннәреннән дүндерелмешләрдер. Хәтта ислам кабул итмәк тугрысында ишарәт булсын тәлкыйн ителмәмештер [төшендерелмәгән]. Күрүебезчә, мөселманнар милләт хәкиме булдыклары вакыт шулай хәрәкәт итәрләр иде. Әмма мәхкүм булдылары соң [ягъни дәүләт яулап алынгач], тәмам моның гакесенчә [киресенчә] бер мөгамәлә күрмешләрдер.

Казаннан әсир алынмыш ханнар вә шаһзадәләр Москвага җибәрелдекләре соң чукындырылдылар. Хөкүмәт тә христиан руханилар идарәсенә табигъ булдыгыннан [буйсынгач], мәсҗедләр җимерелер, исламнар җәбри сурәттә диннәреннән түнтәрелер, чукынмышларның һәрбер мәшәкатьләре чукынмамышлар өстенә йөкләнер иде.

Бүгенге земство хезмәтләрен эшләргә, моннан ике вә өч йөз еллар мөкаддәм бер вакытта шул гасырларның низамнарына [кануннарына]

күрә әһали [халык] мәҗбүр булыр иде. Каторга хезмәтләреннән күпләрен карья халыклары вә хосусан диннәреннән түнәргә ризалык күстәрмәгән мөселманнар башкарырлар иде.

Сугыш көймәләре өчен урман кисүчеләр вә аларны тарттырып суга төшерүчеләр дә, аннан да арканнарга җигеп яр буеннан сөйрәп баручылар лашманлы исемендәгеләр – Петербург бина ителдеге вакыт иң агыр хезмәтләрне мөселманнар башкармыш. Хезмәт агырлыгыңнан вә сазлык урын булдыгы сәбәпле, һәртөрле бизгәк хасталыклары күп булдыгыннан бу бичаралар йөзләр вә меңнәр илә дөньядан үтеп тормышлардыр. Фәкать мөселманнарның бәйлә хезмәтләрдә булындыклары онытылып, исемнәре дә ни кәгазьдә вә ни күңелләрдә булсын калмамыштыр. «Өй ясамыш балта тышта калыр», – диярләр. Тугры бер сүздер.

Иштә бәйлә агыр хезмәтләрдән хөляс булып тормак [котылу] каеды [нияте] илә бәгъзе мөселманнар христианлык кабул итәргә мәҗбүр булырлар иде. Христианлык кабул иткән чит халыклар лашманлык, солдатлык кеби хезмәтләрдән вә земство налогларыннан азат ителенер булмышлардыр.

Сәед Җәгъфәр, Алдар, Килмәк абыз, мелла Баһадир шаһ вакыйгаларының күбесе ошбу җәбер шомлыгыннан мәйданга килмештер.

Мөселманнар өстендә булган бу мәшәкатьләр императрица Екатерина (Әби патша) заманына кадәр дәвам итмештер.

Озын мөддәтләр [вакытлар] Төркия илә сугышмыш Әби падишаһның гаскәре тәмам зәгыйфьләнде, байлыгы бетте вә моның өстекә дә дахли ихтиляллар [эчке восстаниеләр] заһир булды [барлыкка килде]. Бервакыт хөкүмәт шәйлә хәлләргә төшмештер, (мөселманнарның үзләренең хәтерләренә килмешме, юкмы?) Бөтен Урал вә Волга буйларының Русиядән аерылмак ихтималын күз уңгына алырга вә бу тугрыларда чаралар эзләргә башламышлардыр.

Шулай итеп, императрица мөселманнарның хәтерләрен табып, Русиягә изгелек итмәк каеды [нияте] илә «Һәртөрле дин әһелләре өчен үз диннәрен тотарга ихтыярдыр!» мәгънәсе илә хөррияте диния игълан итмештер. Моны исә әһалигә бильфигыль [эш белән] күрсәтмәк өчен Оренбург, Троицкий, Омский, Верхнеурал шәһәрләренә хәзинә мосарифы илә җамигълар [җәмигъ мәчетләр] бина иттермеш, дини бер мәхкәмә төсенә буяп Оренбург собраниесен дә ачмыш вә Петербург шәһәрендә Коръән шәриф бастырыр өчен фәрман язмыштыр. Бу хәлләрне күрмеш мөселманнар Русиянең яңа бер дәвергә кердекләренә вә моннан соң дин вә милләтләрне мөхафәзә итә [искә ала] beләчәкләренә канәгать итеп, кәсеп вәкарьләренә керешмешләрдер.

Милли матбугатыбызны мәйданга китермеш шәй рәхәтләр түгел, бәлки михнәтләр, тау вә ташлар тәхмил итмәслек [күтәрә алмаслык] дәрәҗәдә зәхмәтләр булдыгы, бу җирдә яздыгыбыз сәтырлардан [юллардан] мәгълүм булса кирәк.

## Петербургта басылмыш элек әсәрләр

Император Бөек Петр тарафыннан гарәп хәреф илә төрки телендә бәгъзе фәрманнар басылдыгы билгеле булдыгы кеби, императрица Екатерина тарафыннан Кырым шивәсе төркичә басылмыш бер закон мәҗмәгый [җыентыгы] манзурыбыз булды [игътибарга алынды]. Фәкать болар рәсми шәйләр булдыгы өчен безнең милли матбугатыбыз җирен тотмаслар.

Екатерина фәрманы чыктыгы соң, Петербург шәһәрендә иң элек мәртәбә басылмыш шәй Коръән шәриф булмыштыр. Зур кулда вә 477 биттә табгы ителмәктә булган бу Коръән шәрифнең ахырына табгы тарихы куелмамыш исә дә, 1787 елда басылдыгын зан итәрләр (һиҗри илә 1201-1202 еллар буладыр). Мәзкүр нөсхәне мела Госман бине Исмәгыйль исемендә бер зат тасхих итмеш вә хашиясенә [читенә] бәгъзе изахлар [аңлатмалар]

һәм язмыштыр. Соңгыра ошбу нөсхә, һичбер җире үзгәртелмичә, 1790, 1793, 1796, 1798 елларда тәкрар басылмыштыр.

Милли матбугатыбызның «Бисмиалла»сы ошбу нөсхә Коръән шәрифләр булмыштыр. Ошбу биш дәфга [мәртәбә] басылмыш Коръән шәриф нөсхәләренең саннары хакында кулыбызда мәгълүмат юктыр. Асаре кадимә җәмгыятьләре вә архивларны тәфтиш итеп [тикшереп] йөрүче мөәррихләр [тарихчылар] бер көн булыр, шаид, бу тугрыда рәсми хисапларны табып игълан итәрләр.

Шура. – 1908. – №10. – Б. 324–326; №8. – Б. 231–233; №17. – Б. 525–527; №21. – Б. 673–675.

*Мәкалә Фәхреддин Ризаэддин Мәшһүр адәмнәр:*
*«Шура» журналы сәхифәләреннән китабыннан алынды*
*(Казан: Рухият, 2012)*

# Тарих

# Дүрт ягым кыйбла: Арчаның тарихи халкына бер сәяхәт

## IV

XVIII гасырда рухани фәлсәфә өлкәсендә Габденнасыйр Курсави мәртәбәсендә башка бер генә галим дә җитешмәде. Әмма аның шәхесе һәм өстенлеге бүтәннәрне күләгәдә калдырырга тиеш түгел.

Хәер, халкыбызда булган ул галимнәр, булган! Хәтерләп кенә бетермибез. Шундыйлардан тагын берсе – «Таузыйхи» кушаматын йөрткәне бар.

Аның даны «Тәүзыйх китабы»на мөкиббән булуыннан, аңа аңлатмалар төзүеннән килә. Ул әле башка төрле шәрех китаплары язу белән дә шөгельләнгән. Исеме – Нигъмәтулла имам, Наласа авылында яшәгән. Әтисе – Рәхмәтулла, бабасы – Иманкол исемле икәннәр. Аларның нәселе Рәхманколдан килә. Бу Нигъмәтулла ахун 1815 елда хаҗ сәфәренә китеп, Искәндәрия шәһәрендә вафат иткән, Бусыйри төрбәсе янында җирләнгән…

Түбән Оры авылында йөрибез. Күпләр Казанга күченгән. Ата-ана йортын музей-ихатага әверелдергәннәре дә бар.

Данлыклы авыл булган ул. Монда иске байлар завод-фабрикалар тотканнар. Суны буатып, аның көченә машиналар эшен корганнар. Кайсыларының субайлары әле һаман да утырып торалар. Түбән Оры авылы иңкүлеккә, тирән казан булып сузылган чокыр урынга урнашкан. Монда Кызылъярдагы кебек җилләр дә тән аша үтәли йөрмиләр. Ышык. Кояш нурлары нинди салкын көннәрне дә йомшартырга өлгерә.

Әмма хәзер кайбер урамнары түбәннән югарыга таба менеп киткәннәр. Аңлашыла! Моның хикмәте генә түгел, сәбәбе дә бар.

Оры авылында ул хакта искә алуны хәерсез бер гамәл кебегрәк белсәләр дә, тирә-күрше авылларында аны вакыйга итеп сөйлиләр. Чөнки

даны китапларга кергән. Тарихларда да «Оры туфаны» буларак искәртелә[1]. Ул инде, телдән-телләргә йөри-йөри, гасырдан-гасырга күчеп килә-килә, безнең дәвердә дә сөйләнелә. Миңа аны Кызыръярда кат-кат сөйләделәр.

Бик эссе җәйге вакыт икән. Оры авылына бер ак бабай килеп, йорттан-йортка йөреп, эчәргә су сораган. Әмма аңа бирмәгәннәр. Бары бер яшь кызның гына мәрхәте килеп, аңа су чыгарган.

Бәлки вакыйгалар шуның белән бетәр дә иде, әмма бу кызның әнкәсеме (әллә әткәсеме?) бик усал кеше икән. «Аңа нигә су бирдең?» – дип, кызын тәмам орышкан, тәмам орышкан... Бу хәлгә түзә алмыйча ак бабай, ишетеп торган җиреннән: «Авылыгызны су йотсын»,– дип, каргап дога укыган.

Ул китүгә, озак үтми, күктә кара болыт чыга, бик әшәке җил күтәрелә һәм бик әшәке яңгыр ява башлый. Һәммә тарафтан сулар күтәрелеп, Түбән Оры авылын басып, халкы, малы-туары белән бергә, агызып алып китеп, еракка илтеп ташлаган. Шул туфан суы алып барып тукталган урында бүгенге көндә дә шомлы агачлык һәм зират икән. Аны «Орылар яткан җир» дип аңлаталар.

Оры туфанында бердәнбер кеше – ак бабайга су биргән кыз исән калган. Үзен ачулануларга әрнеп, өйләренең кыек чормасына менеп качып, шунда елап утырганында яңгыр ява башлаган.

Берәүләр әйтәләр: «Туфанның килгәнен ул белми калган»,– диләр. Икенчеләр: «Күреп торган, авыл халкын кызганып елаган»,– диләр.

Түбән Орыда да бу хәбәрне матурлап сөйләделәр. Инде хәзер мәгънәле бер риваять төсен алса да, мин аның асылы белән кызыксынып карадым. Белүче булмады. Һәм менә борынгы китаплардан эзли торгач, күп нәрсәләргә ачыклык керде. Болар инде чын тарихның үзе иде!

Бу туфан вакыйгасы чыннан да булып узган. Төгәл датасы да билгеле. Ул вакыйга 1817 елга карый. Монысы тагын да гыйбрәтлерәк!

[1] Фәхретдинов Р. Асар.- Өченче кисәк.- Б.144.

Түбән Орыда ул вакытта имам-мөдәрисләрдән шәһрәтле Хәбибулла ахун яшәгән. Аның «Хәбибулла ишан» дигән даны еракларга таралган. Нурлы йөзен күрергә, аяк тузанын үбәргә әллә кайсы мишәр якларыннан да киләләр икән.

Хәбибулла ишанның нәселе зур булып, аның бабалары инде язылып узылган Янсари-хафиздан килә икән. Килдеш бәк торыннарыннан болар. Кайчандыр мари яклары болар кулында булган.

Җәйләрен тарантасларына атларның бары тик яхшыларын гына җиктереп, кышларын затлы бизәкле чаналарда җилдереп, туннарның да асылларын гына киенеп йөрегән Хәбибулла ишан. Әтисе – Хәсән, Бабасы – Габделкәрим. Хатыны да ни җитте генә түгел, Хуҗа Сәет нәселеннән килгән, Ханмирза, Котлык кебек бабалары белән дан токкан, Оры авылының мәшһүр байларыннан Туктамыш улы Рәхмәтулланың кызы Зөбәйдә абыстай икән. Хәбибулла ахун Оры авылында таш мәчетнең имамы булган.

Әмма көннәрнең берендә авыл байлары, Хәбибулла ишанга карата күңелләре суынганга, аралары бозылып, аңа каршы котырынып йөри торгач, ахырда туганы Фәтхулла хәзрәтне ахун иткәннәр дә куйганнар. Шулай гына бераз тынычланганнар.

Әмма Хәбибулла ишанның мәртәбәсен санлаучылар да табылган. Тиз арада агач мәчет җиткергәннәр һәм бер мәхәллә булып аерылып чыкканнар.

Боларның икесе дә, Хәбибулла да, Фәтхулла да, ни җитте генә түгел, вәкарьле икәннәр. Мәчетләреннән азан һәм Коръән уку авазлары үзара ярышып ишетелә башлаган, берсе уразага кергәндә, икенчесе бер көнгә соңарта, гаетләрне дә берсе икенчесеннән арттырып уздыра торган булып киткәннәр. Ул ярышулары йорт-җиһаз, арба-чана, ат-дирбия, кием-салым, юл йөреш, кыяфәт күрсәтеш, беләмлек мәртәбәләренә кадәр үстерелеп, заманына күрә башы-ахыры күренмәс шайтаный бер хәрәкәткә һәм бәлагә

әверелә барган. Ә моның сәбәбе, эшнең башы – мөфти хәзрәтләренең кул уйнатуыннан һәм көнчелегеннән килгән. Аңа башкалар катнашып кына киткәннәр.

Тагын да шунысы бар, Оры авылының төп халкы мишәр татарларыннан булып, алар бу якларга шактый таза хәлләрендә килеп урнашканнар һәм, гадәтләре буенча сәүдә эшләрен киң җәелдереп, татар галәмен үз мәнфәгатьләренә бик оста хезмәт иттерә башлаганнар. Икенчедән, Оры авылы халкы үз данын һәм мәртәбәсен даими күз уңында тоткан. Яхшы зиһенле, атаклы имамнар нәселеннән булган Хәбибулланы шәкерт вакытыннан дин башлыгы итеп әзерләүгә зур көчләр куйганнар.

Татар мәдрәсләрендә аң-белем алгач, аны Бохарага җибәрләр, анда да иң шанлы мөдәррисләрдән белем ала Хәбибулла. Хәер, ул үзе дә акыллы шәкертләрдән була. Бохарадан Кабулга китеп, гарәп һәм фарсы телләрен камил үзләштереп, белемнәрен тирәнәйтеп һәм киңәйтеп өлгерә. Хәтта ишанлык серләренә дә төшенә. Һәм менә ул Орыга кайткач, имамлыкта аның белән ярышырлык кеше табылмый.

Тиздән Хәбибулла ишан хакында олы хәбәрләр тарала. Мәдрәсәсе даннарга күмелә. Аңа халык ихлас күңел белән бирелә. Бигрәктә мишәрләр, мәртәбә, дан, кемлек яратучылар буларак, аның атта узып киткәнендә: «Ишан хәзрәтләребез, бәракәт ит!»– дип, тәгәрмәч эзен ятып үбәләр, укыган догасыннан могҗизалар табалар, чана юлларын кочалар икән.

Хәбибулла хәзрәтнең даны зурлыгын сөйләүче фактлардан тагын да берсе шул, бусы – муллаларга бәйлесе... Имамлыкка дәгъвә иткән шәкертне сынаганда бер кыландырып алу халыкта булган бит инде...

Шәкерткә, әлбәттә, төрле сораулар бирелә. Шулардан берсе: «Оры шәрифкә бардыңмы? Ханәкәгә кердеңме? Тәнбиһ укыдыңмы?»– диләр. Әгәр дә Оры ишаны Хәбибулланың алдында булган, аның фатихасын алган шәкерт икән, булды гына, килешү-намә җыела, моны имам итеп сайлыйлар, Уфага, мөфтидән шәһадәтнамә китерергә җибәрәләр. Әгәр:

«Юк!»– дисә, нинди генә укымышлы, олы белемнәр иясе саналмасын, аңардан ике дә уйламый баш тарталар.

Әмма бервакыт Хәбибулла хәзрәтнең дан-шөрәтләре бәхетенә каршылык итә башлый. Вакыйга шулай килеп чыга ки, мөфти Мөхәммәтҗан хәзрәтләренең хаталы эшләреннән берсе хакында эш тикшерү өчен мәхкәмәгә тапшырыла. Менә шунда «аның урынына Оры имамы Хәбибулланы куялар икән» дигән сүз тарала. Бу хәбәр Мөхәммәтҗан мөфтигә дә килеп ирешә. Әлбәттә бу яңалык аның ачуын кузгаткан. Үте сытылуга кадәр җиткергән булса кирәк?

Ул Оры авылының мәчетенә ут төртеп яндырырга әмер бирә. Ярый әле бу эшкә һичкем алынмый, халык тәмам курка кала, күңелләрен аптырау баса.

Вәкарьле Хәбибулла хәзрәткә килгәндә, ул боларны белми дә кала. Үз тәртибендә яшәвен дәвам итә. Әмма Мөхәммәтҗан мөфти, мәхкәмә эшеннән имин узып өлгерми, Хәбибулла ишаннан үч алу уена төшә. Имамлыгыннан очырыр иде – белеме олы, халык арасында хөрмәте галәмнәргәчә ашкан. Хәер, мөфти хәзрәтләре моңарга игътибар итеп тә тормас иде, юк итү эшен башкарыр иде дә... Аңа Хәбибулланың мөфтилеккә дәгъва кылмаган булуы, бары тик каршылыклы халыктан чыккан сүз аркасында гына бу хәбәрнең таралганлыгы Казан байлары аша хат белән Уфага килеп ирешә. Менә шунда мөфти хәзрәтләре, мәчеткә ут төрттерү түгел, мәхәллә халкының күңеленә Хәбибулла ахунга каршы «ут ягу» эшен башлап җибәрергә кирәк таба. Даны сүнсен, имеш.

Байлар арасында махсус рәвештә коткылар таратылып, имамга каршы барысын да котырта башлыйлар. Алар баштарак бирешмиләр. Әмма нинди иманлы кешеләрнең дә күңеленә, әүвәле, аптырау, аннары, коткы төшеп, Хәбибулладан көнләшү, аны начарга чыгару уе урнаша бара.

Татар – татарны сөйми, диләр. Татарлар дус яшәмиләр, диләр. Тагын әллә нинди шундый сүзләр сөйлиләр. Әмма халкыбызның күңеле дә саф,

рухы да ныклы. Әгәр дә кешеләр арасына шайтаный утларны тергезүчеләр булмаса, моны махсус, армый-талмый, ялган, гайбәт, шакшылык юллары белән башкармасалар, татарлар бик тә тату, матур, соклангыч тормыш белән яшәр иделәр. Безнең халык саф бит ул, акыллы, булган бит ул!

Хәбибулла хәзрәткә каршы алып барылган коткыга бирелеп, байлар үзара тарткалаша башлыйлар. Тәмам үпкәләшеп, ахырда ике мәхәлләгә аерылып, Хәбибулла ишан үзенә агач мәчет төзетергә, шунда имамлык итүгә күчәргә мәҗбүр була, туганы Фәтхулла таш мәчеткә мөфти фәрманы илә ахун итеп куела. Ике туган, икесе дә имам, тәмам дошманлыкта яшәүгә күчәләр. Авылларының даны да сүнә бара. Мөхәммәтҗан мөфти дә үз дигәненә ирешә.

Бу вакыйгадан шул аңлашыла: Хәбибулла ахунның кемлеге, ниндилеге белән куанып, аңа чын күңелдән сокланып, мәртәбәсенә бәйле иркен күңел ясап мактанып йөргән халык ахырда үзен-үзе бәлагә сардырган. Үз имамнарын мөфти итеп күрәселәре килү – табигый хәл, Орының, аның белән бергә халкының да даны артыр иде. Әмма, бу теләкләре, беренчедән, Хәбибулланың төсен җибәргән, икенчедән, таш мәчетне харап итә язган, өченчедән, халыкның үзен вәсвәсәгә тапшырган. Бу аларның мәгънәви туфан астында калулары түгел идеме?

Хәбибулла хәзрәт Оры авылында 1762 елда туган, 1817 елда Орыда вафат булган. Шул елны, ишанның вафатыннан соң озак та үтми, Оры авылын туфан суы агызып алып киткән. Мөфти Мөхәммәтҗан (Габдрахманов Мөхәммәтҗан Хөсәен улы, беренче мөфти, ниндидер сәбәп белән бабасы исеменә бәйле рәвештә, ягъни фамилиясенә карап, «Габдрахман мөфти» дип йөртелгән) исә, Хәбибулла вафатыннан соң җиде ел узгач, 1824 елның 17 июнендә 68 яшендә мәңлек йортка күченгән. Мөфтилеген һичкемгә бирми һәм тапшырмый калдырган. Аның Әхмәт исемле улы, башка балалары кебек үк, морза титулында, зур биләмәле җирләр хуҗасы

була. 19 яшендә Санкт-Петербургта дин эшләре министрлыгында олы урынга күтәрелә.

Мөхәммәтҗан мөфтинең бәхет кояшы бик тә югарыдан яктыртып, аны һәрьяктан нурландырып торган. Ул патшалар кебек яшәгән, яхшы арбаларда дүртәр ат җиктереп узып китә торган булган. Аның мәрхәмәтенә ирешү бөек саналган, каһәренә юлыкканнар һичшиксез һәлакәт тапкан, бәла авырлыгын татыган. Нинда данлыклы Хәбибулла ишанны да аның сәясәт тегермәне йоткан, ваклап ташлаган.

## V

Бүгенге көндә Түбән Оры авылы байларча яшәп ята. Күп кенә йортларда кыек түбәләрен алыштырганнар. Заманча итеп яңа йортлар да эшләткәннәр. Укымышлы кешеләре дә күп. Намазларын укып, уразаларын тотып яшиләр. Заманча дини китаплардан тыш, иске басмалар да монда шактый очрады. Кулъязмалар да килеп чыкты. Иманда ныклы халык яши икән дигән сөенеч белән киттек алардан. Изге догалары үзләренә дә бәрәкәт белән әйләнеп кайтсын!

Ә безнең юлыбыз дәвам итте. Алдагы көндә Байкал авылында булырга тиешбез икән. Бу исем кайдан килә икән? Әллә ерак Себердәге Байкал күле белән бәйләнеше дә бармы? Хәер, анысы «бай күл» сүзеннән инде аның, ә монысы бәлки «бай кол»дандыр?

Юк, алай гына булмас! Тәмам төгәл, дөресен ачыклар өчен шактый эзләнергә, архивларны, борынгы китапларны актарырга кирәк. Халык арасындагы киң күңелле иҗатчылар сүзенә ышанып җитеп булмый. Хәер, аларның версияләре дә кирәк, анысы. Гәҗит-журнал өчен, репортер язмаларына шундыйлары кадерле аларның. Әмма фән – башка, ул төгәллекне, чын хакыйкый белемнәрне генә кабул итә.

Арча ягыннан борынгыда укымышлылар шактый булган. Шулардан берсе – XVIII-XIX гасырларда Казанбаш авылында Җәгъфәр улы Бикчәнтәй хәзрәт яшәгән, аның бабасы Мөслим исемле булган. Бу Бикчәнтәй хәзрәт, Уфа шәһәренә имамлыкка имтихан тотарга килгәч, бер «Әхтәри кәбир» (гарәп сүзләренең төрки телдә аңлатмалы сүзлеге) китабы сатып алган. Аның тышлыгына бу хакта хәбәрен язып калдырган. Вафат булуы 1817 елда, Казанбашта икән.

Менә тагын да – Сәйфулла улы Мөхәммәтәмин, Сарман ягы Шыгай авылы муллалары нәселеннән. Бабасы Динмөхәммәт улы Габделхәмит булган. Наласа авылында имам-мөдәррис булып, 1842 елда хаҗ сәфәренә чыгып китә. Каһирә шәһәренә җитеп, монда ил башлыгы Ибраһим патша хозурында кабул ителә. Фарсы теле мөгаллиме Габдеррәшит улы Шәмсетдиннең вафат булуы сәбәпле, Ибраһим патша тарафынан Мөхәммәтәмин аның урынына Әл-Әзһар университетына мөдәррис-профессор итеп билгеләнә. Ул, хаҗын тәмамлый алмыйча, гомеренең соңынача үз эшен зур җаваплылык белән башкара.

Мөхәммәтәмин 1849 елда мәңгелек йортка күчә. Гарәп мәмләкәтләрендә аны олы галим дәрәҗәсендә таный торган булганнар. Гүре Каһирә шәһәрендә. Габденнасыйр Курсави идеяләрен гарәп дөньясына таратучы һәм танытучы, ул ачыклаган сәләфият мәзһәбенә тулысынча бирелүче, мөселманнар арасында җәелдерүче, Идел-Урал ислам әһеленә карата дөнья халыкларында хөрмәт хисләрен тәрбияләүдә зур эшләр башкарган кешеләрнең берсе булуында шик юк.

Мөхәммәтәмин хәзрәт Бохарада, шәкерт булган чагында ук, Габденнасыйр Курсави белән таныша, аннан дәресләр ала һәм ул өйрәткән игътикад-иман юлын дөрес аңлап кабул итә. Дөрес фикерләве, хәтере яхшылык белән аерылып тора. Китаплар да язган. Аның әсәрләрен заманында Ш.Мәрҗани дә укыган. Ул аларны мактап телгә ала. Мөхәммәтәмин хәзрәт Аллаһы Тәгалә хакында Коръәндәге һәм хәдисләрдәге хәбәрләрдән арты-

гын сөйләүне мөселман кеше өчен бозыклыкка һәм ислам дине каршында җинаятькә санаган. Бу хакта Оры, Кенәр, Мәнгәр имамнары белән йөзгә-йөз килеп бәхәсләшә, Габденнасыйр Курсави фикерләрен өстенгә чыгара, хатлар алышып фикерләшә торган булган. Гадәтләре, сыйфатлары, әйткән сүзләре матурлык белән булып, язган китаплары да шул юнәлештә һәм рәвештә булганнар. Алар заманында күп галимнәрне тәрбияләүдә лаеклы урын тотканнар. Аның язган китапларыннан берсе – «Мәгадәнел-макасид», эчтәлеге һәм фикер сөреше белән төгәл аңлаешлы әсәрләрдән, авторы «Кавәметдин Әл-Болгари» дип куелган. Бу – аның галим буларак үзенә алган имзасы.

«Мәгадәнел-мәкасид» китабы Габденнасыйр Курсави хезмәтләре тәэсирендә язылган. Риза Фәхретдинов «Кавәметдин Әл-Болгари» имзасы кемнеке булуын төгәл, фәнни нигездә ачыклауга ирешкән[1]. Ул кичке намаз хакында да бер китап язып, анда үзен, автор буларак, «мөалифе –Мөхәммәтәмин бине Сәйфулла Әл-Болгари Әс-Сабави» дип күрсәткән.

*Фәрит Яхин, профессор,*
*филология фәннәре докторы*

[1] Фәхретдинов Р. Асар.- Алтынчы кисәк.- Оренбург: Ф.Кәрими типографиясе, 1904.- Б. 293.

# Мөселман руханиларына каршы репрессияләр

Большевиклар чорында мөселман руханиларына карата киң таралган репрессияләр инкыйлабка кадәр үк башлана. Гаделлек принципларын тараткан Ислам дине беренче рус инкыйлабы елларында патша Романовлар династиясенең дингә мөнәсәбәтендә чагылмый кала алмый иде.

Бу тенденция XX йөз башындагы зур сәяси үзгәрешләр чорында аеруча көчәя. Патша хакимияте тарафыннан Ислам дине самодержавиегә, дәүләтнең бөтенлегенә яный торган сәяси хәрәкәт буларак карала. Мөселманнарның сәяси активлыгы арту (ә ул бигрәк тә күпчелек очракта руханилардан белем алган формалашып килүче милли интеллигенция вәкилләре арасында күзәтелә) сәяси эзләү аппаратының игътибарын җәлеп итә. Бу игътибарның законлы булуын раслар өчен, рәсми хакимият Россия мөселманнары өммәтендә барган процессларны панисламизм һәм пантюркизм күренешләре дип атый.

Бу очракта Дәүләт Думасы утырышында Пуришкевич чыгышы мисалга китерерлек. Хакимиятнең мөселманнарга карата басымы беренче чиратта реформаторлык хәрәкәтенә ясала. Бу Уфа мөфтияте йогынтысыннан читләшеп, иҗтимагый гаделлекне Исламның рухи башлангычы элементы буларак яклап чыккан Вәисиләр[1] дини хәрәкәтен эзәрлекләүдә аеруча чагылыш таба. Моннан тыш, хәтта «җәдидчелек» дип аталган реформаторлык юлы буенча барырга омтылучы рәсми билгеләнгән руханилар да репрессияләнә.

Жандармерия басымына Россия күләмендә үзенең яңа укыту ысуллары белән дан казанган Әгерҗе өязе Иж-Бубый авылы мәдрәсәсе ду-

[1] Вәисиләр – XIX гасырда Бәһаветдин Вәисов идеяләре нигезендә барлыкка килгән Казан губернасының татар крестьяннары, һөнәрчеләре, вак сәүдәгәрләре дини-иҗтимагый хәрәкәте. – *Тәрҗ.*



чар ителә. Полицмейстер Салов үзенең Казан губерниясе губернаторына мөрәҗәгатендә мулла Галимҗан Галиевнең (булачак мөфти) яңа ысуллар буенча укытуын һәм шул рәвешле панисламизм идеяләрен таратуын хәбәр итә. Г. Галиев (Баруди) инкыйлабка кадәр алдынгы карашлары һәм эшчәнлеге өчен сөргенгә җибәрелә. Большевиклар белән дә дуслыклары булмый. Мөфтинең вафатыннан соң, большевиклар «Кызыл Татарстан» газетасында әдәп-әхлак күзлегеннән бик түбән эчтәлекле «Халык ялгышмасын» мәкаләсен бастыра. Аңа Галимҗан Ибраһимов, Сәлах Атнагулов кебек большевиклар гына түгел, ә шулай ук Фатыйх Әмирхан, Фәтхи Бурнаш кебек шәхесләр дә кул куя. Ә Барудиның җеназасында 12 мең мөселман катнашуына җавап итеп 29.12.21 көнне бастырган мәкаләсендә Г. Баимбәтов хәзрәтне «... мөселманнар арасында контрреволюцияне символлаштыручы фигура» дип тасвирлый.

Россиянкең мөселман халкы 1917 ел вакыйгаларыннан читтә калмый. Большевикларның сәяси лозунглары мөселманнарның мохтаҗ катламына гына түгел, ә мөселман руханиларының (аеруча авыл җирлегендәге)

зур өлешенә дә бик хуш килә. Вәисиләр үзләренең Ислам социализмы идеяләре белән большевикларның якын союздашлары була.

«Болак арты республикасы»ндагы[1] вакыйгалардан соң, мөселман руханилары арасыннан беренче корбан Габдулла Кәрим улы Апанаев була. Мөселман руханиларының яңа хакимияткә лояль мөнәсәбәте аңа хәзрәткә карата кискен чаралар кабул итәргә ирек бирми. Чирәүнең дәүләттән аерылуы халык арасында дини эшчәнлек алып баруда мөселман һәм православ руханиларының мөмкинлекләрен тигезли. Моннан тыш, Исламның идеологик доктринасы яңа сәяси чынбарлыкка тизрәк җайлашу мөмкинлекләре бирә. Бу, башланып киткән үзгәртүләр барышы белән беррәттән, халык арасында аның позицияләре ныгуга китерә.

Аклар хәрәкәте белән турыдан-туры хезмәттәшлек итмәү мөселман руханиларына яңа хакимиятнең яхшы мөнәсәбәтенә өметләнергә нигез бирә, шуңа өстәп, күпчелек татар большевик җитәкчеләре муллалар нәселеннән яки мөселман уку йортларында гыйлем алучылар була. Большевик җитәкчеләре, моны, әлбәттә, истә тота. Большевикларның мөселман фракциясе булуы гаҗәп түгел.

Совет хакимиятенең беренче елларында, зур икътисадый кыенлыкларга карамастан, мөселманнарның дини эшчәнлегенең активлашуы күзәтелә, аеруча бу Татарстанга карый. Бу чиркәү һәм дәүләт мөнәсәбәтләренә бәйле законнар белән дә, Ислам диненә хас яраклашу белән дә аңлатыла. Дәүләт мөселманнар белән үзара мөнәсәбәтләрне рәсми рәвештә билгели, аерым алганда, 30.11.23 көнендә, Кырым, Кавказ һәм Төркмәнстаннан кала, Эчке эшләр Наркоматы РСФСР мөселманнарының рухани оешмасы уставын раслый.

Материалистик идеологиягә юнәлтелгән дәүләт йогынтысы астында булган миллионлаган кеше дини-иҗтимагый институт белән килешә алмаган, билгеле. Ачык каршы тору партиянең мөмкин булган бар ысуллар

[1] «Болак арты республикасы» – Идел-Урал автономияле штатының Совет историографиясендәге атамасы. – *Тәрж.*

белән үткәрелгән атеистик пропагандасы белән яшерелә. Аңа партия һәм комсомол активистлары гына түгел, ә дини эшчәнлекне урыннарда тыя алган администрация һәм түрәләр дә кушылган. Әмма дәүләтнең дингә каршы көрәшендә аеруча зур урынны махсус органнар – Гадәттән тыш комиссия (ЧК) һәм Берләшкән дәүләт сәяси идарәсе (ОГПУ) – алып тора. Патша вакытында кебек үк, сәяси эзләү эчке дини тормышны өйрәнү һәм аңа йогынты ясау өчен яшерен эшчәнлекнең бар формаларын куллана.

ОГПУ үзенең ахыргы максаты итеп руханиларның халыкка йогынтысын дини эшчәнлекне алып баруны эчке яктан бозуны куя, нәтиҗәдә бу руханиларны юк итүгә алыштырыла. 24 елның 2 гыйнварында ОГПУның Татарстан бүлеге җитәкчесе Даниловский РКПнең өлкә комитетына Мәүлид бәйрәмен уздыруда катнашучылар саны артуын хәбәр итә. Органнарны руханилар эшчәнлегендә яңа күренешләр барлыкка килүе дә борчый: мөселманнарның атнасына 1-2 тапкыр Коръән тәфсиренә җыелулары, авыл муллаларының белемнәрен арттыру буенча чаралар (алар программасына хакимият белән эш итүне өйрәнү тәҗрибәсе дә кертелә), яңа шартларга нисбәтле Коръәнне аңлату, Бөтенрусия Үзәк Башкарма Комитеты карарына туры китереп балаларга дини гыйлем бирүне оештыру. Мондый курсларны авыл мөхтәсибәтләрендә дә оештыру планлаштырыла, ОГПУ фикеренчә исә, бу авыл коммунистларының эшләренә зыян салачак.

Үзәкнең күрсәтмәләрен көтмичә, Казан чекистлары Казан мөхтәсибәтендә эчке ызгышларны котырта башлый. Мөхтәсиб Салиховның һәм хуҗалык комиссиясенең яман атын чыгарырга омтылалар.

Мөселман руханиларыннан зур салымнар түләтелә. Мисалга Алабуга кантоны Иске Юраш авылының икенче мәхәллә имамы Шагимардановны китерергә мөмкин. Инспектор аңа 400 сум күләмендә салым билгеләгән. Иң зур баласына 12 яшь булган җиде балалы 53 яшьлек мулла мондый

салымны түли алмагач, атын сатарга мәҗбүр була. Ул шундый салымның ул мулла булганга билгеләнүен аңлый, әмма эшчәнлеген калдыра алмый.

Мөселман руханиларын салымнар белән кысу алар арасында үз вазифаларын калдыру турында фикерләр барлыкка китерә. Арча кантонының өченче мөхтәсибәте имамы 1927 елның февралендә күмәк баш тарту акциясе мөмкинлеге турында фикер белдерә. 1928 елның гыйнвар-февраль айларында 40 имам үз эшеннән баш тарта. Мулла вазифасыннан 17 нче санлы мәчет имамы Вахитов Сәгыйть – татар тарихын өйрәнүче күренекле галим, аның материалларын «Очерки по истории Казанского ханства»ны язганда Михаил Худяков кулланган – баш тарта.

Фәнни экспедицияләр барышында Вахитов Туктамыш хан, Кырым ханы Сәхиб-Гәрәй хан ярлыкларын, хан мөһерләре булган башка документлар таба. Латин графикасына күчү һәм дингә каршы көрәш башлангач, саклап калу максатыннан, ул күп кенә документларны Мәскәүдәге һәм Ленинградтагы Фәннәр Академиясенә тапшыра.

Вазифасыннан баш тартуы хакында ул «Кызыл Татарстан» газетасында яза. Ул фән һәм укыту белән шөгыльләнә, әмма аннан соң өч тапкыр кулга алына. 1937 елда, соңгы кулга алынуында, атарга хөкем ителә. Арест вакытында аның чормасында 3 ящик иске китаплар табыла. 1939 елда Берия кушуы буенча, кулга алынганнарда табылган китап һәм кулъязмалар яндырыла. Вахитовта табылган китаплар да шулай юк ителгән, дип фаразларга мөмкин.

Бу шартларда имам вазифасыннан баш тартулар ОГПУ органнары өчен отышлы булмый, чөнки алар мөселманнар белән йөзгә йөз калырга тиеш булачак, бигрәк тә авыл җирлегендә. Шуңа өстәп, элеккеге муллалар урынына элек Совет учреждениеләрендә эшләгән яки бөтенләй гыйлемсез кешеләр килә башлый. Нәкъ шул сәбәпле, ОГПУ үзенең таләпләрен үтәүче муллаларның китүенә каршы чыга.

Шулай итеп алар Дөбъяз районы Сулабаш авылы мулласы Хәсән Гата Мөхәммәдовны, ул вакытта ук билгеле композитор Солтан Габәшинең әтисен, калдыра. Шуңа өстәп, мәҗбүри рәвештә, аңа мөхтәсиб вазифасы да йөкләнелә. Әмма 2 июнь көнне Хәсән Гата Мөхәммәдов «Сыйратүлмөстәкыйм» монархистик оешмасында торуда гаепләнә һәм кулга алына.

Бөтенрусия Үзәк Башкарма Комитетының 1924 елгы декреты буенча балаларга дини белем бирү рөхсәт ителсә дә, җирле хакимият бу мәсьәләдә һәрдаим төрле кыенлыклар тудырып тора. Татарстан хакимияте бу эштә бигрәк тә аерылып чыга, ул 18 яшьтән өлкәнрәкләргә генә дини гыйлем бирергә рөхсәт итә һәм дөньяви фәннәр өйрәтүне тыя. Урындагы түрәләр бернинди нигезсез дини мәктәпләр ачуны тыя. Кантон милициясе балаларга дини белем бирүне тыйганнан соң, Чистай кантоны Курманай авылыннан Гыймадеддинов ВКП (б) комитеты секретарена хатында болай дип яза: «Коммунистлар дингә каршы пропаганданы оештыра алмады, һәм хәзер алар дингә каршы административ ысуллар белән көрәшә». Хатын мондый сүзләр белән тәмамлый: «Без курыкмыйбыз, һәм берничә мәхәллә исеменнән рөхсәт бирүне таләп итәчәкбез. Рөхсәт итмәсәләр, барыбер балаларны укытачакбыз. Коммунистлар җиңеләчәк, һәм без җиңүчеләр булачакбыз».

Балаларга дини гыйлем бирү мәсьәләсе Әгерҗе, Алабуга кантоннары авыллары мөселманнары тарафыннан актив күтәрелә. Кызлар өчен дә, малайлар өчен дә теркәлмәгән мәктәпләр барлыкка килә башлый. 1926 елның 1 маена Чистай кантонының 69 совет мәктәбендә 6454 кеше белем алган, 37 дини мәктәптә – 892 кеше. 1927 елның 1 гыйнварына республикада рәсми дини мәктәпләрнең саны 207 була, аларда биш меңнән артык кеше укыган, шул ук вакытта рөхсәтсез 35 мәктәп эшләп килгән, шәкертләре саны 500 балага якын булган.

Шиксез, хакимият моңа җавапсыз кала алмый. Бу башлангыч дини белем бирә торган мәктәпләрнең мөгаллимнәре (алар арасында мулла-

лар һәм аларның җефетләре күп була) кулга алына, административ җәза ала. 1926 елның июленнән 1927 елның сентябренә кадәр 32 дин эшлеклесе җавапка тартыла, алар арсыннан ике ханым Шакурова Гайшә һәм Сафина Фатыйма берничә айга иректән мәхрүм ителә.

*(Дәвамы бар)*

*Ровель Кашапов*

# Нәсыйхәт

# Локман Хәкимнең Коръәндә әйтелгән нәсыйхәтләре

Локман Хәким, хикмәткә ия булгач, үзенең хатынын һәм балаларын бер Аллаһы Тәгаләне генә танырга чакыра. Пәйгамбәребез S : «Һәр яхшы сүз – сәдака»[1], – дигән. Ә инде иң күркәм һәм иң яхшы сүз «Ләәә иләәһә илләлааaһ» кәлимәсе, шул сүз генә җәннәткә ачкыч булып тора. Аллаһының Рәсүле S әйткән: «Аллаһы Тәгаләдән башка гыйбадәт кылырлык зат булмавына һәм минем Аллаһының илчесе булуыма шаһитлек иткән, шушыңа чын күңелдән ышанган һәр кеше, шул халәтендә Раббысы каршына килсә, ул һичшиксез җәннәткә керәчәк!»[2]. Шулай ук Пәйгамбәребез S Әбү Һүрайрага: «Бар, бу дивар артында Аллаһы Тәгаләдән башка гыйбадәт кылырлык һичбер зат булмавына (Ләәә иләәһә илләәлааһ) ихлас ышанган һәр кешене җәннәт белән сөендер»[3], - дигән.

«Сәдаканы үзеңнән һәм гаиләңнән башла»[4], дигән хәдис бар. Аллаһы Тәгаләне таныгансың икән, хатыныңны, балаларыңны Аның берлеген танырга һәм зурларга өйрәт, хикмәт белән, сабырлык белән. Күп вакыт иң якыннарыңны өндәү читләрне өндәүгә караганда авыррак. Чөнки алар синең хакта башкалар белмәгәнне дә белә.

Локман Хәким улына нәсыйхәт кылып әйткән:

﴿ وَإِذۡ قَالَ لُقۡمَٰنُ لِٱبۡنِهِۦ وَهُوَ يَعِظُهُۥ يَٰبُنَيَّ لَا تُشۡرِكۡ بِٱللَّهِۖ إِنَّ ٱلشِّرۡكَ لَظُلۡمٌ عَظِيمٞ ١٣ ﴾

---

1 Имам әл-Бохари, Мөслимнең хәдисләр җыентыклары

2 Имам Мөслимнең хәдисләр җыентыгы

3 Имам Мөслимнең хәдисләр җыентыгы

4 Имам ән-Нәсәинең хәдисләр җыентыгы

**«Син Аллаһы Тәгаләдән башка берәр затка табынып ширек кылма. Хактыр ки, күп илаһларга табыну, ширек кылу – зур золымлык».**

«Локман», 34:13

Пәйгамбәребез S сәхабәләргә бу аятьтә «золым» (гаделсезлек) сүзе астында зур ширек кылу һәм көферлек ятканын аңлаткан. Алар аркасында кеше Раббысының ачуына дучар була. Шул сәбәпле аны мәңгелек җәза көтә. Ширек кылу ул гафу ителми торган зур гөнаһ. Шуңа Локман Хәким үзенең улына: «Күпаллалык зур гаделсезлек санала», – дип әйткән.

Сыннарга табыну һәм күпаллалык, чыннан да, зур гаделсезлек, җир йөзендә моннан да зур гөнаһ юк. Юктан бар ителгән әйберләрне, туфрактан яратылганнарны ничек итеп бар дөньяны Яратучыга тиңләп була? Ничек итеп бернинди хәкимлеккә ия булмаган колларны Идарә итүчегә тиңләп була? Ничек итеп Аллаһы ярдәменә һәр мизгел саен мохтаҗ булган, камил булмаган әйберләрне бер нәрсәгә дә мохтаҗ булмаган һәм камил Затка тиңләп була? Моннан да зур гаделсезлек була аламы?!

Бу турыда Аллаһы Раббыбыз Коръәни Кәримдә күп урыннарда әйтә. Шуларның кайберләре:

﴿ أَيُشْرِكُونَ مَا لَا يَخْلُقُ شَيْـًٔا وَهُمْ يُخْلَقُونَ ﴿١٩١﴾ وَلَا يَسْتَطِيعُونَ لَهُمْ نَصْرًا وَلَآ أَنفُسَهُمْ يَنصُرُونَ ﴿١٩٢﴾ ﴾

**«Ул мөшрикләр һичнәрсәне бар итәргә көче җитмәгән нәрсәләрне Аллаһыга тиң кылалармы? Ул нәрсәләр үзләре дә халык кылынганнар. Алар мөшрикләргә ярдәм бирергә кадир түгелләр һәм ул нәрсәләр үзләренә дә ярдәм итә алмаслар».**

«Әгъраф /Пәрдә», 7:191-192

Шулай ук Раббыбыз әйтә:

﴿ قُلِ ٱلۡحَمۡدُ لِلَّهِ وَسَلَٰمٌ عَلَىٰ عِبَادِهِ ٱلَّذِينَ ٱصۡطَفَىٰٓۗ ءَآللَّهُ خَيۡرٌ أَمَّا يُشۡرِكُونَ ٥٩
أَمَّنۡ خَلَقَ ٱلسَّمَٰوَٰتِ وَٱلۡأَرۡضَ وَأَنزَلَ لَكُم مِّنَ ٱلسَّمَآءِ مَآءٗ فَأَنۢبَتۡنَا بِهِۦ حَدَآئِقَ
ذَاتَ بَهۡجَةٖ مَّا كَانَ لَكُمۡ أَن تُنۢبِتُواْ شَجَرَهَآۗ أَءِلَٰهٞ مَّعَ ٱللَّهِۚ بَلۡ هُمۡ قَوۡمٞ
يَعۡدِلُونَ ٦٠ ﴾

**«Аллаһы Тәгалә хәерлерәкме яки Аңа тиңдәш кылынган илаһлармы? Кем җир вә күкләрне халык итте, сезгә күктән су иңдерде? Шул су белән чәчәккә күмелгән күп җимеш бакчаларын үстердек, ул бакчаларның агачларын үстерү сезгә лаек булмады (ягъни аларны үстерергә көчегез җитми). Шулай булгач Аллаһыдан башка тагын бер илаһ бармы? Әлбәттә, юк, бәлки алар (уйлап чыгарылган илаһка табынучылар) хак юлдан авышкан кавемдер».**

«Нәмел /Кырмыска», 27:59-60

﴿ أَمَّن جَعَلَ ٱلۡأَرۡضَ قَرَارٗا وَجَعَلَ خِلَٰلَهَآ أَنۡهَٰرٗا وَجَعَلَ لَهَا رَوَٰسِيَ وَجَعَلَ
بَيۡنَ ٱلۡبَحۡرَيۡنِ حَاجِزًاۗ أَءِلَٰهٞ مَّعَ ٱللَّهِۚ بَلۡ أَكۡثَرُهُمۡ لَا يَعۡلَمُونَ ٦١ ﴾

**«Кем җирне селкенми торган итеп, дәхи җир өстендә күп елгалар, бөек таулар бар итте, бер-берсе белән кушылмасыннар өчен, диңгездә ике төрле су арасына пәрдә кылды? Аллаһыдан башка тагын бер илаһ бармы? Бәлки мөшрикләр Аллаһының бер генә икәнен белмиләрдер».**

«Нәмел /Кырмыска», 27:61

﴿ أَمَّن يُجِيبُ ٱلۡمُضۡطَرَّ إِذَا دَعَاهُ وَيَكۡشِفُ ٱلسُّوٓءَ وَيَجۡعَلُكُمۡ خُلَفَآءَ
ٱلۡأَرۡضِۗ أَءِلَٰهٞ مَّعَ ٱللَّهِۚ قَلِيلٗا مَّا تَذَكَّرُونَ ٦٢ ﴾

**«Кем җәберләнгән кешенең догасын кабул итә, кешеләрдән зарарны җибәрә? Ул сезне җиргә хуҗа кылды. Аллаһыдан башка тагын бер илаһ бармы? Бик аз вакытта вәгазьләнәсез!»**

«Нәмел /Кырмыска», 27:62

﴿ أَمَّن يَهْدِيكُمْ فِي ظُلُمَاتِ الْبَرِّ وَالْبَحْرِ وَمَن يُرْسِلُ الرِّيَاحَ بُشْرًا بَيْنَ يَدَيْ
رَحْمَتِهِ ۗ أَإِلَٰهٌ مَّعَ اللَّهِ ۚ تَعَالَى اللَّهُ عَمَّا يُشْرِكُونَ ﴿٦٣﴾ ﴾

**«Кем сезне төн караңгылыгында корыда һәм диңгездә йолдызлар белән адаштырмыйча йөртә, сезгә яңгыр алдыннан рәхмәт җилен җибәрә? Аллаһыдан башка тагын бер илаһ бармы? Аларның Аллаһыга тиң кылган нәрсәләреннән Раббыбыз пакь һәм бөек».**

«Нәмел /Кырмыска», 27:63

﴿ أَمَّن يَبْدَأُ الْخَلْقَ ثُمَّ يُعِيدُهُ وَمَن يَرْزُقُكُم مِّنَ السَّمَاءِ وَالْأَرْضِ ۗ أَإِلَٰهٌ مَّعَ اللَّهِ ۚ قُلْ
هَاتُوا بُرْهَانَكُمْ إِن كُنتُمْ صَادِقِينَ ﴿٦٤﴾ ﴾

**«Башта юктан бар итеп, соңрак үлгәннән соң тергезүче Аллаһы Тәгалә хәерлерәкме яки мөшрикләрнең сыннарымы? Сезне күктән һәм җирдән кем ризыкландыра? Раббыбыз кыла торган эшләрне Аллаһыдан башка эшли ала торган илаһ бармы? Әгәр янә бер илаһ бар дигән сүзегез дөрес булса, дәлилегезне китерегез».**

«Нәмел /Кырмыска», 27:64

Раббыбыз гыйбадәт кылу өчен бар кылган бәндәсенең әһәмиятсез булган башка яратылганнарга гыйбадәт кылуын кичерми. Һәрнәрсәне Бар кылучы, көдрәтле һәм бөек Раббыбыз әйтә:

﴿ إِنَّ ٱللَّهَ لَا يَغۡفِرُ أَن يُشۡرَكَ بِهِۦ وَيَغۡفِرُ مَا دُونَ ذَٰلِكَ لِمَن يَشَآءُۚ وَمَن يُشۡرِكۡ بِٱللَّهِ فَقَدِ ٱفۡتَرَىٰٓ إِثۡمًا عَظِيمًا ٤٨ ﴾

**«Аллаһы Тәгалә Үзенә тиңдәшлек кылуны гафу итми, тиңдәшлек кылудан башка гөнаһларны Үзе теләгән кешегә гафу итәр. Бер кеше Аллаһыга кемнедер, нәрсәнедер тиңдәш кылса, дөреслектә, ул Аллаһыга олы ялганны ифтира кылган була».**

«Нисә /Хатыннар», 4:48

Кешенең Аллаһы Тәгалә алдындагы иң зур бурычы – күпаллалыктан ваз кичү. Моның өчен кеше бер Аллаһыга гына итагать итәргә тиеш.

Аллаһы Тәгалә Үзенең колларына әти-әниләре алдындагы бурычларны үтәргә фарыз кылып әйтә:

﴿ وَوَصَّيۡنَا ٱلۡإِنسَٰنَ بِوَٰلِدَيۡهِ حَمَلَتۡهُ أُمُّهُۥ وَهۡنًا عَلَىٰ وَهۡنٖ وَفِصَٰلُهُۥ فِي عَامَيۡنِ أَنِ ٱشۡكُرۡ لِي وَلِوَٰلِدَيۡكَ إِلَيَّ ٱلۡمَصِيرُ ١٤ ﴾

**«Кешегә Без ата-анасына яхшылык итәргә әмер иттек, баланы анасы зәгыйфьлек өстенә зәгыйфьлек белән күтәрә, ягъни корсагында авырлык белән күтәрә һәм авырлык белән тудыра, баласын ике ел имезә. Кешегә Миңа һәм ата-анаңа шөкер ит, дип боердык, чөнки ахырда Миңа кайтарылачаксыз».**

«Локман», 31:14

Әлеге аятьтә Аллаһы Тәгалә кешегә әти-әнисенә карата рәхимле булырга куша һәм бу хакта Ул, һичшиксез, колыннан сораячак. Кеше Аллаһы Тәгаләгә шөкер итәргә, гыйбадәт кылырга, Аның алдында булган бурычларын үтәргә һәм Раббым мәрхәмәтле, Ул мине гафу итәчәк дип, гөнаһ эшләмәскә тиеш. Болар белән беррәттән әти-әниләргә карата да ихтирамлы булырга, алар белән кыска, төгәл итеп сөйләшергә, алар алдында үзеңне түбәнчелекле тотарга, аларга хөрмәт белән карарга, ярдәм итәргә,

яхшылык эшләргә һәм аларны кимсетүче, аларның күңелләрен калдыручы сүзләр сөйләмәскә, гамәлләр кылмаска кирәк.

Аллаһы Тәгалә бу аятьне җибәреп әниләребезгә карата булган бурычларыбызны йөкләү белән бергә Үзенең хозурына кайтачагыбызны да исебезгә төшерә. Раббыбызның кушканнарын үтәү-үтәмәвебез турында барыбыз да җавап тотачакбыз. Үтәгән булсак, зур әҗер алачакбыз, киресе булганда, җәзага тартылачакбыз.

Чыннан да, яралгы барлыкка килгәч, хатын-кыз көчсезләнә, зур авырлыклар белән баласын карынында йөртә, бик көчле авыртуларга сәбәп булган тулгак ачысын татый. Бала тугач әни кеше аны карый, тәрбияли, ике ел дәвамында күкрәк сөтен имезә. Шундый зур авырлыкларга сабыр иткән һәм баласын башкаларга караганда катырак яраткан әниебезгә карата яхшы мөгамәләдә булу безнең бурычыбыз тугелмени?

﴿ وَإِن جَٰهَدَاكَ عَلَىٰٓ أَن تُشْرِكَ بِى مَا لَيْسَ لَكَ بِهِۦ عِلْمٌ فَلَا تُطِعْهُمَا ۖ وَصَاحِبْهُمَا فِى ٱلدُّنْيَا مَعْرُوفًا ۖ وَٱتَّبِعْ سَبِيلَ مَنْ أَنَابَ إِلَىَّ ۚ ثُمَّ إِلَىَّ مَرْجِعُكُمْ فَأُنَبِّئُكُم بِمَا كُنتُمْ تَعْمَلُونَ ١٥ ﴾

> **«Әгәр әти-әниең сине илаһ икәнлегенә дәлилең булмаган нәрсәне Миңа ширек кылуга көчләсәләр, ул вакытта аларга итагать итмә, аларга дөнья эшләрендә һаман яхшылык кыл, диндә Мине берләү һәм итагать итү белән Миңа инабәт иткән мөэминнәр юлына ияр, ахырдан Миңа кайтарылырсыз һәм Мин кылган эшләрегездән үзегезгә хәбәр бирермен».**

«Локман», 31:15

Без әти-әниләребезне хөрмәт итәргә тиешбез. Бары Аллаһы Тәгаләгә нәрсәне дә (кемне дә) булса тиңләргә чакырганда, фарызларны үтәүдән тыйганда, хәрәмгә өндәгәндә генә аларга каршы килү рөхсәт ителә. Бу очракта әти-әниләрне тыңламау аларны хөрмәт итмәү булып саналмый,

чөнки башка яратылганнарга караганда кешенең Раббысы каршындагы бурычлары мөһимрәк. Бар итүчегә каршы килеп, яратылганнарга буйсыну тыела.

Әти-әниләр мәҗүсилек һәм күпаллалыкка чакырсалар, хәрәм эшләр кылсалар да, аларны хөрмәт итәргә кирәк. Раббыбыз, бары гөнаһ кылырга боерган очракта гына әти-әниләргә буйсынмаска, ди, ләкин әлеге очракта да аларга карата яхшы мөгамәләдә булырга куша.

Пәйгамбәребез S : «Әтиең гөнаһ кылырга барганда булышма, әмма кайтканда каршы ал», – ди. Начар эштә аларга ярдәм итәргә ярамаса да, гөнаһ кылуларына карамастан, әти-әниләребез булган өчен генә булса да, без аларны хөрмәт итәргә, тәрбияләргә тиеш.

﴿ وَقَضَىٰ رَبُّكَ أَلَّا تَعْبُدُوٓا۟ إِلَّآ إِيَّاهُ وَبِٱلْوَٰلِدَيْنِ إِحْسَـٰنًا ۚ إِمَّا يَبْلُغَنَّ عِندَكَ ٱلْكِبَرَ أَحَدُهُمَآ أَوْ كِلَاهُمَا فَلَا تَقُل لَّهُمَآ أُفٍّ وَلَا تَنْهَرْهُمَا وَقُل لَّهُمَا قَوْلًا كَرِيمًا ﴿٢٣﴾ ﴾

**«Фәкать Аллаһыга гына гыйбадәт кылырга һәм ата-анага изгелек итәргә Аллаһы Тәгалә хөкем итте һәм әмер бирде. Әгәр син исән чакта аларның берсе яки икесе дә картлыкка ирешсәләр, син аларга «уф» та димә, каһәрләмә, кәефләрен җибәрмә, аларга һәрвакыт йомшак һәм мөлаем сүзләр сөйлә!»**

«Бәни Исраил /Ягъкуб балалары», 17:23

Аллаһы Тәгалә кешегә бу дөньяда әти-әнисенә яхшылык кылырга, бары диннән читләштерүгә һәм Раббыбызга итагать итмәскә этәргән очракта гына аларга буйсынмаска куша.

*Җәлил хәзрәт Фазлыевның*

*«Локман Хәким нәсыйхәтләре» китабыннан*

# Пәйгамбәребезнең S кичерү сәләте

Аллаһ Үз колларын кичерергә ярата. Кеше кылган гөнаһларында үкенеп, ихлас тәүбә кылса, Аллаһ киң кодрәте илә аны ярлыкар. Коръәндә Ул Үзенең Гаффар (Кичерүче) икәнен әйтә, һәм колларының да мәрхәмәтле, кичерә белүче булуларын таләп итә.

Бу сыйфатларның иң югары үрнәге – Мөхәммәд пәйгамбәр S .

Өхед сугышыннан соң Һинд исемле хатын Пәйгамбәребезнең S яраткан абзыйсы Хәмзәнең бавырын тартып ала һәм чәйни башлый. Ә Пәйгамбәр S , аның Ислам кабул итүен белгәч тә, аны кичерә. Бу Мәккә алынганның беренче көнендә була. Пәйгамбәрнең S артында басып торган Һинд:

– Расүлүллаһ, син мине таныдыңмы? – дип сорый.

Мөхәммәд S , сигез ел үтүенә карамастан, аның тавышын хәтерләвен аңлатып:

– Мин синең тавышыңны оныта аламмы соң? – ди.

Шуңа да карамастан, Пәйгамбәр S Һиндне гафу иткән.

Мәккә яулангач, Пәйгамбәр куркып хөкем көткән шәһәр кешеләреннән:

– Ий корәешлеләр! Мин сезгә карата нинди хөкем чыгарырмын, дип уйлыйсыз? – дип сорый.

– Без синең мәрхәмәтлелегеңә ышанабыз.

– Мин сезгә Йосыф пәйгамбәрнең абыйларына биргән җавапны бирәм: «Сезне бүген гаепләү дә, шелтәләү дә юк. Барыгыз! Сез ирекле!» – ди Мөхәммәд пәйгамбәр S .

Әбү Җәһелнең улы Икрима мөселманнарның иң зур дошманнарыннан була. Ислам кабул итүеннән соң, Пәйгамбәр S аның бар явызлыкларын кичерә.

Хәбир бин Әсәд шулай ук Ислам дошманнарыннан иде. Мөхәммәднең S кызы Зәйнәб Мәккәдән Мәдинәгә һиҗрәт кылганда, Хәбир аны дөясеннән этеп төшергән. Көмәнле Зәйнәб егылганда яралана һәм баласы төшә. Моннан тыш та Хәбирнең явызлыклары күп булган. Ислам кабул иткәннән соң, Пәйгамбәр аны да гафу иткән. Пәйгамбәребез еш кына:

– Аллаһым! Кардәшләремнең гөнаһларын кичер, чөнки алар аларны белми кылалар! – дип дога кылган (Ибн Мәҗа).

## Пәйгамбәрнең S хатын-кызларга мөнәсәбәте

«Нисә» сүрәсендә Аллаһ: **«Ий мөэминнәр, хатыннарны көчләп, мирас урынына тоту сезгә хәләл түгел»**, – ди (4:19). Шул рәвешле ирләргә хатыннарын кадерләргә куша. Пәйгамбәребезнең S тормышы үрнәк булып торган җәмгыятьтә хатын-кызлар элек беркайчан күрмәгән дәрәҗә һәм статуска ирешә. Иң яхшы ир-ат дип ул S хатынына яхшы мөнәсәбәт күрсәткән ирне атаган, үзенең дә хатыннарына бик мәрхәмәтле булуын әйткән. Ә ул заманнарда гарәпләрдә хатыннарына карата дорфа булучыларны бик ихтирам иткәннәр. Расүлуллаһ S хатын-кызларны хөрмәт иткән, аларның фикерләренә игътибарлы булган, аларга хокуклар биргән. Һәм хатын-кызлар да үзләренең кирәкле, кадерле күркәм затлар булуын аңлый башлый.

Пәйгамбәр S яхшы ирнең иң матур үрнәге була. Ул хәләл җефетләренә мактау сүзләре әйтеп торган, хисләрен бик күркәм рәвештә җиткергән, үз янына дөясенә утыртып йөргән, аларның елаганын күрсә, күз яшьләрен кулы белән сөрткән, тынычландырырга тырышкан. Надан ирләр хәез вакытында хатыннарын санга сукмаган. Пәйгамбәр S исә мондый мөнәсәбәтне тыеп, бу көннәрдә хатыннарына аеруча игътибарлы

булган. Хәезне хатын-кыз организмының табигый халәте икәнен аңлап, ул җефетен аңа чәчләрен юышырга ярдәм итәргә сораган, аңа терәлеп утырып Коръән укыган (Бохари), ягъни шул рәвешле ул читләшмәвен күрсәткән. Хатын-кызларга мондый мөнәсәбәт очраклы яки вакытлы күренешләр булмый, ә Пәйгамбәрнең s бөтен яшәү рәвешенә хас була. Өйлә намазыннан соң ул көн дә һәр хатынының хәлен белешә торган була, сәламәтлекләре һәм мәшәкатьләре турында сораштыра (Бохари, Мөслим). Бер көнне дә калдырмый, хәтта Зәйнәб бин Җәһшкә өйләнгән көнне дә ул, Гайшәдән башлап, бар хатыннарына кереп, хәлләрен белешеп чыга. Һәм һәр хатыны аны сәламләп: «Яңа җефетең ничек? Аллаһ аннан да, синнән дә риза булсын!» – сүзләре белән котлый (Бохари).

Гайшә g дә Пәйгамбәрнең s хатыннарга мөнәсәбәте хакында хәдисләр тапшыра: «Иртәнге намазның сөннәтеннән соң, мин уянган булсам, Пәйгамбәр s минем белән сөйләшә иде, әгәр мин әле тормаган булсам, мәчеттә камәт әйтүләрен көтеп, янымда ятып тора иде». Шулай ук хатыннары ял итсен һәм күңел ачсын дип, Пәйгамбәрнең s алар белән төрле бәйрәм чараларына баруы билгеле.

Расүлүллаһ s хатын-кызларның тәрбиясе һәм белем бирүне бик әһәмиятле санаган. Беренче чиратта ул моны үз йортында хатыннарына белем бирү аша тормышка ашырган. Алар исә бар алган гыйлемнәрен башка хатын-кызларга тараткан, Ислам нигезләрен җиткергән. Пәйгамбәребез s укытуны әңгәмә яки нәсыйхәт рәвешендә оештырган.

## Пәйгамбәребезнең s ятимнәргә мөнәсәбәте

Пәйгамбәребезнең s хәдисендә: «Иң күркәм йорт – ятимнәргә яхшы мөнәсәбәт күрсәтелгән йорт. Иң начар йорт – ятимнәргә начар мөнәсәбәт

күрсәтелгәне!» – диелгән. Тагы бер хәдистә бу болай дәлилләнә: «Ятимне тәрбияләүче һәм яклаучы белән без Җәннәттә шушы ике бармак кебек янәшә булырбыз», – бу сүзләрне әйткәндә Пәйгамбәребез S имән бармагы белән урта бармагын күрсәткән. Ул сәхабәләреннән һәрвакыт: «Сез бүген ятимне башыннан сыйпадыгызмы? Авыруның хәлен белдегезме? Берәрсенең кайгысын уртаклаштыгызмы?» – дип сорый торган була (Тәбәрани, Сахибүл-җәмигъ, 80).

Янә бер хәдистә: «Әгәр берәү Аллаһ ризалыгы өчен ятимне башыннан сыйпаса, Аллаһ аңа шушы ятимнең башындагы чәч бөртеге кадәр савап бирер», – диелгән (Әхмәд ибн Хәнбәл).

Исламгача кадәрге чорда ятимнәр бик күп булган. Аларны мыскыл иткәннәр, хакларын үтәмәгәннәр. Расүлебез S дә ятим үскән, һәм кабиләсенең ятимнәргә мөнәсәбәтен яхшы белгән. Аллаһ аңа мөрәҗәгать итеп: **«Раббың сине ятим хәлендә табып, тәрбия урынын насыйп итмәдеме?»** – ди (93:6). Һәм: **«Шул сәбәпле, ятимнәрне җәберләмә»**, – дип боера (93:9). Аллаһ сөекле пәйгамбәрен Үзе тәрбияләгән, саклаган һәм Мөхәммәдкә S башка ятимнәрне якларга, аларны кайгыртырга нәсыйхәтләгән. Әлбәттә, бу һәр мөэмингә дә карый.

Галәмнәр горурлыгы Расүлуллаһ S ятимнәр мәсьәләсенә пәйгамбәрлегенең башлангыч чорында ук зур игътибар бирә башлый. Йәмәнгә беренче һиҗрәт кылучы мөселманнарның башлыгы Җәгъфар бин Әбү Талиб d илнең патшасы Нәҗашига мөселманнар һәм Ислам дине турында сөйләгәндә Пәйгамбәр S турында болай ди: «Ул һәрвакыт мохтаҗлар һәм көчсезләр янында, ул ятимнәрнең мөлкәтен кулланырга яки аны үзеңә алырга тыйды» (Ибн Һишам, «Әссиратүн-нәбәвия»).

# Йәгез, бер дога

# Дога – гыйбадәтнең асылы

Аллаһның Үзенә якын бәндәсен хөрмәтләвенең бер билгесе – бәндәсенең догасын кабул итүе; ярдәм сораса, ярдәм бирүе; яклау сораса, яклавы. Дога – гыйбадәтнең асылыдыр, чөнки кеше башка беркемгә дә өметләнмәгәндә, Аллаһка дога кылып, Аңа мөрәҗәгать итә. Пәйгамбәребез S әйткән:

«Төн саен Аллаһы Тәгалә (Аның рәхмәте) дөнья күгенә иңә һәм: «Дога кылучы бармы? Аның догасын кабул итәм. Сораучы бармы? Аңа сораганын бирәм», – дип сорый».

Дога кылганда күңелнең ихлас булуы зарури. Һәм бөтен барлык белән Аллаһы Тәгаләгә түбәнчелек күрсәтеп сорарга кирәк. Күңел ихлас булса һәм кабул булуында шик булмаса, дога, теләсә нинди вакытта һәм теләсә нинди телдә дә кабул булачак.

## Дога һәм тәкъдир

«Әгәр бөтен нәрсә алдан билгеле икән, ни өчен без дога кылып, Аллаһка үтенәбез?» – дип сораучылар бар.

Әйе, тәкъдир билгеләнгән, ләкин без аны белмибез. Намаз – җәннәт ачкычы, ләкин һәр намаз укучы үзен җәннәттә дип әйтә аламы? Шуңа күрә без өмет итәбез, шуңа күрә дога кылабыз.

Пәйгамбәребез S әйтте: «Дога – гыйбадәтнең җелеге». Аллаһы Тәгалә дога кылганны, ихлас күңелдән сораганны ярата, чөнки дога – ул үзеңне кол итеп тану, Аллаһның ярдәменә мохтаҗ булуыңны күрсәтү (дога кылганда кул күтәрү исә ул – ялвару билгесе).

Безнең белән булачак барлык хәлләр билгеләнгән (тәкъдир кылынган) булса да, без һәрвакыт догада булырга тиеш. Дога кылуның төп максаты – һәр нәрсәнең хәерле тәмамлануын сорау (яхшылыкның да, яманлыкның да, шатлыкның да, кайгының да), ягъни һәрбер хәлнең ахы-

ры дөньябыз өчен һәм бигрәк тә ахирәттәге тормышыбыз өчен файдалы булуын сорарга кирәк.

Туры юлга күндерүне, гөнаһларны гафу итүне, җәһәннәм утыннан саклауны һәм җәннәткә кертүне сорау – бәндә Раббысыннан сорарга мөмкин булган нәрсәләрнең иң әһәмиятлеләре.

Кешенең Аллаһы Тәгалә каршындагы дәрәҗәсе Аңа кылынган дога вә гыйбадәте белән бәяләнә. Дога вә гыйбадәте булмаган кешенең Аллаһы Тәгалә каршында бер дәрәҗәсе дә калмый. Пәйгамбәребез S болай дип әйтте:

«Аллаһ Тәгалә дога кылмаган кешегә ачулана».

Аллаһ Тәгалә дә «Аеручы» сүрәсендә болай дип әйтә:

**«Әйт: «Әгәр Аллаһка ялваруыгыз һәм гыйбадәтегез булмаса, Аллаһ сезнең белән нәрсә эшләр иде, ягъни Аллаһка гыйбадәт кылмасагыз һәм итагать итмәсәгез, Аңа ни өчен кирәксез?»**

Аллаһка гыйбадәт кылу намаз уку, зәкәт түләү, ураза тоту гына түгел. Аллаһ разый була торган һәрбер гамәл гыйбадәт булып санала. Дога – олуг гыйбадәт. Чын күңелдән дога кылганда мөэмин-мөселман түбәнчелек белән Аллаһтан ялвара, Раббысына кол була.

## Дога кабул була торган очраклар

Аллаһка дога кылучының йөрәге Аңа гына юнәлгән булса һәм дога кабул була торган 6 вакытның берсенә туры килсә, Аллаһның хикмәте белән, бу дога җавапсыз калмас.

Ул вакытлар түбәндәге:

- төннең соңгы 1/3 өлеше;
- азан вакытында;
- азан белән камәт аралыгында;
- фарыз намазлардан соң;
- имам мөнбәргә менеп, җомга хөтбәсен тәмамлаганчы;

- җомганың соңгы сәгатендә (икенде намазыннан соң) кылынган дога, Аллаһның кодрәте белән кабул кылыныр.

Шулай ук дога кылучының йөрәге тәкъвалык белән тулы булып, кыйбла тарафына юнәлеп, тәһарәтле килеш, үзенең догасын Аллаһ Тәгаләне мактаудан, Пәйгамбәребезгә S салават әйтүдән башласа, бу дога кылучыга хәерлерәк булыр. Шушы сүзләрдән соң кулларын догага күтәргән кеше үзенең гөнаһларына ярлыкау сорарга тиеш.

Дога кылучы кешенең телендәгесе йөрәгендә дә чагылыш табарга тиеш. Йөрәге исә курку һәм өмет хисе белән тулы булырга, Аллаһы Тәгалә аның догасын һичшиксез кабул итәчәк икәненә инанган булырга тиеш.

Пәйгамбәребезнең S күп кенә хәдисләрендә сораган вакытта Аллаһы Тәгаләнең гүзәл исемнәре белән сорау хуплана, дип әйтелгән.

Әнәс ибн Мәлик тапшырган хәдистә Пәйгамбәребезне берәр нәрсә борчыганда, аның: «И Мәңге Исән (Әл-Хәййү) һәм барлыкка китерелгән һәр нәрсәгә Тереклек бирүче (Әл-Кайййүм), Үзеңнең Рәхмәтеңә өмет итеп, Синнән ярдәм сорыйм», – дип соравы китерелә.

## Кемнең догасы кабул була?

Пәйгамбәребез S бу турыда бер хәдисендә болай дигән:

«Өч төрле кешенең догасы кабул булыр: мәзлумның (җәбер-золым күргәннәрнең), мосафирның һәм ата-ананың балаларына карата кылган догалары кабул булыр». Догасы кабул булганнардан берсенә Пәйгамбәребез S болай дип мөрәҗәгать иткән:

«Әй Мүгаз! Мәзлумның догасыннан саклан, чөнки аның белән Аллаһ арасында догасының кабул булуына киртә булырлык пәрдә юктыр».

Икенче бер хәдистә болай дип әйтелә: «Өч кешенең догасы кире кайтарылмас: авыз ачуга кадәр – ураза тотучының, гадел хөкем итүче дәүләт башлыгының, золымга очраган кешенең. Аллаһ боларның догаларын болытлар өстенә чыгарыр, күк капусларын ачар һәм шулай дип әйтер: «Дан

вә гыйззәтем беләи ант итәмен ки, бер заман соң булса да сиңа ярдәм итәрмен».

Бу хәдисләрнең һәрберсендә мәзлумнарның догалары кабул булачагы турында әйтелә.

Золым Ислам диненең һичбер шартына туры килмәгән һәм бер вакытта да хупланмаган, киресенчә, зур гөнаһлардан саналган. Шул сәбәпле булса кирәк, хәдисләрдә мәзлум догасының кабул булуы хакында күп сөйләнә.

Аллаһы Тәгалә бер көдси хәдистә шулай дигән:

«Әй колларым! Белегез ки, Мин Үземә золым-җәберне хәрам иттем. Аны сезгә дә хәрам кылдым, шулай булгач, бер-берегезгә золым итмәгез».

Аллаһы Тәгаләнең золым хакында әйтелгән фәрманыннан соң моннан да начаррак нәрсә була аламы? Бер-беребезне рәнҗетүдән, мескеннәрне кыерсытудан сакланыйк. Күркәм әхлак иясе булырга омтылыйк.

## Ун кол азат итү савабы

Әбү Һөрәйрәдән d риваять ителгәнчә, Пәйгамбәребез s болай дип әйткән: «Кем көнгә йөз мәртәбә: «Ләә иләәһә илләлааһү вәхдәһүу ләә шәриикә ләһ, ләһүл-мүлкү вә ләһүл-хәмдү вә һүә галәә күлли шәй-иң кадиир»

Ягъни: «Аллаһтан башка илаһ юк. Аның тиңдәше һәм охшашы юк. Мөлкәт – Аныкы, мактау да Аңа хастыр. Аның һәр нәрсәгә көче җитә», – дисә, бу дога аның өчен ун кол азат итү савабына тиң булыр, аңа йөз савап язылыр, йөз гөнаһы кичерелер, ул көн кичкә кадәр шайтанның явызлыгыннан имин булыр һәм һичкем аның бу догасыннан артыграк дога укый алмас», – дип әйткән.

# Намазлар

## Җәмәгать намазлары

Җәмәгать намазларын укыту мәчет имамының (имамнарының) турыдан-туры вазифасы булып тора. Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте мәчетләрендә җәмәгать намазларын сайлап куелган имамнан (сайлап куелган имамнардан) башка беркем дә уздыра алмый. Шуның белән бәйле рәвештә, имам (имамнар) намазны шәхсән үзләре уздырырга тиеш яисә алар бу эшне кандидатурасы имам-мөхтәсиб белән килештерелгән мөәзингә тапшыра.

Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте мәчетләрендә барлык намазлар да хәнәфи мәзһәбендә билгеләнгән тәртиптә укыла.

Имамга оеп укыла торган фарыз намазларга соңга калып килгәннәргә икенче тапкыр җәмәгать намазы укыту тәкъдим ителми. Әгәр дә мәчет юл кырыенда яисә транспорт юлы янында урнашкан булса – икенче җәмәгать белән намаз уку тыелмый.

## Җәмәгать намазы укыганнан соң башкарыла торган гамәлләр

«Әллааһүммә әнтәс-сәләәмү үә минкәс-сәләәмү тәбәәрактә йәә зәлҗәләәли үәл-икраам».

Мәгънәсе: «Йә Рабби, Син – һәрбер бәладән Саклаучы. Һәрбер сәламәтлек – Синнән генә. Син – мөбарәк Зат, әй олуглык һәм хөрмәт иясе Аллаһ».

Фарыз (иртәнге һәм икенде намазлары очрагында) һәм сөннәт (өйлә һәм ахшам очрагында) намазлары, шулай ук, ястү булганда – витр намазы

беткәннән соң, имам, урыныннан тормыйча гына, намаз арты зикерләрен әйтер өчен, үзе артында булган кешеләргә йөзе белән борылып утыра.

Намаз арты зикере әйтү тәртибе түбәндәгечә. Имам кычкырып әлеге доганы укый:

«Субъхәнәл-лааһи үәл-хәмдү лилләәһи үә ләә иләәһә иллә-лааһү үәл-лааһү әкбәр үә ләә хәүле үә ләә куввәтә иллә билләһил галиил газыйм мәә шәәАлләһү кәәнә үә мәә ләм яшәә ләм якүүн».

Мәгънәсе: «Аллаһы Тәгалә барлык кимчелекләрдән пакь. Барча мактаулар Аллаһы Тәгаләгә хас. Бер Аллаһы Тәгаләдән башка Илаһи зат һич юк. Аллаһы һәрнәрсәдән олуграк».

Шуннан соң имам эчтән генә «Аятел-Көрси»не укый, кычкырып бары тик «Аятел Көрси»нең башын гына укый.

Аннары утыз өчәр тапкыр «СүбехәәнәЛлааһи», «ӘлхәмдүлилЛәәһи», «Әллааһү әкбәр» зикерләрен әйтә, башта – кычкырып, ә аннары эченнән генә кабатлый. Зикерләр әйтелеп беткәч, имам, намаз укучылар белән бергәләп, учларын өскә каратып, кулларын күкрәк турысына күтәрә һәм дога кыла:

**«Әллаһүммә тәкаббәл миннә саләәтәнәә үә сийәәмәнәә үә кыйәәмәнәә үә кыйра’әәтәнәә үә рукүүгәнәә үә сүҗүүдәнә үә кугүүдәнәә үә тәсбиихәнәә үә тәхлииләнәә үә тәхашшүгәнәә үә тәдарругънәә. Әллааһүммә тәммим тәкъсыйранәә үә тәкаббәл тәмәәмәнәә үәс-тәҗиб дугаә’ әнәә үәгъфир әхйәә’әнәә үәрхәм мәүтәәнәә йәә мәүләәнәә. Әллааһүммәх-фәзнәә йә фәййәду мин җәмиигил-бәләәйә үәл-әмрадъ. Әллааһүммә тәкаббәл миннәә һәәзиһис-саләәтә (әл-фәрда мәгәс-сүннәти) мәгә җәмиги нүксаанәәтиһәә бифәдликә үә кәрамикә үә ләә тәдриб биһәәтвүҗүүһәнәә йәә иләәһәл-гәәләмиинә үә йәә хайран-нәсыриин. Тәүәффәнәә мүслимиин үә әлхикнәә бис-саалихиин. Үә саллаллааһү тәгәәлә галәә хайри халкиһии Мүхәммәдин үә галәә әәлиһии үә әсхәәбиһии әҗмәгиин».**

Мәгънәсе: «Йә Рабби, безнең намазларыбызны, уразаларыбызны, кыямыбызны, рөкугыбызны, сәҗдәбезне, кагъдәбезне, тәсбихебезне, тәһлилебезне, тыйнаклыгыбызны һәм ялваруларыбызны кабул кыл. Йә Рабби, кимчелекләр белән кылынган гамәлләребезне камилләштер, тәмам булган гамәлләребезне, догабызны кабул кыл. Әй Хуҗабыз, тере булучыларны ярлыка һәм үлгәннәргә рәхмәтеңне ирештер. Әй рәхмәт кылучы Аллаһы, Үз камиллегең һәм юмартлыгың белән бездән ошбу намазыбызны һәрбер кимчелекләре белән кабул кыл. Ул намазларыбызны йөзләребезгә ыргытма. Әй бөтен галәмнәрнең Раббысы һәм ярдәм итүчеләрнең иң камилрәге, безне мөселман хәлебездә вафат кыл һәм изге кешеләр белән бергә ит. Мәхлукларның иң яхшырагы Мөхәммәд галәйһиссәламгә, аның әһеленә (гаиләсенә), барлык сәхабәләренә рәхмәтеңне бирсәң иде».

Имам дога кылып бетергәннән соң, куллары белән битләрен сыпыра. Аннан соң Коръән укып дога кылырга киңәш ителә. Иртәнге һәм ахшам намазларыннан соң өч мәртәбә «Ихлас» белән «Фәләкъ», «Нәс» сүрәләрен уку да хәерле.

Намаздан соңгы зикерләрне бары тик биш вакыт намазларның фарызлары һәм сөннәтләре, шулай ук җомга намазының сөннәте укылганнан соң гына әйтү тиеш. Намаздан соңгы зикер әйтүне әзерлеге булган мөәзин дә уздыра ала.

Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте мәчетләрендә таралган гореф-гадәт буенча, намаздан соңгы зикер әйтелгәннән соң мәхәллә кешеләре, кулларын бирешеп, бер-берсен сәламли, шуннан соң кыска гына дога укыла.

# Җомга намазы

## Вәгазьнең структурасы

Җомга вәгазе ике өлештән – хөтбә һәм вәгазьдән тора.

Вәгазь шулай ук ике өлешкә – нәсыйхәт һәм рәсми өлешкә бүленә.

## Хөтбә

Аллаһыга мактаулар (зикерләр) булган хөтбә тирән эчтәлекле җомга намазы шарты булып тора.

Хөтбә шулай ук ике өлештән тора. Беренче өлештә Аллаһы Тәгаләгә зикер әйтелә, Пәйгамбәребезгә S, аның гаиләсе әһелләренә, гадел хәлифләргә һәм көрәштәшләренә изге теләкләр, тәшәһһүд, диндәшләргә үгет-нәсыйхәт әйтелә, Коръән-Кәримнән өзекләр китерелә. Икенче өлештә, тәкъвалыкның башка рәвешләреннән тыш, имам дингә ышанучылар өчен дога кыла. Хөтбәнең ике өлеше бер-берсеннән имамның бераз утырып торуы белән бүленә.

Хөтбә җомга намазы кергән вакыттан (Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәтендә кабул ителгән намаз вакытлары нигезендә) намаз башланганчыга кадәр укыла.

Тәкъдим ителә торган хөтбә тексты үрнәкләре Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәтенең голәмәләр шурасы тарафыннан билгеләнә һәм Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте мөфтие тарафыннан раслана.

Хөтбә гарәп телендә укыла.

Хөтбә вакыты өч минуттан да артык булырга тиеш түгел.

## Вәгазь

Вәгазь җомга намазы кергәнче (Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәтендә кабул ителгән намаз вакытлары нигезендә) укыла.

Вәгазь хөтбәгә өстәмә булырга, ягъни җомга намазы җиткәч тә укылырга мөмкин.

Вәгазьнең нәсыйхәт өлешендә имам-хатыйб тыңлаучыларга мөселман диненең төп нигезләмәләрен һәм рухый-әхлакый үгетләрне җиткерә. Монда ул Коръәнгә һәм Сөннәткә таяна, пәйгамбәрләр, Мөхәммәд пәйгамбәр S, аларның көрәштәшләре, исламның игелекле ир-атлары тормышыннан мисаллар китерә һәм мәхәлләнең игътибарын дин тотучының рухый тормышын тәшкил итүче барча нәрсәгә юнәлтә.

Вәгазьнең рәсми өлешендә имам мөселманнарга Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәтенең рәсми хәбәрләрен (Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте корылтае, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте пленумы, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте президиумы, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте мөфтие, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте баш казые, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Казыйлар шурасы, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең голәмәләр шурасы карарларын), шулай ук оештыру мәсьәләләренә кагылышлы төбәк (шул исәптән, Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәтенең төбәк казыятләре карарлары) һәм җирле (шул исәптән, мәхәллә җыелышы һәм мәхәллә советы карарлары) әһәмияттәге башка кирәкле мәгълүматны җиткерә.

Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте мәхәлләләренә йөрүчеләргә җиткереләчәк рәсми мәгълүматның эчтәлеген Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте мөфтие бил-

гели. Татарстан Республикасы мөселманнарының Дания нәзарәте рәсми мәгълүматын мөселманнарга җиткерүне районның имам-мөхтәсибе тикшереп тора.

Вәгазьнең нәсыйхәт өлеше Коръән-Кәримгә һәм Пәйгамбәребез s сөннәтенә ияргән, имам Әбү Хәнифә дини-хокукый юнәлеше нигезендә факыйһ һәм голәмәләр иҗтиһадында чагылыш тапкан Коръән, Сөннәт һәм шәригать нормаларындагы хакыйкать нигезендә бәян ителә.

Исламның дини абруйлары сыйфатында таянырга ярамаган затлар, шулай ук үрнәкләре һәм мираслары вәгазьләрдә искә алынырга тәкъдим ителгән затлар исемлеге Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте голәмәләр шурасы тарафыннан билгеләнә һәм мөфти хәзрәтләре тарафыннан раслана.

Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте имамхатыйблары вәгазе татар телендә алып барыла. Бик сирәк очракларда, максатка ярашлылык принцибыннан чыгып, җомга намазы вәгазьләрен рус һәм башка телләрдә өстәмәләр белән уку рөхсәт ителә. Вәгазьләрне рус һәм башка телләрдә өстәмәләр белән уку өчен Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте мөфтиенең махсус рөхсәте кирәк.

Вәгазьнең дәвамлылыгы, әгәр ул намаз вакытына кадәр укылса – кырык минуттан артмаска, ә намаз вакыты кергәннән соң укылса – егерме минуттан озаграк булмаска тиеш.

## Җомга намазын үткәрү тәртибе

### I вариант

Җомга намазы җиткәнче, имам дин тотучыларга вәгазь белән мөрәҗәгать итә.

Мөәзин җомга намазына чакыра торган беренче азанны әйтә.

Имам һәм мәхәллә дүрт рәкәгать сөннәтне укый.

Мөәзин тагын җомга намазына чакыра торган икенче азанны әйтә.

Имам мөнбәргә күтәрелә.

Имам хөтбәнең беренче өлешен сөйли.

Имам мөнбәр баскычына утыра (ике вәгазь арасында утырып тору).

Имам хөтбәнең икенче өлешен укый.

Имам җомга намазының фарыз өлешен башкару өчен мөнбәрдән төшә.

Мөәзин җомга намазының фарыз өлешен башкаруга чакыра торган камәт әйтә.

Имам җитәкчелегендә мәхәллә мөселманнары җомга намазының фарыз өлешен укый.

**II вариант**

Мөәзин җомга намазына чакыра торган беренче азанны әйтә.

Имам һәм мәхәллә халкы дүрт рәкәгать сөннәтне укый.

Имам дин әһелләрен сәламли һәм мөнбәргә менә.

Мөәзин тагын бер кат җомга намазына чакыра торган икенче азанны әйтә.

Имам хөтбәнең беренче өлешен укый һәм дин тотучыларга вәгазь сөйли.

Имам мөнбәр баскычына утыра (ике вәгазь арасында утырып тору).

Имам хөтбәнең икенче өлешен укый.

Имам җомга намазының фарыз өлешен башкару өчен мөнбәрдән төшә.

Мөәзин җомга намазының фарыз өлешен башкаруга чакыра торган камәт әйтә.

Имам җитәкчелегендә мәхәллә мөселманнары җомга намазының фарыз өлешен укый.

Җомга намазын кайсы вариант буенча үтәү имам-хатыйб һәм мәхәллә белән килештерелә.

# Бәйрәм намазы

## Вәгазь

Вәгазь ике өлештән – нәсыйхәт һәм рәсми өлешләрдән тора.

Вәгазь бәйрәм намазы укылганчы сөйләнә.

Вәгазьнең нәсыйхәт өлешендә имам-хатыйб тыңлаучыларны мөселман диненең бәйрәм намазы укыла торган бәйрәм белән бәйле төп нигезләмәләре белән таныштыра.

Вәгазьнең рәсми өлешендә имам мөселманнарга Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәтенең рәсми хәбәрләрен (Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте корылтае, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте пленумы, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте президиумы, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте мөфтие, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте баш казые, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Казыйлар шурасы, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең голәмәләр шурасы карарларын), шулай ук оештыру мәсьәләләренә кагылышлы төбәк (шул исәптән, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең төбәк казыятләре, район мөхтәсибәте карарлары) һәм җирле (шул исәптән, мәхәллә җыелышы һәм мәхәллә советы карарлары) әһәмияттәге башка кирәкле мәгълүматны җиткерә. Рәсми мәгълүмат вәгазь ахырында җиткерелә.

Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте мәхәлләренә җиткерелергә тиешле рәсми мәгълүматның эчтәлеген Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте мөфтие билгели. Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәсми мәгълүматын мөселманнарга җиткерүне районның имам-мөхтәсибе тикшереп тора.

Вәгазьнең нәсыйхәт өлеше Коръән-Кәримгә һәм Пәйгамбәребез S сөннәтенә ияргән, имам Әбү Хәнифә дини-хокукый юнәлеше һәм Әбү Мансур әл-Матуриди тәгълиматлары нигезендә факыйһ һәм голәмәләр иҗтиһадында чагылыш тапкан Коръән, Сөннәт һәм шәригать нормаларындагы хакыйкать нигезендә бәян ителә.

Исламның дини абруйлары сыйфатында таянырга ярамаган затлар исемлеге Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте голәмәләр шурасы тарафыннан билгеләнә һәм мөфти хәзрәтләре тарафыннан раслана.

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте имам-хатыйблары вәгазе татар телендә алып барыла. Бик сирәк очракларда, максатка ярашлылык принцибыннан чыгып, бәйрәм вәгазьләрен рус телендә өстәмәләр белән уку рөхсәт ителә. Вәгазьләрне рус телендә өстәмәләр белән уку өчен Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте мөфтиенең махсус рөхсәте кирәк.

Бәйрәм вәгазенең дәвамлылыгы егерме минуттан да ким булмаска һәм утыз минуттан да артмаска тиеш.

## Хөтбә

Аллаһка мактаулар (зикерләр) булган хөтбә тирән эчтәлекле бәйрәм намазының шарты булып тора.

Хөтбә шулай ук ике өлештән тора. Беренче өлештә Аллаһы Тәгаләгә зикер әйтелә, Пәйгамбәребезгә S, аның гаилә әһелләренә, гадел хәлифләргә һәм көрәштәшләренә изге теләкләр, тәшәһһүд, диндәшләргә үгет-нәсыйхәт әйтелә, Коръән-Кәримнән өзекләр китерелә. Икенче өлештә, тәкъвалыкның башка рәвешләреннән тыш, имам дингә ышанучылар өчен дога кыла. Хөтбәнең ике өлеше бер-берсеннән имамның бераз утырып торуы белән бүленә.

Хөтбә бәйрәм намазы укылганнан соң сөйләнә. Хөтбә тәмамлангач, имам мөселман халкын бәйрәм белән котлый, аннары кардәшләр бер-берсенә кул бирешә һәм бер-берсен тәбрикли.

Тәкъдим ителә торган кануни хөтбә тексты үрнәкләре Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең галәмәләр шурасы тарафыннан билгеләнә һәм Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте мөфтие тарафыннан раслана.

Кануни хөтбә гарәп телендә укыла.

## Бәйрәм намазын үткәрү тәртибе

Имам мөнбәргә менә һәм вәгазь сөйли.

Бәйрәм намазы вакыты кергәннән соң, имам намаз вакыты җитүен әйтә һәм мөнбәрдән төшеп, намаз укучыларга рәтләргә тезелергә куша. Имамга шуны истә тотарга кирәк: бәйрәм намазында өстәмә тәкбирләр әйтү мәҗбүри (вәҗиб) гамәл булып тора. Беренче рәкәгатьтә – истигаза укыр алдыннан – өч тәкбир һәм икенче рәкәгатьтә рөкугъ алдыннан өч тәкбир әйтелергә тиеш. Шулай ук әлеге тәкбирләрнең кирәклеге турында намаз укучыларның исләренә төшерү дә лазем. Ахырдан намаз укыла.

Намаз вакытында имам Коръән аятьләрен кычкырып укырга, «Фатихә» сүрәсеннән соң «әмин» сүзен эчтән генә әйтергә тиеш.

*«Гыйбадәт кылулар һәм дини йолалар*
*уздыру турында нигезләмә»дән*

# «Мәүлид Ән-Нәби»

## «Мәүлид Ән-Нәби бәйрәме» хакында бер-ике сүз

Элеккеге заманнарда пәйгамбәребез Мөхәммәд Расүлүллаһи s хәзрәтләренең туган көнен аерым-ачык билгеләп бәйрәм итү һәм шул көндә фәкыйрь-мескеннәрне ашлар ашатып, аларны сәдакалар биреп шатландыру, Расүлүллаһи s тууы, үсүе хакында гарәп яки төрки телләрдә бәян ителгән касыйдәләрнең укылганы төгәл билгеле түгел.

Әмма һиҗри исәп белән алтынчы гасырда Ирбиль падишаһы Мәлик Мозаффар Әбү Сәгыйт Күкбүре бине Гали бине Биктәкин, Мөхәммәд Расүлүллаһины s ихлас күңеленнән яратканга һәм үзе дә бик юмарт кеше булганга күрә, шушы «Мәүлид-шәриф» касыйдәсен укуны һәм зур табыннар-ашлар әзерләп, халыкны җыеп ашатуны, шунда күп изгелек кылып, сәдакалар таратып, кешеләргә ярдәм итүләрне гадәткә кертә. Ул һәр ел саен «Мәүлид-шәриф» көнендә галимнәрне, мәшәехләрне һәм дә күп санлы фәкыйрьләрне җыеп зур аш мәҗлесе ясый.

«Мәүлид-шәриф» касыйдәләрен укучыларга һәм голәмә, мәшәехләргә яхшы, матур киемнәр бүләк итеп, якынча өч йөз мең алтын микъдарында мал сарыф итә. Расүлүллаһины s бик тә яратканга күрә, күңеле тулып, аның өммәтен, бихисап фәкыйрьләрне һәм гыйлем әһелләрен, бу «Мәүлид-шәриф» бәйрәме сылтавы белән, шулкадәр күп маллар сарыф итеп, шатландыра торган була.

Хафиз ибне Раҗәп «Ләтаифүл-мәгариф» исемле китабында дүшәмбе көн ураза тотуның мөстәхәб булуы хакында хәдис шәриф бәян итеп, «Мәүлид шәриф бәйрәме»нә һәм анда, ачык рәвештә халыкка белдереп, шөкераналар кылырга кирәклегенә дәлилләр булганлыгын күрсәтә.

Хәдисләр җыентыгы «Мөслим»дә, Әбү Котада d риваять итүенчә, Расүлүллаһи s , аның дүшәмбе көн ни өчен ураза тотуы турында сора-

гач: «Зәликә йәүмүн вулидтү вә унзиләт галәйә фиһи ән-нүбүвәтә!» – дип әйткән. Тәрҗемәсе: «Бу көн мин туган һәм миңа пәйгамбәрлек иңдерелгән көн!»

Димәк, бу Расүлүллаһи s үзенең туган көнен һәм пәйгамбәрлек килгән көнен аерым гыйбадәт белән хөрмәт итүе, шушы олы нигъмәт өчен (кешеләргә сөекле Пәйгамбәрен җибәргәне өчен), мөселманнарның Аллаһы Тәгаләгә шөкерана кылырга тиешлеген күрсәтә.

Шуңа күрә, ай хисабы буенча да аның туган көнен, шәригать кысаларыннан чыкмыйча, нинди рәвештә булса да хөрмәт итү нигезсез түгел, ә, киресенчә, дөрес икәнлеге исбатлана.

Телгә алынган Хафиз ибне Рәҗәпнең «Ләтаифүл-мәгариф»ендә, «Мөслим»дә Әбү Котада d риваяте буенча, китерелгән хәдисләргә таянып исбат ителгәннән соң, шулай ук мөхәддис, факыйһ галимнәрне дә искә алып үтмичә булмас. Сүюти, Гаскаләни вә Касталәни хәзрәтләренең дә, бу мәсьәләдә хәдис шәрифләр китереп, Пәйгамбәребез s туган көнне ихтирам итүне рөхсәтле һәм күркәм эш икәнлегенә фәтва биргәннәрен дә күрә алабыз. Боларны төгәл итеп белергә теләгән кешеләр шәех Йосыф бине Исмәгыйль Нәбаһәнинең «Хуҗҗәтуллаһи галәл галәмин фи мугъҗизәт сәйидил мурсәлин» китабына мөрәҗәгать итә алалар!

*Бу мәкалә дамеллә Галимҗан хәзрәт Әл-Барудиның*
*«Әд-дин вәл-әдәп» мәҗәлләсеннән (журналыннан)*
*нәкыль ителде (күчереп алынды)*

# Төрки «Мәүлид Ән-Нәби касыйдәсе»

## Бисмилләһир Рахмәнир Рахим!

Әүвәлән бер хикәять әйтәем,
Әһле әхбәрдән риваять итәем (борынгылар сөйләгәнне китерәм).
Бар иде Багдадта бер салихә, (изге хатын)
Габидә хатын иде һәм насихә (гыйбадәтле, нәсихәт кылучы).
Беркөн ул дөньядан әйләде сәфәр,
Дөньяга килгән кеше, шиксез, китәр.
Анасыннан бераз акча мирасы бар,
Җәннәт аңа ни өчен булмасын карар?!
Бар иде бер изге угълы – яшь егет,
Итәгатьле йөрер иде һәрвакыт.
Шул акчасы калды мирас угълына,
Ул дияр: «Ни алыйм соң мин моңа?»
Уйлый-уйлый йөрегәндә бу егет,
Күп кешегә очрады шул вакыт.
Мәүлид укыйлар җыелышып бер өйдә,
Бу егет тыңлады һәм ихлас илә.
Ишетүгә гашыйкъ булды ул егет,
Күзләреннән яшь акты чишмә кебек.
Ул егет күрде төшендә шул төнне,
Гүя җиткән икән Кыямәтнең көне.
Чакыралар фәрештәләр шул заман.
«Кил! Кайда син? Җәннәткә кер, әй фәлән!
Мәүлидкә хәстәрләнгәннәр дә дахи, (тагын)
Җәннәткә керсен алар да һәммәси!»
Күрде шунда бу егет бер зур сарай,
«Кертсәгезче мине монда!» – дип сорай.

Диделәр: «Монда керә шундый кеше –
Хөрмәт итсә нәбинең туган көнен,
Синең хөрмәт иткәнең юк ул көнне!» –
Дип читкә этәрделәр ул мескенне.
Йокысыннан уянып күп елады,
Күңелен һәм ихлас уты чолгады.
Иртәгесен ул акчага җыйды аш,
Мәүлид укытты түгепләр канлы яшь.
Ул егет Мәүлид укытты ел саен,
Шатланып көтәр иде Мәүлид аен.
Көлә-көлә ахыйрәткә күчте ул,
Чөнки әҗәлнең мәңгелек суын эчте ул.
«Үлмәгәндер!» – диделәр кауме аның,
«Чөнки Газраил җиңел алды җанын!»
Бер табип китерделәр тизлек белән,
«Җаны чыкмыш – диде ул – рәхмәт белән!»
Кауме диде: «Үлмәгәндер, үлмәгән!»
Чөнки җан чыкканын һич кем белмәгән.
Баксалар ул егетне, ифрат матур,
Нуры балкый, гүя җәннәт эчендә хур.
Диде: «Белегез, үлемендә шөбһә юк,
Аллаһ, Хак бакъмыш аңа, рахмәте чук!»(киң рәхмәтле)
Шул минутта күзен ачты ул үзе,
Диде: «Каумем тыңлагызчы бу сүзне!
Хак миңа бер нурны ачык күрсәтте,
Җаныңны рәхәттә тот һәрчак диде.
Җәннәт эчендә урынымны әзер күрдем,
Мостафа белән шунда бергә идем.
Чөнки кылдым Мәүлидинең хөрмәтен,

Хак Тәгалә кылды шуңа рахмәтен.
Көлгәнем будыр минем, белегез, – диде –
Хөрмәт итегез туган көнен!» – диде.
Шулай диде, күзләрен йомды янә,
Кауме калды шатланып – көлгәненә.
Ул Хәбибең хөрмәте өчен, ий гани,
Шәфәгатен насыйп кыл син, ий вәли!
Ий Мөхәммәд Мостафа син, ий Расүл,
Кыл шәфәгать безләргә яүмүн нүзүл.

Гәр теләр булсагыз сез уттан нәҗат, (уттан котылырга)
Гыйшкъ илә, дәрт илә әйтегез салават.

*Саллүү галәйһи вә сәллиму тәслимә*
*Хәтта тәналү җәннәтән вә нәгыймә.*
*Аллаһүммә салли вә сәллим вә бәрик галәйһ*

## Истанбуллы кятип мәкаменә

Ий Ходайдан лотфы ихсан теләгән, кил Мәүлидкә,
Җәннәт эчендә хур-гыйлманнар теләгән, кил Мәүлидкә.
Ул Расүлнең туган көне нәкъ кадер киче иде,
Һәм шулай ук тулган айдай, нурланып балкыр иде.
Җан-күңелдән, чын йөрәктән тыңларга Мәүлидкә кил,
Дөньяда, исән чагыңда тыңларга Мәүлидкә кил.
Заты-пакь, сыйфаты-нур, Хактыр ул зати хәсән,
Мәҗлестәш, дуслар кирәксә, тыңларга Мәүлидкә кил.
Укылырса Мәүлидтә махсус касыйдә һәрзаман,
Бел шуны, Расүлнең рухы шатланып торыр һаман.
Әгәр шул мәҗлескә чакырсалар дәгъват белән,

Бер минут торма, тиз йөгер, калма яукаулык белән!
Күпме шөгылең булса да ташла, кил син мәҗлескә,
Катнаш шунда, сора шәфәгать, өметеңә ирешү кичә.
Җәннәт әгъләне теләсәң, Мәүлид мәҗлесенә кил,
Кәүсәр чишмәсеннән эчәргә теләсәң, Мәүлидкә кил!
Сыйрат күперен тиз кичәргә теләсәң, Мәүлидкә кил.
Йи Кәрим,Син насыйп ит җәннәтне һәммәбезгә,
Дидар йөзеңне насыйп ит күрергә һәммәбезгә.

* * *

*Бисмилләһир Рахмәнир Рахим*

Әссаләтү вәс сәламу галәйкә йә Расүлуллаһ!
Әссаләтү вәс сәламу галәйкә йә Хәбибуллаһ!
Әссаләтү вәс сәламу галәйкә йә Нәбийүллаһ!
Әссаләтү вәс сәламу галәйкә йә хайри халкыйлләһ!
Әссаләтү вәс сәламу галәйкә йә нура гаршилләһ!
Әссаләтү вәс сәламу галәйкә йә сахибә каб каусәйн!
Әссаләтү вәс сәламу галә әшрафил мурсәлин!
Вә галә әлиһи вә әсхабиһи әҗмәгыйн,
Вәлхәмдүлилләһи Раббил галәмин.
Бирахмәтикә йә Әрхәмәр Рахимин!

* * *

*Бисмилләһир Рахмәнир Рахим*

Әүвәл Аллаһ исмен зикер итәем,
Соңра башлап, һәр эшкә керешәем!
Эш башында кем аны зикер итәр,

Ул эшен Аллаһ аңа ансат итәр.
Аллаһ исмен зикер итеп эш башламак,
Һәркемгә важип, тиештер аңламак.
Булса Аллаһ исме берлә һәр эшең,
Бушка китмәс эшләгән һәрбер эшең!
Шаукъ илә «Аллаһ» дисә кемнең теле,
Барлык гөнаһы түгелер яфрак кебек!
Пакь булыр Аллаһ исмен зикер иткән,
Ирешер максатына «Аллаһ» дигән!
Килегез, чын күңелдән «Аллаһ!» диик,
Күзләрдән яшьләр түгеп без аһ итик.
Шулай итсәк, буш куймас Аллаһ безне,
Рахмәте киң, ярлыкар һәммәбезне.
Бердер Аллаһ, берлегенә шөбһә юк,
Сөйләгәннәр ялгышып – дөнья тулук.
Барча галәм юк икән, Ул бар иде,
Һәм әзәлдән бай иде, Җәббар иде.
Җен-фәрештә һәм адәм – берсе дә юк,
Һәм янә тугыз фәләк – һичберсе юк!
Гарше-көрси, ай-кояш һәм юк иде,
Барча җаннан әүвәл ук Ул бар иде.
Кодрәт белән боларны бар әйләде,
Берлегене барча икърар әйләде.
Бу хосуста күп сүзгә хаҗәт тә юк,
Аллаһ бардыр, бердер Ул, башкасы юк!
Әгәр шәфәгать кирәк исә эзләгез,
Ул Расүлнең сөннәтеннән бизмәгез.
Ий Мөхәммәд Мостафа син, ий Расүл,
Кыл шәфәгать безләргә яүмүн-нүзүл.

Әй газизләр, инде килде сүз башы,
Тыңлагыз сез агызыплар күз яше.
Бер васыять сөйләмәкче буламын,
Ул васыять ошбудыр, тот колагың.
Һәркем аны тыңласа, тотар исә,
Ул кешедән һәрзаман хушбуй исә.
Кылар Аллаһ шул кешегә рахмәтен,
Мәүлид ән-нәбинең кылса хөрмәтен.
Тыңлаганнар һәм табар фазыйләтен,
Укыса шамаилен, нәсабәтен!
Рухыны шат итәек саләт илә,
Әһле бәйте, барча әсхабләренә.
Ул туган көннәрене хөрмәт иткән,
Тыңлар шул кыйссасыны ихлас белән.
Ий Мөхәммәд Мостафа син, ий Расүл,
Кыл шәфәгать безләргә яүмүн-нүзүл.

Гәр теләр булсагыз сез уттан нәҗат, (уттан котылырга)
Гыйшкъ илә, дәрт илә әйтегез салават.

*Аллаһүммә салли вә сәллим вә бәрик галәйһ*

Хак Тәгалә чөн яратты Адәмне,
Һәм Адәм белән зиннәтләде Ул галәмне.
Сәҗдә кылды күп фәрештә Адәмгә,
Әмма Иблис кылмады аңа сәҗдә.
Диде Аллаһ: «Ни өчен бу инкярың?
Юкса бармы монда бер-бер әфкярың?»
Диде: «Балчыктан аны яраттың Син,

Ни өчөн аңа сәҗдә кылыйм соң мин?»
«Мине уттан яраттың бит Син!» – диде,
«Утмы өстен яки балчыкмы?» – диде.
Куйды Адәм алдына Ул бер нурны,
«Бел, Хәбибем нурыдыр бу нур!» – диде.
Диде Ул нурга: «Аның алдында тор!»
Калды шунда ничә еллар ошбу нур.
Соңра Һәва анабызга күчте, бел,
Торды анда ничә айлар, ничә ел.
Шис тугач та күчте аңа ошбу нур,
Аның алдында тәҗәлли кылды зур.
Соңынтын Ибраһимга, Исмәгыйлгә һәм
Озын сүзнең кыскасы, шулдыр кәлям.
Шул рәвешчә күчә-күчә килде ул,
Фәхре галәм Мостафага төште ул.
Галәмнәргә рахмәт дип килде бу нур,
Килде, торды ул нәбидә ошбу нур.
Әгәр шәфәгать кирәк исә эзләгез,
Ул Расүлнең сөннәтеннән бизмәгез.
Ий Мөхәммәд Мостафа син, ий Расүл,
Кыл шәфәгать безләргә яүмүн-нүзүл.

Гәр теләр булсагыз сез уттан нәҗат, (уттан котылырга)
Гыйшкъ илә, дәрт илә әйтегез салават.

*Аллаһүммә салли вә сәллим вә бәрик галәйһ*
Әминә хатын – Мөхәммәд анасы,
Ул сәдәфтән туды энҗе данәсе.
Ул – Мөхәммәд, дөньяга хөрмәт итәр,

Вакыт җитте килмәккә хәйрел-бәшәр
(кешелекнең иң хәерлесе).
Инде аның килүе булды анык,
Күп галәмәт пәйда булды алдан ук.
Ул рабигыль-әүвәл аенда иде,
Уникенче киче, дүшәмбе иде.
«Күрдем» – диде, ул Мөхәммәд анасы,
«Бер гаҗәп нур, нәкъ кояшның яктысы!
Ялт итеп чыкты өемнән шул заман,
Күкләргә тик нур белән тулды җиһан.
Һәмдә һавада түшәлде бер түшәк,
Аты сөндүс, түшәгән аны мәләк.
Өч әләм тагын куйдылар өч җиргә,
Аралары бик ерак бер-беренә.
Бере мәшрикъ, бере мәгърибтә аның,
Бересе нәкъ уртасында Кәгъбәнең.
Белдем аннан ул мөбәрәкнең нурын,
Заһир булды килмәсеннән әүвәлен.
Инде күктән күп фәрештә сафи саф,
Кәгъбә кебек кылдылар өем тәваф.
Кинәттән өч хур кызы пәйдә булды,
Кайдан кергәннәрен аңлап булмады.
Өчесе дә яныма утырдылар,
«Мостафа килә!» – диеп гәп кордылар.
Диделәр: «Углың кебек хөрмәтлене
Ул Ходай һичбер анага бирмәде!
Бик олугъ дәүләт иясе буласың,
Холкы күркәм бер угыл тудырасың!

Бу угыл гыйлме ләдүн солтаныдыр,
(Аллаһыдан бирелгән гыйлем иясе)
Бу угыл тәүхиде гыйрфан кянидер!»
Сыйфатын шул рәвешчә аңлаттылар,
Ул мөбәрәк нур белән шатландырдылар!
Диде Әминә: «Вакыт җитте тәмам,
Килә инде дөньяга хәйрел-әнәм (кешеләрнең иң хәерлесе).
Эсселектән сусадым гаять катый,
Шул вакыт эчерделәр бер ширбәти.
Ап-ак иде, кардан да салкын иде,
Бу кеби тәм дөньяда һич юк иде.
Эчтем аны, барча эгъзам булды нур,
Эчемә һәм тышыма да тулды нур.
Килде бер аккош канат илә очып,
Аркамнан ул сыйпады, яныма төшеп.
Тугъды шул сәгатьтә ул солтани дин,
Нурга тулды барлык сәмәвәт-зәмин (күкләр-җир).
Әгәр шәфәгать кирәк исә эзләгез,
Ул Расүлнең сөннәтеннән бизмәгез.
Ий Мөхәммәд Мостафа син, ий Расүл,
Кыл шәфәгать безләргә яүмүн-нүзүл.

Гәр теләр булсагыз сез уттан нәҗат, (уттан котылырга)
Гыйшкъ илә, дәрт илә әйтегез салават.

*Әссаләтү вәссәламу галәйкә йә Расүлүллаһ. Әссаләтү вәссәламу галәйкә йә Хәбибәллаһ. Әссаләтү вәссәламу галәйкә йә Сәйидәл-әүвәлинә вәл ахирин.*

## Мәхәле кыям (аягүрә басып)

Расүлүллаһи S хәзрәтләренең тууы зикер ителгән вакытта аягүрә торып, салават шәриф уку галимнәр күзлегеннән бик күркәм эш итеп кабул ителгәнгә күрә, гарәп голәмәләре, бигрәк тә Хәрамәйни-шәрифәйни (Мәккә һәм Мәдинә шәһәрләрендәге Хәрам мәчетләре) голәмәләре бу урында аягүрә басып, салават шәрифне укырлар. Түбәндәге бәетләрне аягүрә торып басып уку тиешле була. Чөнки бөек галимнәрнең сүзләре буенча, Расүлүллаһ S әфәндебезнең туу вакыты искә алынып сөйләнелсә, шул зикер ителгән мәҗлескә аның мөбәрәк рух шәрифләре пәйда була диеләә!

Яратылмыш барча мәхлүк булды шат,
Кайгылар китте галәмнән, калды саф.
Бар тереклек галәмнәргә кылып сәда, (аваз салып)
Барсы берләшеп диделәр: «Мәрхабә!»
Мәрхәбә, ий гали солтан, мәрхәбә! (бөек солтан)
Мәрхәбә, ий кяни солтан, мәрхәбә! (инанганнарның солтаны)
Мәрхәбә, ий куррәтел-гәйнел-хәлил! (күз шатлыгы булган дус)
Мәрхәбә, ий хасси мәхбүби Җәлил! (Аллаһының сөеклесе)
Мәрхәбә, ий җөмләнең матлубы син! (барчасының теләге)
Мәрхәбә, ий Халикъның мәхбүбе син! (Аллаһының сөеклесе)
Мәрхәбә, ий җан-җанани, мәрхәбә!
Мәрхәбә, ий дәрткә дәрман, мәрхәбә! (хастага шифа)
Мәрхәбә, ий гасый өммәт мәлҗаи! (гөнаһлыларны сыендыручы)
Мәрхәбә, ий чарасызлар әшфагый! (чарасызларның яклаучысы)
Мәрхәбә, ий рахмәтүл лил галәмин! (галәмнәрнең рәхмәте)
Мәрхәбә син, ий шәфигуль музнибин! (гөнаһлыларның шәфәгатьчесе)
Ий җәмали көн, йөзе бәдре мөнир! (тулган ай йөзле, көн кебек матур булган)

Ий каму төшкәннәргә син дәстәгир! (авырлыкка төшкән һәммәсенә ярдәмче)
Ий күңелләр дәртенең дәрманы син! (күңел хасталарының дәвасы)
Ий яратылмышларның солтаны син! (дөнья мәхлүкләренең солтаны)
Ий Мөхәммәд Мостафа син, ий Расүл,
Кыл шәфәгать безләргә яүмүн-нүзүл.

Гәр теләр булсагыз сез уттан нәҗат, (уттан котылырга)
Гыйшкъ илә, дәрт илә әйтегез салават.
*Аллаһүммә салли галә сәйидинә Мүхәммәдинин-нәбий-йль-уммийи вә галә әлиһи вә саһбиһи вә сәллим.*

Бу газәмәттән Әминә хубыри,
Аклын җыеп аңына килде кире.
Күрде, китмеш һәммә хурлар, кемдә юк,
Угълы да юк, күрмәде, эзләде күп.
«Алдылар әллә микән хур кызлари?»
Уйлый-уйлый, эченнән кылды зари.
Як ягына борылып карар иде –
Күрде бер почмакта хәйрел-бәшәри.
Шулай Кәгъбәтуллага каршы Расүл,
Сәҗдә кылган хәлдә күрде аны ул.
Сәҗдәдә башы-теле тәхмид әйтер.
Һәм күтәрмеш бармагын тәүхид итәр.
Тибрәнер авызлары сөйләр кәлям,
Аңламадым, ни дияр хәйрүл-әнам.
Авызына куйдым колагым, тыңладым,
Сөйләгән сүзләрене һәм аңладым.
Дияр ки: «Ий Мәүләм, йөзем тоттым сиңа,

Йә Иляһи, өммәтем биргел миңа?!»
Хакка баглап күңеленнән һиммәтен, (тырышлык-омтылышын)
Дияр иде: «Өммәтем, вә өммәтем!»
Бала чактан ук теләде ул өммәтен,
Картлыгыңда син оныттың сөннәтен.
«Өммәтем!» – диде сиңа ул Мостафа,
Әйт салават, син дә аңа бул сафа (чиста).
Ий Мөхәммәд Мостафа син, ий Расүл,
Кыл шәфәгать безләргә яүмүн-нүзүл.

Гәр теләр булсагыз сез уттан нәҗат, (уттан котылырга)
Гыйшкъ илә, дәрт илә әйтегез салават.

*Аллаһүммә салли галә сәйидинә Мүхәммәдинин-нәбий-йль-уммийи вә галә әлиһи вә саһбиһи вә сәллим.*

Мәккә халкының олугълары рәвах,
Кылдылар Кәгъбәне бер кич тәваф.
Күрделәр Кәгъбәне, сәҗдә кылды ул,
Төшмәде бер ташы, кире торды шул.
Кәгъбәнең почмаклары бирде сәлам,
Диделәр: «Кем, тугъды ул хәйрел-әнам!»
Кәгъбәтулладан ишетелде сәда, (аваз)
Диде: «Тугъды бу кичә нур әл һуда!» (һидаять нуры)
Яланаяк, башы ачык, сафи саф,
Итәчәк өммәтләре мине тәваф.
Чистартып поттан, кәфердән ул Расүл,
Коткарачак мине мөшрикләрдән ул!»
Фәхре галәм җитте кырык яшенә,

Пәйгамбәрлек таҗын киде башына.
Иңде Коръән Аллаһтан аять-аять,
Пәйда булды ничә төрле могъҗизәт.
Әүвәле ул кем, мөбарәк тәненең,
Күләгәсе төшмәде җиргә анының.
Чөнки анының нур иде бар гәүдәсе,
Нурның булмас һичкайчан күләгәсе.
Анының мөбәрәк баш өстендә һәрзаман,
Күләгәләп бер болыт йөрде һаман.
Мөхәммәд туган көненең кичәси,
Тулды нур белән бөтен дөнья дәхи (тагын).
Шәүләсе итте анының Шамда зуһур, (Шамда күренде)
Әһле Мәккә күрделәр, кем, юк кусур (юк кимчелек).
Сүнде фарси магъбүденең утлары,
Чыкты ташып Бохәйраның сулары.
Күп гаҗәеп могъҗизалар күрделәр,
Тугъдыгы көн икәнлеген белделәр.
Фәхре галәм тууынча барча җан,
«Бик зур шатлык безгә, – диделәр – һаман!»
Ий Мөхәммәд Мостафа син, ий Расүл,
Кыл шәфәгать безләргә яүмүн-нүзүл!

Гәр теләр булсагыз сез уттан нәҗат, (уттан котылырга)
Гыйшкъ илә, дәрт илә әйтегез салават.

*Аллаһүммә салли галә сәйидинә Мүхәммәдинин-нәбий-йль-уммийи вә галә әлиһи вә саһбиһи вә сәллим.*

*Сөләйман Чәләбинең*

*«Мәүлидән-Нәби» («Вәсиләтүн нәҗат») китабыннан*

# Әдәби сәхифә

**Муса Акъегет**

# Хисаметдин мелла

*(Дәвамы)*

## VII

Берничә көн үтте. Хәзерге вакытта Хисаметдин шәһәрнең тимер юл вокзалында. Көн кичкә авышкан. Шәһәрнең һәммә халкы вокзалга җыелган. Чөнки бу поезд белән мөфти хәзрәтләре Петербургтан Уфага узачак, имеш. (...)

Вокзалның эчендә вә тышында анда-монда мөселманнар сөйләшеп йөриләр. Гали бай Җаватов бу шәһәрнең ахуны вә башка байлар белән бергә сөйләшеп тора. Бикбулат мулла да шунда күренә. Ләкин авызыннан «әйе, шулай»дан башка бер сүз дә чыкмыйдыр. Әбүзәр бәк Дәүләтгилдиев, ялтыравык төймәле формасын киеп, Хисаметдин белән йөри.

Барчасыннан ерак, вокзалның бер диванында яшь бер әфәнде утыра. Бу кеше, крымка бүрекне бераз кырын киеп, һичкемгә кушылмаеп, утыргычның артына аркасы илә таянып, камыш таягы белән ачык калушларының йөзенә уйнап орыр иде. Күзләре дикъкатькә иң лаеклылар. Арыслан гайрәте белән карыйлар. Күзләре белән татарлардан һәрберсен йотып багар, һәр багышында кешенең эченә кереп чыгар. Бу вакыт әлеге арыслан күз, Хисаметдин мелла белән Әбүзәр мирзага багып, сүзләрен тыңлый иде. (...)

Кинәт колокол каккан тавыш поездның килүен белдерде. Күп халык платформага чыгып, мөфтине күрергә өмет итте. Мөфти хәзрәтләре үзенә махсус бер вагон алган иде. Шәһәр байларының чакыруын кабул итте. Вагоннан чыкты. Имамнар бер-бер артлы мөфти хәзрәтләренә сәлам бирерләр иде. Күбесе кулын үбеп, түбәнчелек белән каршылады-

лар. Мөфти Сәлимгәрәй Тәфкилев хәзрәтләре хәзерләнгән табын янына утырды. (…)

Хисаметдин вокзалда арыслан күзне эзли башлады. Ләкин теге арыслан күз инде вокзалдан чыгып киткән икән, аны тапмыйча, Әбүзәр белән вокзалдан чыгып, «Мохтар!» дип, каты тавыш белән кычкырды. Шунда ук, җир астыннан чыккан кебек, артында извозчик Мохтар пәйда булды. Ике яшь егет Мохтарның арбасына утырып киттеләр. Юлда барганда Әбүзәр бәк Мохтардан сорады:

– Эшләр ничек, баеп буламы?

– Мең рәхмәт, сез урнаштырдыгыз! – диде Мохтар.

– Миңа рәхмәт кирәкмәс. Яхшы гына баерсың. Шул булыр җаныма хуш рәхмәт. Сөйлә, айда күпме табасың? – дип сорады Әбүзәр бәк.

– Егермедән егерме өч монетка кадәр табамын, – җавап бирде Мохтар.

– Соң ничек алай була? Егерме өч сум табасың, ә айлык хакың фәкать алты сум? – диде мелла.

– И дустым мелла! Айлык хакны инде сөйләмә. Извозчиклыкта башка юллар белән табалар. Әгәр йокламасаң, һәр көн казанырсың өч-дүрт сум. Ә хуҗага бары ике сум бирсәң дә, бик шат буладыр. Шулай һәр көн бер-ике сум яшереп каласың да, акча да җыела.

– Болай мал хасил итмәк тугры юл түгел, – диде мелла.

– Бик тугры, чөнки ул акча өчен бәлки ничә төн йокланылмый. Моны ат хуҗасы үзе дә аңлый, һич сүз әйтми, зарар юк, – җавапланды Мохтар.

– Әлбәттә, хуҗа аңласа бу эшне һәм дә рәнҗемәсә, зарар юк, – диде мелла.

– Кара, эшне бел! – диде Әбүзәр бәк.

– Аллаһка шөкер, хәзердә илле монет акча тупладым, – диде Мохтар.

– Эшлә, эшлә, әүвәл җәфа, соңра сафа, – сүз кушты Хисаметдин. Сөйләшә-сөйләшә яшьләр бер йорт янына җитеп, арбадан төштеләр. Бу

йортка төшереп, Мохтар күздән югалды. Бу өй зур агач өй булып, ишегалды мәйданы киң иде. Яшьләр зур өйгә кермичә, бакчага үтеп, анда булган бакыр мастерскоена керделәр. Бакырханә эче тузан вә бакырчы хезмәткәрләр белән тулы. Анда самавыр төзәтәләр, монда лампа төзәтәләр. Бер тарафта молоток-чүкеч илә бакырны чик-чик сугып, башны авырттыралар. Бу бакырханәнең хуҗасы теге, вокзалда күргәнебез, арыслан күз Зурколаков иде. Әбүзәр бәк белән Зурколаков шулкадәр якын дус иделәр ки, гүя боларның ике гәүдәсенә бер җандыр. Мондый дуслыкның сәбәбе бу ике зат уй-фикерләренең уртак булуыдыр.

Әбүзәр бәк татар тормышы хакында фикерләрен күп җирдә сөйләсә дә, һичкем аңламады. Кайбер татарлар: «Фән вә фән, мәгърифәт, гыйлем вә һөнәр кирәк дип сөйлиләр, бу ни сүз? Гыйлем вә мәгърифәтсез дә гомер итә beләбез», – дип, Әбүзәр бәктән көлделәр. Кайбер имамнар болай диделәр: «Һөнәрле, мәгълүматлы кавем булу, әлбәттә, яхшыдыр, ләкин татар милләте һөнәрле була алмас. Бик күп еллар узды, татар милләте зыяланмады да, инде Әбүзәр кебекләр татарны башка милләтләр шикелле һөнәрле вә мәгълүматлы итәргә телиләр, бу – мөмкин түгел», – дип, Әбүзәр бәктән көләләр иде. Әбүзәр бәк, мондый татарларга ачуланып, дияр иде ки: «Әфәнделәр, мең еллар узды, татар зыяланмады, дисез. Зыяланмадык шуның өчен кем, эчебездә мәгълүмат алырга омтылыш, теләк юк иде. Мең елларга бакмагыз, бу вакыттан зыялыланырга омтылыш-теләгебез уянса, заман узу белән без дә мәгълүматлы булырбыз. Ләкин, мең еллар шулай узды дип, йоклауда дәвам итсәк, мең түгел, янә миллион еллар үтәчәк, вә без искечә наданлык дәрьясында калырбыз, вә үзебез һөнәрләр белмичә, башка милләтләргә хезмәтче вә кол булырбыз. Бәс, телик мәгърифәтне вә һөнәрне, чөнки татарда ярты гакыл түгел, зиһене бик камилдер. Зыялы булырга сәләтле бер халыктыр. Уяныгыз, кардәшләр! Уйланыгыз, моның кеби гакылсыз дәлилләрегез илә үзегездән көлдермәгез! Карагыз башка милләтләргә, бигрәк тә французларга, немецларга: болар суда

көймәдә балык кебек йөзү түгел, һавада кош кебек очу машинасы төзи беләләр. Әмма безнең сукалау белән вак сәүдәдән башка һөнәребез юк кебидер... вә фәлән... фәлән». Бу юлда Әбүзәр бәк һәр никадәр сөйләсә дә, фикерләрен һич кемсә аңламас иде. Кыскасы, бу фикерләр стенага борчак сипкән кеби иде. Татарны зыяландырудан өметен кисәргә дә аз калган иде. Ахыр чиктә Әбүзәр өметсезлектән котылды. Зурколаков та мондый идеяләргә күңел беркеткән кеше иде һәм Әбүзәр бәккә фикердәш булды. Икенче дусты Хисаметдин шулай ук аның фикерләрен хуплар иде.

Әмма максудыбызга килик. Гайса Зурколаков, егерме алты яшьлек бер егет булып, һөнәре бакырчылык иде. Бакырханәсе атасыннан калган иде. Хәзердә атасы вафат булган, Гайниҗамал исемле карт анасы бар иде. Атасы исән вакытта Гайсаны мөселманча вә бераз русча укыткан иде. Яшь вакытларыннан бирле Гайса Зурколаков ислам вә рус, гыйлем вә һөнәр китапларын укырга һәвәс егет булды.

Гайниҗамал абыстай алтмыш яшьләренә җитмеш бер хатын иде. Гаять диндар, яхшы вә хакыйкатьле хатын. Шәһәрнең барча халкы Гайниҗамал абыстайны хөрмәт итәләр иде. Гайниҗамал абыстай мелланы күреп болай диде:

– Мелла, син улымның хәлен белергә күптән килмисең?

– Хәзердә хәл белергә килдем, абыстай. Сиңа бер үтенечем дә бар.

– Нинди үтенечең, мелла, сөйлә, ишетәек.

– Безгә мәрхәмәт итеп, башкода булсагыз иде, абыстай. Өйләнергә телим, Габбас аганың кызын сорасагыз, бик зур мәрхәмәтегездән булыр иде! – диде Хисаметдин мелла. (...)

Бер өч-дүрт көннән соңра Гайниҗамал абыстай Габбас агайга башкода булып барды исә дә, Хәнифәне бирергә якын да килмәделәр. Хәнифә туташ Сибгатуллага бармаячагын вә мелла Хисаметдинга бару теләген һәр никадәр анасына сөйләсә дә, Шәмсекамәр абыстай кызына:

– Үз файдаңны үзең белмисең, ризыклы вә бай хатын булырсың. Сабыр ит, Сибгатуллага бирербез. Сүземне тыңла: син бала, мин ана! Баштан колак зур булмый, – дип, Хәнифәне үгетләде. Үзенчә төрле чаралар кылды.

Шәһәрдән илле чакрым ераклыкта бер авылда торучы ишан вә багучыны китертеп, бу ишан Хәнифә туташны Хисаметдин мелладан суытмага вә Сибгатулла әфәндегә җылытмага, ягъни мәхәббәт иттермәгә кереште. Вә бу хәйлә илә Хәнифә туташка догалар эчереп вә аягына туфраклар ташлап вә шуның кеби башка нәрсәләр эшләп, ишан хәзрәтләре Габбас агада бер атна кунак булып ятты. Киткәндә: «Инде курыкмагыз, эшемне тәмамладым», – дип, Габбас агадан акча һәм әйберләрдән гыйбарәт күп бүләк алды. Ләкин хәзерге заманда суытмак вә җылытмак, сөйдермәк вә биздермәк һөнәрләрнең юк нәрсә икәнен вә мондый һөнәрләр – булмый торган эш, чын ялганчылык вә шарлатанлык икәнен һәрбер зиһенле кеше яхшы белер.

## VIII

(...) Август аеның якты бер көне иде. (...) Авыл өстендә зур шау-шу вә гөрелтеләр купты. Түбән очтан өчәр ат җигелгән ун арба җил кебек киләләр.

– Бай туе, бай туе башланды! – дип, халык, умартадан чыккан корт кеби, өйләреннән тамашага чыга башладылар. Туй җәмгыяте урам буенча әйләнә, мылтык атудан, кыңгырау тавышыннан колаклар тона. Урамны төтен алды, бер сугыш купты дип уйларсың. Алдагы колясканың мылтыклары артыграк гөрселдиләр, бу коляскада кияү булачак Сибгатулла әфәнде һәм кияү егетләре утырган, атлары яшен кебек йөгерә. Хәтта ки юл аша узып баручы бер эт, өлгермичә, коляска көпчәкләре астында калып, уртага ярылып, эчәкләре һаваны бераз ислэттеләр. Туй Хисаметдин мелланың йорты каршысына җиткәндә, Сибгатулла әфәнденең кушуы-

на күрә, мылтыклар тагын да көчлерәк гөрселди башладылар. Сибгатулла әфәнде шул мылтык шартлаулары белән үзенең җиңүче булуын Хисаметдин меллага күрсәтергә уйлаган иде. Ләкин Хисаметдин, өйдә булмаганга, үзенең җиңелүен күрә вә ишетә алмады.

Сибгатулла әфәнде бик шат булып, туй мәҗлесен зур һәм тантаналы итеп ясады. Ни өчен шатланмасын, теләгенә ирешә, бу көн Хәнифәне аладыр! Кияү егетләре һәммәсе бал бузасы әсәреннән кып-кызыл кызарганнар. Сибгатулла әфәнде бигрәк тә кызарган иде. Ул кияү егетләренә карап: «Сүттерт, йөздерт!» – сүзләрен бик шатлык илә әйтә. Кыскасы, туй процессы ишетелмәгән вә күрелмәгән бер сурәттә башланды. (…)

Көндезге сәгать дүртләр иде. Кояш үзенең нурларын вә эсселеген чуар булып җәйрәп яткан кырларга чәчә. Сабан басуы дип аталган кырларның күренеше бик гүзәл иде: солы, карабодай вә тары үсеп утырган кырлар күзләргә кызгылт, аксыл, саргылт төсләрдә күренәләр иде. Кырларның гүзәллеге шат туйчыларны тагы да шат итә иде.

Туй җәмгыяте «Н» авылыннан биш чакрымнар киткән бер вакытта, көтмәгәндә каршы яктан атлы бер егет килеп җитте. Бу егет туй җәмгыятенең барудан тукталуына сәбәп булып, иң элек алда баручы Гали байның коляскасы янына килеп сөйләште. Сүз-сүздән соң байның ачуланганлыгы күренеп тора иде. Бәлки бу егет яман хәбәр китергәндер, дип уйладылар. Атлы хәбәрче белән биш-алты минут сөйләшеп, Гали бай углы Сибгатулланы янына чакырды. Туй җәмгыяте: «Ни өчен туктадык?» – дип кычкырыша башлады. Сибгатулла әфәнде исә, атасы илә хәбәрләшкәч, үлек кеби агарып, кайгы вә фикерләр дәрьясына батты. Башкода Бикбулат мулла телсез калып, нишләргә, ни дияргә белмичә аптырап калды. Шунда Гали бай: «Кайтырга кирәк», – дип, туйчыларга игълан итте.

– Бу ни хәл? Ни гаҗәеп, ни өчен кайтабыз? – дип, туйчылар хәйранга калдылар. Ничек булса да булды, туйчыларның барчасы, башларын җиргә иеп, кире авылга кайтырга мәҗбүр булдылар. Тик Гали бай белән Бикбу-

лат мулла гына, кайтмыйча, хәбәрче атлы егет артыннан шәһәргә юлландылар.

Юлда күп уйланулардан соң, Гали бай Бикбулат муллага болай диде:

– Гаҗәеп, мин хәстәрлек күрдем, туй чыгымнарын күтәрдем вә кәефләрен тәмам кылдым, ә алар кызларын югалтканнар Бу ни галәмәт!

– Бу сүзләргә каршы Бикбулат мулла бер сүз дә әйтә алмады, тик башын тагын да түбәнрәк иде.

## IX

Туйдан алда берничә көннәр Хәнифә туташ казык төбенә хатлар куйса да, алар сөйгәненә җитешмәде – Хисаметдин шәһәрдә дә юк, хәбәре дә юк. Хәнифә туташка мәгълүм түгел ки, ни сәбәптән мелланың туйдан хәбәре озак юк икән? Бәс, Хәнифә туташ өмет итте ки, Гали бай туе кебек олуг вакыйгадан Хисаметдин хәбәрдар булып, шәһәргә киләчәк вә үзен коткарачак. Чөнки: «Безне кем дә аера алмас», – дигән сүзләре туташның хәтерендә иде. Әмма туташның өмете акланмады. Инде шимбә көн җитте, якшәмбе – туй. Әмма Хисаметдиннан һичбер хәбәр юк. Кайгыга баткан Хәнифә үз бүлмәсендә өзгәләнә: «Ничә көннәр көтәмен, ни өчен килми икән? Бер-беребездән аерылмаска вәгъдә бирештек. Аның мәхәббәтендә мин шикләнмим. Мәхәббәтенә күрә мине ташламас, аерылышуны һич тә уйлый алмыйм. Ни өчен мине болай зарыктыра икән? Гаҗәеп! Юк, туй турында ул белмидер, белсә, бакчага, әлбәттә, килеп җитәр иде. Һай кош булса идем, очып яныңа җитешеп, хәлемне белдерер идем. Бүген инде шимбә көн булды. Килеп җитмәсә, мин һәлак булдым. Сөймәгән кеше белән бергә яшәмәк һәлакәт булмыйча нидер? Йә Аллаһ, нинди гөнаһларыма күрә мине газаплыйсың. Юкса ул хыянәт иттеме? Хәер, ул андый кеше түгел. Кичен бакчага килер. Ул җаным мине ташламас. Икейөзле кеше түгел».

Ничә мәртәбә туташ теге казык янына чыгып керде, әмма мелла юк, хаты алынмаган.

«Килмәде, килмәде, һәлак булам ахры? Юк, монда ни булса да бар, эшнең асылын белергә кирәк. Мелла хыянәт итсә дә, Сибгатуллага никахланмамын». Шул рәвешле күп уйлардан соң Хәнифә туташ ныклы бер карарга килде. Вә үз-үзенә диде: «Туктагыз, мин эш кылырмын, миңа хәзер барсы да бер, мин һәрбер казага әзермен». Шулай дип, яшь кыз үз-үзен юатты вә күңеле бераз хуш булды. Анасы исә олуг гайрәттә туй хәзерлекләре белән мәшгуль иде. Ахыр чиктә ярты төннәр булды. Хәнифә туташ бакчага хаты янына чыгып, бу юлы да мелланың юклыгын белеп, хатын кире кесәсенә куйды вә бүлмәсенә кайтты. Өйдә барсы да яттылар. Хәнифә туташ кулына беренче туры килгән киемен киеп, тәрәзәдән әкертен генә туры урамга сикерде. Бу – яшь кызның өйдән качуы иде. Төн бик караңгы. Шәһәр тирән йокыга талган. Каравылчы сызгыруыннан башка, яшь кызның колагына бер хәрәкәт тә ишетелмәде. Урамда янган фонарьлар гына кызның күңеленә бераз тынычлык бирделәр. Ул, бераз батыраеп, тротуар буйлап бара бирде. Күргәнебезчә, бу яшь кыз караңгы бер төндә иртәгәге никахтан качып бара. Әмма кемгә, кая барырга? Кем сыендырыр?

«Ни булса булыр, Гайниҗамал абыстайга барып хәлемне белдерим, ул яхшы хатын, мине һәрвакыт ярата иде», – дип, ул туп-туры Зурколаков өенә юнәлде (...)

– Абыстай, үтенеп сорыйм, Хисаметдин мелла шәһәргә килеп җиткәнче мине яшереп тор, кил Аллаһ ризалыгы өчен!

– Ай кызым, әстәгъфируллаһ! Ата-анаңа итагать кирәк. Юк, юк, өйгә кайт! – диде Гайниҗамал абыстай. – Бу ни хәл, ярабби! Ничек яшьләр бозылдылар! – Бу сүзләр Хәнифә туташның елавын, яшьләрен тагын да арттырып, ул янә каты ялварып:

– Әгәр син, абыстай, шәфкать итеп яшермәсәң, мин үз-үземне үтерүгә кадәр барырмын. Кил, шәфкать ит, җанымны коткар!-диде. Шуннан сон гына Гайниҗамал абыстай кызны берничә көнгә калдырырга риза булды вә әйтте:

– Бак, кызым, өч көннән кая теләсәң, шунда кит. Бу эшләр ярамас.

Хәнифә туташ, рәхмәтләр әйтеп, Гайниҗамал абыстай өендә урнашты.

### X

Гали бай илә Бикбулат мулла, шәһәргә җитеп, Габбас агайга керделәр.

Туй мәсьәләсендә «Н» авылында бер гауга купкан кебек, бу вакыт Габбас аганың өендә госманлы-төрек сугышына охшаш хурлашмак вә дәгъва башланды. Гали бай кодасының өенә килеп керү белән иң әүвәл сүзләре мондый булды:

– Инде, Габбас ага, яхшы кешеләр болай эшләмиләр. Туемны ничек кайтардыгыз. Мин туй белән киләм, сез кызыгызны күздән юк иткәнсез. Моны туйдан элек хәбәр итәргә кирәк иде, бу рисвайлык миңа!

– Сабыр ит, мин җан-тән белән. Үзебез синнән дә рисвай булдык...

Гали бай белән Габбас ага арасында хурлашмак шул дәрәҗәгә җитте ки, бер-берсенә күп әдәпсез сүзләр дә әйтештеләр. Шәмсекамәр абыстай үзе чыкканнан соң гына дәгъвалар азая төште. Чөнки Шәмсекамәр абыстай чыгып, шулай ук күп сөйләп, татлы ашатты да ачы костырды:

– Аллаһ, Аллаһ, байлыгыгызга инанып, кызымны көчләдем, харап булдым, йөрәк бәгърем баламнан аердың. Кайдадыр, белмибез, – дип, Шәмсекамәр абыстай күп сөйләде. Кыскасы, Хәнифә туташның югалуы күп сүзләргә, каты дәгъваларга сәбәп булды.

Ләкин без, бу бәлешләребезне калдырып, мелла Хисаметдинның хәлләренә күз салыйк.

Туйдан ике атна кадәр элек шәһәрнең чиста бер чәйханәсендә башка кешеләрдән ерак вә аерым бүлмәдә чәй эчеп, Хисаметдин, Әбүзәр бәк вә

Зурколаков әфәнделәр утыралар. Зурколаков әфәнде кызып болай сөйли башлады:

– Дуслар, милләт файдасы, милләт файдасы дип сөйләнәсез, сүз белән файда барлыкка килмәс, эш кирәк, җил куганнар.

– Мин бөтенләй файдасыз да тормыймын, сабыйларны укыту белән милләткә хезмәт итәм, – диде көлебрәк Хисаметдин мелла.

– Бу эшләрне сөйләмә, ихласлы милләтпәрвәр кеше бары тик балалар укыту белән генә канәгатьләнмәс. Булса булсын зуррак файда, – кисеп әйтте Зурколаков.

– Синең телең – кискен пычак. Синең белән кем дә сөйли алмас, – җавапланды Хисаметдин.

– Сабыр итегез, дуслар! Иң кирәк булган нәрсә, – сүзгә кереште Әбүзәр бәк, – кирәк булган нәрсә – татарны фән китапларыннан хәбәрдар итеп уятудыр. Җәмгыятебезнең күпчелеге фәннәрдән хәбәрләре юктыр. Фәнни китапларны туплап, шәкертләребезгә таратырга кирәк!

– Бу – икенче эш, бу мәгъкуль! – диде Зурколаков.

Бу уртак эш хакында күп киңәшкәннән соң, өч дус мондый карар бирделәр: шәһәрнең ислам халкыннан акча туплап, Кырымда нәшер ителгән җәгъръәфия, тарих вә табигатькә караган фән китапларын сатып алып, шәкертләргә вә укый-яза белгән фәкыйрь кешеләргә өләшергә. Әбүзәр бәк вә Зурколаков кеби кешеләрнең, әлбәттә, үз акчаларына да китаплар алдырырга хәлләреннән килә иде. Ләкин, бу вакыт мөселман җәмгыяте гомуми эшкә никадәр ихласлы, һәвәсле булуын тәҗрибә өчен, иганә акча җыярга карар бирделәр. Дуслар, иганә дәфтәре ачып, акча тупладылар. Мәгарифне сөюче исламнарның күбесе бу эшкә шактый булышлык вә ихлас күрсәттеләр. Әмма кайбер мөселманнар: «Буш эш белән йөрисез, безгә фән нигә кирәк», – дип, иганәгә акча бирмәделәр. Мондый мөселманнарга каршы Зурколаков бик ачы вә яман сүзләр әйтте. Хәтта ки иганә акчасы җыелгач, дуслар Әбүзәр бәктә булганда, Хисаметдин мелла Зурколаковны шелтәләде:

– Гайса, синең телеңне бераз кыскартмак кирәк, бик хәрап синең телең, иганә акча сораганда, ничә кайбер исламнарны хурладың. Бераз әдәп кирәк иде.

– Нинди әдәп? Исламлык дәгъвасын кылалар да, уртак исламия файдасы өчен монет кадәр акчаларын чыгармак өчен алар белән сәгать буе сөйләшергә кирәк. Миңа фән китапларының файдасын инкяр итсеннәр дә, мин мондый кешеләрнең сүзләрен әдәп белән тыңлап торыйм. Исламия файдасы өчен тырышып йөрүне тиле вә буш эштән санасыннар да, мин аларга әдәпле булыйм. Андый гакыллы ишәкләр фән белүне зарарга санасыннар да, мин аларны хурламыйммы? Андый мөселманнарны хурлау гына аздыр. Битләренә төкереп, алардан йөз чөерергә кирәк. Андый гакыллы ишәкләрне…

– Булды, булды! Җитәр, җитәр, Аллаһ өчен җитәр инде, Гайса, синең белән сөйләшү мөмкин түгел! – дип, Гайса әфәнденең сүзен кисте Хисаметдин.

– Әлбәттә, минем белән буш сүзләрне сөйләшеп булмас! – кисеп әйтте Зурколаков.

– Туктагыз! – диде Әбүзәр бәк. – Китаплар җибәрү хакында хат языйк.

Дуслар хат яздылар. Хат белән бергә иганә акчасына үзләреннән дә шактый акча өстәделәр.

Ун көннәр узгач, фән китаплары почта белән килеп тә җитте. Мәгарифпәрвәр егетләр китап өләшүне Хисаметдин меллага тапшырдылар. Бәс, Хисаметдин, китаплар өләшер өчен, тирә-якта булган татар авылларына чыгып китте. Нәкъ шул вакыт, ягъни Хисаметдин китаплар өләшергә авылларга чыккан вакытта, туй эшләре башланды.

Туй турында ишетү Хисаметдинга һич мөмкин түгел иде. Чөнки мелла авылларда зур тырышлык вә эштә булып, дин кардәшләренә китаплар биреп, фән мәнфәгатьләрен кайгыртып-аңлатып сәфәрдә йөрде. Ахыр чиктә, туй маҗараларыннан соң бер көн соңра, «Нун»га кайтты. (…) Хәнифә

турында ишетеп, анасыннан никадәр сорашса да, эшнең асылына төшенә алмады. Анасы диде ки, кайберәүләр авылда сөйлиләр, Габбас кызы качкан имеш. Кайберәүләр, суга баткан, дип сөйлиләр. Кайберәүләр, Габбас ага кызын үзе яшергән, дип сөйли. Авылдагы төрле-төрле хәбәрләрдән мелланың гашыйк җаны бик борчылып, өендә бер төн дә кунып тормыйча, шәһәргә мәгъшукасын эзләргә юлланды. Шәһәрдә көнне анда-монда сугылып, төрле кешеләр белән сөйләшеп, борчылып уздырды. Ләкин мәгъшукасы хакында һичбер дөрес хәбәр ишетмәгәч, кичен Гайниҗамал абыстайга барырга карар бирде. (...)

Гайса Зурколаков мелланы каршылап, китаплар өләшү турында сорашты.

– Ни өчен бик озак йөрдең? – диде Зурколаков.

– Нинди озак? Минемчә, тиз кайттым әле мин. Китаплар биргәндә, укый-аңлый торганрак шәкертләргә бирергә кирәк, андыйларны табу бик тиз эш түгел.

– Ахры, меллаларга вакыт бәһале нәрсә түгел. Син бел ки, вакыт бик кыйммәтле нәрсә. Вакытны бушка сарыф итмәк ярамас. Үзең беләсең ки, бер минут юкка үткәрсәң, ул бер минутны кире кайтармак мөмкин түгел. Шуның өчен инглиз мәкале бар ки, «вакыт сәрмаядер, сәрмаяне бушка сарыф хәрамдыр». Бәс, вакытны да бушка сарыф итсәң, гөнаһлы булырсың!

– Булды инде, Гайса! Әйттем ич инде, тиз кайттым. Буш вә кирәксезгә йөрмәдем! – җавапланды мелла.

– Ләкин мин синнән дә тиз кайтыр идем! – диде Зурколаков.

– Син бүген шат күренәсең, Гайса! Күп сөйләү – шатлык галәмәтедер. Әмма белмим, нигә шатланасыңдыр.

– Мин шат булсам, син бүген кайгылысың. Борыныңны җиргә салуың кайгы галәмәтедер. Әмма кайгыланып ни файда булсын. Һәрвакыт шат булу күңелгә дә хуш, эшләр яхшырак барадыр. Кайгы исә һәм эшкә, һәм тәнгә зарар. Чөнки татар шагыйре болай ди:

Каенсар төбендә кар булмас,

Кайгылы йөрәктә май булмас.

– Күп сөйлисең, ахры, синең йөрәктә май күп.

– Үлчә йөрәгемне, ничә мыскал икән? – диде көлеп Зурколаков.

– Кайдан сиңа килде көлке? – сорады мелла.

– Ай мелла, син аңла, безнең өебездә күп эшләр бар. Ничек килмәсен көлке, анаем булды төлке. Миңа карата төлкелек итә башлады.

– Нинди төлкелек? – сорады мелла.

– Олуг төлкелек. Узган төндә анаема бер мосафир килмеш. Мин сорадым: «Анай, кем сиңа килде?» Ул миңа әйтми: «Кем килмәс, хатыннар эшенә катнашырга синең эшең түгел», – ди. Мине дә мосафирны күрер өчен үз бүлмәләренә һич җибәрмидер. Бу төлкелек түгелме? Углыннан мосафирны яшерә.

– Гаҗәп, нинди ул мосафир?

– Мин белмим. Хезмәтче хатын миңа диде ки: «Килгән мосафир яшь хатындыр», – диде Зурколаков.

Шуннан соң Хисаметдин белән Зурколаков Гайниҗамал абыстайга керделәр. Меллабыз Гайниҗамал абыстай белән сөйләшкән арада, үзе дә сизмәстән, сүзне туйлар, Габбас агалар тарафына юнәлдерде. Ләкин Гайниҗамал абыстай әлеге сүзне озайтмыйча, аз-аз сөйләп, кыска җавапланып тынып калды. Мелла борчылып, теге кунак хатын хакында сөйләп карады. Ләкин абыстай моңа җавапта болай диде: «Килгән кунак – бер авылдан килгән хатын».

Инде Хисаметдин мелла, мәгъшукасы хакында бер мәгълүмат та тапмыйча, төн җиткән вакытта Зурколаковлардан чыкты. Хәнифә туташны уйлый-уйлый, кайгылы хәлдә бара иде. Күктәге болытлар вә яңгыр мелланың кайгысын тагын да арттыралар иде. Караңгы кич, аяк астындагы юешлек вә көчәйгән яңгыр – һәммәсе мелланың өметсезлеген арттырып, күңеленә бер кәефсезлек китерәләр иде. Шул хәлдә Хисаметдин, зонтын ачып, хәсрәткә ба-

тып, кунак өенә, ягъни Әбүзәр бәккә кайтып бара иде, кинәт артыннан бер кеше куып җиткәнне ишетеп, әйләнеп караса, хәйран калды. Бу – шатлыктан хәйран калу иде. Артыннан җиткән кеше – мәгъшукасы Хәнифә туташ икән! Ике гашыйк шунда ук бер-берсенә якынлашып сарылдылар. Элекке кайгы шатлыкка әйләнде. Инде яңгыр да гүя күңелле итеп ява.

– Синме, җаным? Күзләрем алдамыймы? – дип сорады Хисаметдин.

– Тиз, кая китсәң дә алып кит; артыбыздан төшмәсеннәр. Гайниҗамал абыстайда сине күреп, чыгып киткәнеңне көтеп, аннан качтым, – диде туташ. (…)

Ярты сәгать үтәр-үтмәс, Хисаметдин мелла сөйгәне белән бергә үзенең йөгрек атында «Нун»га юнәлде…

## XII

Бер атнадан соң «Нун»да Хисаметдин мелла өендә туй мәҗлесе булды. Габбас ага, Шәмсекамәр абыстай, күп фикерләрдән соң, игътибар белән яхшы гына уйлап, каргыш вә ачуларын ташлап, дәгъвалашудан файда чыкмаячагына төшенеп, ахырда Хисаметдин мелланы кияүлеккә кабул иттеләр.

Асылда Габбас аганы солыхка Гайниҗамал абыстай илә Зурколаков кайтардылар. Чөнки Хәнифәне авылына алып кайтканның соңында Хисаметдин тизлек белән Зурколаковларны башкодалыкка вә килешү эзләргә Габбас агайга җибәргән иде. Инде шуннан соң хәзер мондый шатлыклы туй мәҗлесен күрәбез. Бу туйда Габбас ага вә Шәмсекамәр абыстайның якыннары белән бергә, Хисаметдин мелланың дус-ишләреннән Гайниҗамал абыстай, Гайса әфәнде һәм Әбүзәр бәк тә булдылар. Белешебез Бикбулат мулла никах укырга мәҗбүр булды. (…)

Гашыйклар берәр ел «Нун» авылында зәвык белән, күңелле итеп тордылар. Әмма ике ел үтмәстән, Хисаметдин, мөлкәтен сатып, Кавказга Тифлис шәһәренә күчте һәм гаиләсен дә шунда күчерде.

Югарыда яздыгымыз ятим Мохтар, хәзерге вакытларда Тифлистә мануфактура малы илә сәүдә итеп вә мал-мөлкәт иясе булып, үзенә Тифлистә абруй-авторитет казанып, иске дусты Хисаметдин мелланы анда имамлыкка чакырды.

Элекке теләнче Мохтар хәзер инде Мохтар әфәнде Хәмитов булып, имам булган Хисаметдинга үз акчасына мәдрәсә салдырды вә мәдрәсә шәкертләренә кесәсеннән тереклек итәр өчен акча билгеләде.

Башка белешләребез һәркайсы үз эшендә калдылар.

**Ришат хәзрәт Курамшин**

# Сорый белсәң – теләк, сорый белмәсәң…

Нурулла хәзрәт мәчеттәге бүлмәсендә Коръән укып утырганда, кемдер кыяр-кыймас кына ишек шакыды. Укый башлаган аятен тәгәлләп, “садәкаллаһүлгәзыйм” дигәннән соң, хәзрәт башын күтәреп, ишек шакучыга дәште:

- Әйе, кем бар анда, рәхим итегез!

Менә ишек ачылды һәм бүлмәгә башына яулык япкан, матур хиҗап күлмәк кигән урта яшьләрдәге мөлаем бер хатын керде. Киеменнән генә түгел, нурлы йөзе белән күз карашыннан да аның гамәл-гыйбадәт кылучы мөслимә булуы аңлашыла иде. Сәлам биреп исәнләшкәннән соң, ханым, өстәл янындагы урындыкка утырып, болай диде:

– Хәзрәт, үземне борчый торган бер сорау белән килдем әле мин сезгә. Мөмкинме?

– Нишләп мөмкин булмасын? Бик хуп, Аллаһ ярдәме белән җавап бирергә тырышырбыз, ин шә Аллаһ.

– Эш шунда ки... минем инде күптән тормышка ашырасы килгән бер теләгем, алай гына да түгел – олы бер хыялым бар. Ләкин көнен дә, төнен дә дога кылып сораганыма карамастан, әлеге хыялым нигәдер тормышка ашмый. Догам кабул булсын өчен миңа берәр киңәш бирә алмассыз микән?

– Дога кабул булсын өчен Аллаһ кушканнарны үтәргә, Ул тыйган нәрсәләрдән тыелырга кирәк, – диде Нурулла хәзрәт, – Әйтик, намаз укымасаң, хәрам ризык ашасаң, дога кылып Аллаһы Тәгаләдән нәрсәдер сорау бик читен бит ул, сеңлем.

– И хәзрәт, инде биш елдан артык намазда, Аллаһка шөкер. Чиста күңел белән, хәрамләшмичә яшәргә тырышам, әлхәмдүлилләһ!

Мондый җавапны ишеткәч, имам болай диде:

– Рәхмәт, сеңлем, бик рәхмәт, ихлас кылган гамәл-гыйбадәтләрегез кабул булсын! Ә дога-теләкләрнең кабул ителмәве хәерлегә дә булырга мөмкин.

Киңәш сорарга дип килгән хатын: “Ничек инде шулай?” – дип гаҗәпләнүен белдергәч, Нурулла хәзрәт үзенең имамлык чорында булган гыйбрәтле дә, хикмәтле дә хәлне исенә төшереп, сөйләргә булды.

– Берничә ел элек мәчеткә сезнең яшьләрдәге бер ханым килеп керде. Елый-елый сәдакасын сузып, дога кылуымны үтенде ул. Тормыш иптәше вафатына инде бер ел булган, ә ул аны һаман оныта алмый һәм һаман үкенә икән. Нәрсә булганын сөйләвен үтенгәч, ул күңелен ачып, күз яшьләре белән сугарылган тормыш вакыйгасын бәян итте:

“Ирем бик әйбәт кеше иде, әмма эше буенча командировкаларга еш йөрде. Кайчакта берничә көнгә чыгып китә, кайвакытта ике-өч атнага, бер айдан артык эш сәфәрендә йөреп кайткан чаклары да күп булды. Бу миңа һич тә ошамый иде. Иремнең өйдән чыгып китеп, атналар, айлар буе читтә йөрүеннән тәмам туйгач, дога кылып: “Йә Раббым, ирем гел янымда гына булсын, беркая да китмәсен иде!” – дип, Аллаһы Тәгаләдән ялварып сорый башладым. Ике ел дәвамында бернинди дә үзгәреш булмады, әмма мин

өметемне өзмичә дога кылуымны дәвам иттем һәм көннәрдән бер көнне иптәшемнең эшеннән шалтыратып, шомлы хәбәр җиткерделәр: “Ирегезне авыр хәлдә хастаханәгә алып киттеләр, шунда барсагыз иде”.

Хастаханәдә озак кына яткырганнан соң, иремне өйгә озаттылар: носилка белән “Ашыгыч ярдәм” машинасына күчереп, без яши торган йортка күтәреп кертеп куйдылар. Ни булганын аңлап та бетерә алмадым: паралич сугып, ул бөтенләй хәрәкәтсез калган иде. Шуннан ел ярым өйдә урын өстендә ятканнан соң, ирем күзләрен мәңгелеккә йомып, бакыйлыкка күчте. Кадерлем гел янымда торып, бәхетле булырмын дип хыялланган идем югыйсә, әмма догада дөрес сорый белмәгәнмен шул”.

– Менә шундый гыйбрәтле сабак, сеңлем, – дип, имам хикәятен тәмамлап куйды. – Кайчакта без бик тә теләгән нәрсәнең тормышка ашмавы хәерлегә дә булырга мөмкин.

Хәзрәт бүлмәсенә кергән хатын беравык сүзсез утырды. Бераздан исә, аңына килгәндәй, башын күтәрде дә, әкрен генә әйтеп куйды:

– Алай икә-ән. Сорый белсәң – теләк, сорый белмәсәң…

Шуннан соң йөрәге “дөп-дөп” килгәнен тойгангадыр, ханым кинәт кенә торды да, бүлмәнең ишегенә таба кызу-кызу атлады. Нурулла хәзрәт исә, ихлас кызыксынуын белдереп, сорап куйды:

– Ашыкма әле, сеңлем, хыялың турында берни әйтмәдең ич, синең тормыш иптәшең кайда эшли?

Бермәлгә ишек төбендә туктап, ханым башын хәзрәт ягына борды да, кысылган иреннәре аша берничә генә сүз кысып чыгарды:

– Кайда эшләсен? Шунда инде, шунда.

Шуннан соң бүлмәдән чыгып, ишекне япты да, күңеле тулып елап җибәрде. Бу мизгелдә ул бик мөһим бер нәрсәне аңлап, Раббысына шөкер хисләрен җиткерде һәм, фикере белән элек кылган догаларын төзәтә-төзәтә, үзенә бик тә кадерле булган кешесен күрергә дип өенә ашыкты.